Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 32 (1397) 19 август 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

8

Яртысына якын халкын чуашлар тәшкил иткән Чүпрәле районыннан бик якты хис-тойгылар белән кайттык.

12

Г.Камал театры актрисасы Люция Хәмит балаларча ихлас елмаюы, рольләрдәге эчкерсезлеге белән аерылып тора.

16

Казанда узган түгәрәк өстәл сөйләшүе республикада керамика сәнгатен үстерүгә бәйле бик күп четерекле мәсьәләләрне ачты.

Борынгылар сүзе гел заманча – Хәрәкәттә һәммә бәрәкәт!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш авылында Котлы авылы тарихына багышланган истәлек ташы куелды.
- Бөек Ватан сугышы музей-мемориалында Михаил Девятаевка Советлар Союзы Герое исеме бирелүгә 65 ел тулуга багышланган «Тормыш батырлыктан гыйбарәт» күргәзмәсе эшли.
- Лениногорск районының Тукмак авылына 100 ел тулу уңаеннан бәйрәм оештырылды.
- Төркиядә Себер татарларының Госманлы дәүләтенә мөһаҗирлеге турында «Себердән Төркиягә гасырлык күчешнең бәяны. Бөгрүделик татарлары» дип аталган төрекчә китап дөнья күрде.
- Самара өлкәсе Иске Ярмәк авылында шагыйрь Зыя Ярмәки исемендәге сквер ачтылар.
- Татарстан мәдәнияте көннәре кысаларында башкала Мәскәү кинотеатрларында Татарстанда төшерелгән сигез фильм һәм ике мультфильм күрсәтеләчәк.
- Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясында «Мирас һәм традицияләр» күргәзмәсе буенча түләүсез экскурсия узды.
- Болгар шәһәре һәм Биләр авылы территориясендә, соңыннан Казанда рәссамнарның Бөтенроссия пленэры үтте.
- Казанда Беларусь Республикасы мәдәнияте көннәре бара.
- 24 августта Мәскәүдә Россия дәүләт балалар китапханәсендә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинга багышланган иҗат кичәсе узачак.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Шамил САДЫЙКОВ, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры:

«Бүген төп проблема – телне камил белгән, татарча фикер йөртә алган, чиста татар телендә текст яза алган балалар булмау. Моның бер сәбәбе, әлбәттә, татар мәктәпләренең саны кимү. Соңгы биш ел эчендә килгән студентларның күбесе Арча яки Актаныш районыннан. Әгәр бала татар мәктәбендә укымаса, татарча аралашмаса, татар китаплары һәм матбугатын укымаса, аның теле камил булмый. Безнең хәзерге бурыч – саф татар телле балаларны эзләп табып, аларны журналистикага өйрәтү».

СЫНАМЫШЛАР

19 августтан (Алма Спасы) соң уҗым чәчә башлыйлар ● Икенче Спас – бияләй ал кулыңа запас ● 21 август һавасы гыйнварның нинди булачагын күрсәтә ● Сөмбеләдә (августта) арыш чәч – тамагың булмас ач ● 23 августта эссе булса, көз җылы килә; көчле яңгыр яуса – яңгырлы була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 22 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 10 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **14 сәгать 48 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **26 августта 14 сәгать 17 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

19 август – рәссам, реставратор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Айдар Нурмөхәммәт улы Хисамовның тууына 60 ел (1962–2019);

– рәссам Нияз Нурмөхәммәт улы Хисамовка 60 яшь (1962).

20 август – режиссёр, педагог, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Илгиз Габидулла улы Мәҗитовның тууына 90 ел (1932–2004);

– язучы, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Равил Вәли улы Вәлиевнең тууына 80 ел (1942–2020).

21 август – язучы Газизҗан Салих улы Кашаповның (Кашшаф-Үзиле) тууына 80 ел (1942–1991).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 22-25 август.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(19-27 август)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген мөхәррәм аеның 21 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рамазан КӘБИРОВ

МӘГАРИФКӘ «МӘ» дип торалармы?

Укытучыларның август конференцияләре мөнбәренә

Тормыш - педагогика фәне казанышларын, укытуның яңа методларын, яңа дидактик идеяләрне практикага акрын кертү, дәресләрне оештыра һәм аларны үткәрү методикасының эшләнеп җитмәгән булуын раслады. Бу милләтебезне нык борчуга сала. Кайбер сәбәпләрен ачыклап, һичшиксез хәл ителергә тиешле нигезләрне саныйк:

1. Мәгариф һәм фән министрлыкларының берләштерелүе – тик зыянга гына.

2. Аларның җитәкчеләрен бертуктаусыз алмаштырып тору борчуга сала.

3. Традицион укыту алымнарына кул селтәп, IT технологияләрне, бүген инде цифрлаштыруны беренчел итеп карауны шиксез максат итеп кую һәм алга-артка карамыйча, абына-сөртенә «цифрлы технологиядән башка укыту юк» принцибын гамәлгә ашыру акылга сыймаслык. «Адымнар» мәктәпләрен ачуны киметә төшеп, милли телдә белем-тәрбия бирүче, гореф-гадәтләргә өйрәтүче, илебезгә, телебезгә, ата-бабаларыбызга, әти-әниләргә тугрылыклы, ярдәмчел, эшлекле яшь буын тәрбияләүче мәктәпләр беренчел булырга тиешлеген һәммәбез аңлый. Мәктәп китапханәләрендә «Татмедиа» канаты астында чыгучы барлык газета-журналларның булуы кире какмаслык дәлил. Бөтендөнья татар конгрессының милли мәгариф – татар мәгарифе белән бөтенләй диярлек шөгыльләнмәве күңелдә әрнү уята.

4. Педагогик кадрлар булдыру, аларның белемнәрен камилләштерү буенча гасырлык тәҗрибәсе булган педагогика университеты, гуманитар институт мәгариф юлыннан бөтенләй читләштерелде. Алай гына да түгел – ишекләренә йозаклар салынды.

5. Ата-аналарның мәктәп, укытучы эшчәнлегенә, укыту-тәрбия өлкәсенә урынсыз тыкшынуы мәгарифне тик аксата гына.

6. «Уен» методикасы белән заманга яраклы яшь буын тәрбиялибез дигән һәлакәткә илтүче юлны юлдаш итеп алу да файдага булмады.

7. Дәреслек һәм программаларның билгеле бер калыпта, мәгънәви, тәрбияви кысалардан чыгып, «каләм тота беләм» дип санаучыларның дәреслек-хрестоматияләр язуга алынулары шик уята. Төпләп уйласаң, туган тел һәм әдәбият дәресләкләрен язу өчен, ким дигәндә меңьеллык татар әдәбияты тарихын җентекләп белү таләп ителә.

8. Хәзерге заман укытучысының компетентлыгы, дәрәҗәсе, тормыш шартлары түбәнәя бару, хезмәт хакының көлке дәрәҗәдә булуы турында дистә еллар сүз алып барылса да, нәтиҗәсе күренми.

9. Авыл мәктәпләренең ябылу процессын читтән генә битараф күзәтеп тору җитәкчеләр өчен гадәти бер хәлгә әйләнде.

10. Муниципаль районнарда эшләгән атлы булып саналган мәгариф бүлекләре штатларын дүрт-биш тапкыр кыскартып, аларда штатта торучыларның ун кешедән дә артмаска тиешлеген басым ясау урынлы. Чөнки мәктәпләрдән, балалар бакчаларыннан көндәлек мәгълүмат – фотолар җыю һәм аны министрлыкка җибәрү, белгечләр булган очракта, методик эшне җанландыру өчен җитәрлек сан бу. Укучылар, укытучылар кимегән, мәктәпләр ябылган вакытта, нәкъ шулай эшләү урынлы булачак.

11. Авыллардагы мәктәпләрдә озынайтылган көн төркемнәрен яңадан эшләтеп җибәрү бүген иң кирәкле укыту-тәрбия адымы булачак.

12. «Туган телне гаиләдә өйрәнү зарур», – дигән милләтләргә каршы юнәлтелгән ялгыш караштан арыну, тәүбәгә килү кирәк. Башка фәннәрнең өйдә, әти-әни, әби-бабайлар белән өйрәнергә кирәклегенә басым ясамыйбыз бит.

13. «Балаларга Болгар дәүләте тарихын өйрәтү беренчел булырга тиеш», – дигән фикер дә ялгыш, аннан арыну – файда. Татар тарихы Алтын Урдадан башлана, моны кемнең исенә төшерәсе? Гомумән, мәктәпләрдә Татарстан тарихы дәресләрен туксанынчы еллардагыча рәсми рәвештә укытуны бу елның беренче сентябреннән гамәлгә кертү дөрес булачак.

14. Әдәбият фәнен укытуга килсәк, кемсә наданнарыбызның (бигрәк тә журналистларның, социаль челтәрләрнең) «Шигърият – татар әдәбиятының йөзек кашы» дигән уйдырмалы караштан кичекмәстән баш тарту. Әдәбиятның йөзек кашы – әдипләр була бит ул.

15. Туган җирләрендә яшәп тә, төрле сәбәпләр белән туган тел мохитеннән мәхрүм ителгән милләттәшләребезнең үз телләрендә белем алуга хокуклары чикләнмәс бер бурыч булу зарурлыгына җитәкчеләребезне инандыру. Сабантуй бәйрәмнәрен чит төбәк-җөмһүриятләрдә үткәрүнең мәҗбүриленгәнә ышандылар бит. Сабантуйларны үткәрүне берәү дә икърар итми. Тик аларның татар милләте геннарына нигезләнгән, татар телле, исеме җисеменә туры килердәй булуы хуплана лабаса! Иң әүвәл, борын астыннан сөрт дигәндәй (гафу үтенәм), бәлки, Татарстанда Сабантуй бәйрәмнәрен җиренә җиткереп, читтә яшәүчеләргә үрнәк булырдай итеп оештырып үткәрәседер?

16. Мәктәп директорлары корпусы мәсьәләсендә дә борчылырлык урыннар күп. Тиешле белеме, тәҗрибәсе, мөгаллимлек эшенә маһирлеге җитеп бетмәгән, әмма яшь (имеш!), «цифрлы» җитәкчеләр өстенлек итә башлады. Бу эшне башкару психологик, методик яктан тулы әзерлекле, укытучылар һәм укучылар кадерен белүче ЗЫЯЛЫЛАРГА тапшыру элек-электән гадәткә кергән. Ак күлмәк, галстук, кәнәфи, мин-минлек белән генә, яшь булсаң да, ерак китеп булмас...

Ачыкланып бетмәгән кайбер фикерләрне кыскача шәрехләп китү дә зыян итмәс. «Әти-әниләре укытучы булган», – дигән теорияне читкәрәк этәреп, укытучы һөнәренең ачысын-төчесен үзе «татыган», белемле, тәҗрибәле, үзфикерле, әмма башкалар фикерен дә читкә куймаучы ПЕДАГОГ кына мәгариф министры вазифаларын җиренә җиткереп башкара ала. Шуның өстенә: «Туган тел гаиләдә өйрәнелергә тиеш», – дигән ялгыш вә демагогик фикердән азат булуы да беренчел булырга тиеш. Туган телләр мәктәптә төпләп өйрәнелергә тиешлеге һәркемгә мәгълүм ки. Элеккеге каһарман мәгариф министрыбыз Мирза Мәхмүтовның проблемалы укыту методикасын онытканлыкны яки барлыгын да белмәгән җитәкчеләребез, Совет хакимияте чорында рус һәм татар телләре янәшә торып, икесе дә тигез рәвештә укытылуын искә алсын, бер дә булмаса, башкалардан сораштырсын иде. Данлыклы милли мәктәпләр институты булганлыгын, анда эшләүче галимнәрнең татар һәм башка милләт балаларына рус теле һәм әдәбиятын укыту буенча эшчәнлеген сызып ташлау, йомшак кына әйткәндә, үтә наданлык һәм җавапсызлык билгесе ул.

Бүгенгедәй хәтеремдә, ун ел элек Татарстан Дәүләт Советында татар телле мәктәпләрнең директорлар киңәшмәсе булды. Сүз яңа кабул ителәчәк Мәгариф турындагы закон турында барды. Фикер алышуларда катнашып, әлеге Законның тиешенчә эшләнеп бетмәгәнлеге хакындагы фикеремне катгый рәвештә әйттем. Башкалар да хуплады. «Файдасы» булды – Закон атна эчендә кабул ителде.

Сүз иярә сүз чыгып, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы хезмәткәрләре (алар да катнашкан иде) директорларны рәхәтләнеп сүкте. Чөнки ул елны республика буенча бер укучы гына әдәбияттан БДИ биргән иде. Гаепләрне тиз таптылар, баксаң, мәктәп директорлары һәм татар теле, әдәбияты укытучылары икән! Ниһаять, ун ел узгач, «нәтиҗә янә күренде». Быел инде бер укучы гына татар теленнән БДИ биргән. Чамалыйсыздыр, үзгәрешләр ифрат «куанычлы»... Сәбәпләре мең тапкыр язылган, сөйләнгән, яңадан тукталу урынсыз.

Утырышлар залыннан чыгуга, үземне ТНВ журналисты «эләктереп» алды. Беренче сүзе укытучыларның бу елдан хезмәт хаклары артуы хакында булды. Мин болай җавапладым: «Сез хаклы түгел, бу әле укытучыларның хезмәт хакы артуын расламый, ә бәлки элеккеге еллардагы түләнмәгән әҗәтләрне кайтаруның беренче адымнары гына»... Дөресен әйтергә кирәк, җавап эфирда да яңгырады. Шуннан соң ун ел вакыт узды. Тик укытучыларның хезмәт хаклары һаман бер урында таптана. Шуны да өстик: сүзебез эштән аерыла икән, ялгышларыбызны әле танымыйбыз, төзәтергә дә ашыкмыйбыз тормыйбыз, дип санарга мең мәртәбә хакыбыз бар.

Укытучылар август конференцияләренә нәкъ менә бергәләп фикерләшү, иртәгәге көнгә дөрес юнәлешләр билгеләү өчен җыела. Карап багыйк, битарафлар саны кимерме?

ИЛАҺИ ЯШӘЕШ

Бар җиһан илаһият кануннары буенча яши. Җирдә бөтен мәхлукат та Аллаһ кануннарына буйсына. Бары тик адәми зат кына, үзенә йөкләнгән илаһи миссиянең (ә ул – Җир хуҗасы булу, Хак Тәгалә шуның өчен аңа акыл биргән) асылын аңламыйча, җаһил юлга кереп китә, саташып һәм ясалма кыйммәтләр системасы булдырып, ниндидер иррациональ дөньяда яши башлый. Ә кем аны хак юлдан яздыра соң? Дини тәгълиматларда анысы инде иблис образында бирелә. Мәгәр, иблис токымы Җирдә дә яши. Ул гына түгел, тормышта без иблис вәсвәсәсе белән һәр көнне очрашып торабыз. Кешенең нәфесен, мин-минлеген һ.б. йомшак якларын кулланып, мәгълүмат чаралары аша бу токым тәүлекләр буена үзенең геосәяси мәнфәгатьләрен алга сөрә, акны – кара, караны ак итеп күрсәтә, бәндәләрне саташтырып, әнә шул ясалма кыйммәтләр системасына кертә, юлдан яздыра. Күпләр игътибар иткәндер, телевидениедә бүген һәр каналда бер «иблис» утыра...

Әлбәттә, Җирдә җаһилият белән көрәш бер бүген генә бармый. Россиягә, дөнья тотучылар тарафыннан геосәяси максатларда (сәясәт коралы итеп куллану өчен) корылган дәүләт буларак, бу яктан аеруча кыенга туры килә. Чөнки ул һәрчак ясалма идеологияләр вә ясалма кыйммәтләр системасында кала. Узган гасырда, әйтик, революцион үзгәрешләр генә дә анда өч тапкыр булды, хәтта революцион династияләр дә барлыкка килде. Дөрес, оныкларына кайчак бабалары идеологиясенә каршы да ши итәргә туры килгәләде, әмма идарәдәге кавем шул ук калды. Бүген инде идеология кабат капма-каршыга үзгәртелә. 90 нчы елларда либераль кыйммәтләрне алга сөргән бәгъзеләр, бүген парламентта тоталитар режим һәм үз геосәяси ихтыяҗларына кирәкле законнар кабул итә. Илдә төп халыкларның туган телләрен чикли һәм милли мәгарифләрен җимерә торган законнар кабул итүдә зур роль уйнаган шундый бер зат бүген үзәк телевидение каналында инде зур сәясәт турында лаф ора, иҗтимагый аңны саташтыруда бабасы эшен дәвам итә. Мондый кискен борылышлар идарәдәге кавемгә «болганчык суда балык тоту» өчен кирәк. Андыйлар, асылда, Көнбатыш белән капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итә.

Хуш, ә гади халыкка нишләргә соң? Җавап, гадәттәгечә, гади: иблис коткысына бирелүдән туктап, абсолют кыйммәтләр системасында (илаһият кануннары буенча) яши башларга өйрәнергә. Ә алар бөтен кешелек дөньясы һәм хәтта бар җиһан өчен дә уртак. Ул чакта инде иблис токымының мәкерле гамәлләре генә түгел, ә җаһил ниятләре дә уч төбендәге кебек күренәчәк. Дөрес, моның өчен Аллаһтан бирелгән акыл көчен дә эшкә җигеп иҗтиһат кылырга туры киләчәк. Юкса, күпләр диние дини йола үтәү дип кенә белә. Ислам динендәгеләрдә дә бу бар: иман ныклыгына караганда, дини йолаларны өстен күрү; гарәпләргә охшарга тырышу (аларча исәнләшү, хатын-кызларның аларча киенеп йөрүе) һ.б. Араларында хәтта, диндә милләт юк, дип тәкрарлый торган наданнар да очрый. Илаһи асылы һәм әхлак ягыннан бу инде ата-ананнан баш тартуга тиң. Иман ныклыгы исә, дини йолалар үтәүне генә түгел, ә иң элек яшәү рәвешен илаһият кануннарына туры китереп үзгәртүне күздә тота. Ул кешенең экстремаль шартларда да үз кыйбласына тугры калуында күренә. Андыйлар инде иблис вәсвәсәсенә бирешмәячәк.

Ә илаһи яшәешкә күчүне һәркемнең үзеннән һәм гаиләсеннән башлавы мәслихәт. Миссияле милләт буларак, татар кешесе өчен мондый куелыш аеруча зур әһәмияткә ия. Чөнки Аллаһтан аңа ошбу изге юлда әйдәп баручы көч һәм үрнәк булу бурычы йөкләнә. Илаһи яшәеш глобаль колач алсын өчен, әүвәл дәүләтләрнең дә илаһи яшәешкә күчүе, парламентларның исә илаһият кануннарына җавап бирә торган законнар кабул итүе лязем. Моның өчен инде ул дәүләтләрнең конституцияләре дә илаһият кануннарына туры килүе, ә аларны тикшерү БМО каршындагы махсус комиссиягә (Венеция комиссиясе үрнәгендә) йөкләнүе зарур. Фарыз гамәл буларак, илаһи борылыш та уңышка ирешер, чөнки Аллаһ юлындагылар артында Аның ихтыяры вә кодрәте тора.

Фоат УРАЗАЙ.

«Кара пулат» – Болгарда

Болгар музей-тыюлыгы территориясендә ачык һавада «Кара пулат» («Черная палата») операсы күрсәтелде. Тамаша XIV гасыр Алтын Урда сәнгатенең уникаль ядкәре – Кара пулат фонында узды.

Премьераны Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә карады. Сәламләү сүзендә ул бу җирдә Татарстан халкының нинди нәтиҗәләргә ирешүен искәртте. «Миңа калса, без үзебез дә бу еллар эчендә монда ни эшләгәнебезне аңлап бетермибез. Кыска вакыт эчендә без Болгарны мәңгеләштердек. Быел да ислам кабул ителүнең 1100 еллыгын билгеләп үтәбез – эпохаль вакыйга. Тыныч, бернинди каршылыкларсыз», – дип ассызыклады Минтимер Шәймиев.

Опера Ильяс Камал җитәкчелегендәге Тинчурин театры оркестры уены белән тәкъдим ителде. Кара пулат диварына заманча яктылык эффектлары, 3D-mapping кулланылды, анимация ярдәмендә, әйтерсең бина «җанланып китте». Аның стеналарында көрәш күренешләре, спектакльнең төп геройларының күңел һәм эмоциональ халәте чагылдырылды.

Операда төп рольләрне Татарстанның атказанган артистлары Илүсә Хуҗина һәм Артур Исламов, яшь җырчылар Илгиз Мөхетдинов, Денис Ханбаба башкарды. Спектакльдә шулай ук Д.Венедиктова, Э.Сафина, Д.Мөхетдинова, Э.Калислямова, Ә.Вәлиева, П.Зиннәтова, Д.Шәрәфетдинов, Р.Хәбибуллин һәм башкалар катнашты. Операда Тинчурин театрыннан Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты Зөфәр Харисов, Илнур Байназаров һәм Зөлфәт Закиров уйнады.

«Кара пулат» операсын Тинчурин театры сәхнәсендә режиссер, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты Георгий Ковтун куйган иде. Операның open-air версиясенең режиссеры – Илгиз Зәйниев.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов хәбәр иткәнчә, проект Мәдәният министрлыгы һәм «Яңарыш» фонды ярдәме белән гамәлгә ашырылган. «Проект бик катлаулы. Операны саф һавада һәм тарихи мохиткә якын, шулай ук театрлар һәм концерт заллары өчен гадәти булмаган шартларда кую шактый катлаулы», – дип билгеләп үтте ул.

Аяныч сан

Татарстанның җиде районында 9 нчы сыйныфны тәмамлап, татар теленнән төп дәүләт имтиханын тапшырган бер генә бала да юк.

Бу хакта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Президент каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов милли мәгарифне үстерүгә багышланган республикакүләм форумында әйтте.

«Югыйсә, 1 нче сыйныфтан алып 9 нчы сыйныфка кадәр атнасына кимендә икешәр сәгать татар теле укытылган бит аларга», – дип гаҗәпләнде Марат Әхмәтов.

«Республикадагы балаларның дүрттән бере генә туган телендә белем ала. Чынбарлыкта әле ул саннар тагы да эч пошырырлык булырга мөмкин. Сезнең, укытучыларның, мәгариф идарәләре җитәкчеләренең, мәктәп җитәкчеләренең, уку-укыту буенча урынбасарларының ни дәрәҗәдә татар җанлы булуы мәктәптә татар телен укытуның эчтәлегенә искиткеч зур йогынты ясый», – диде Марат Әхмәтов.

Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова докладына әзерләнгән слайдта да татар теленнән төп дәүләт имтиханы тапшыручылар булмаган районнар күрсәтелде. Бу Апас, Буа, Югары Ослан, Алабуга, Кама Тамагы, Менделеев, Тәтеш районнары.

Минзәлә, Чистай, Ютазы, Норлат районнарында да татар теленнән имтихан тапшыручылар саны аз. Алдынгылар исәбендә – Кукмара, Балтач, Чүпрәле, Әлки районнары.

М. Закирова татар теле һәм укытучыларын балаларда татар теле һәм әдәбиятыннан имтихан тапшыруга кызыксынуны арттыру өчен тырышырга өндәде.

Татар хикәяләре төрек телендә

Шушы көннәрдә Төркиядән шатлыклы хәбәр килеп иреште. Төрек телендә татар язучылары әсәрләре тупланган «Хәзерге заман татар хикәяләре антологиясе – XXI гасыр» дигән китап дөнья күргән.



Ул Анкара шәһәрендәге абруйлы «Һәҗә» нәшриятында саллы китап (376 бит) булып басылып чыккан. Җыентыкта хәзерге вакытта иҗат итүче утыз язучыларыбызның хикәяләре белән танышырга мөмкин.

Әсәрләрне төрек теленә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Фатих Кутлу тәрҗемә иткән. Антологиягә кереш сүз авторы – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла. Бу күркәм эш «Һәҗә» нәшриятының танылган тәрҗемәче Фатих Кутлуга тәкъдиме белән башланган. Ул исә әүвәл Татарстан Язучылар берлегендә татар әдипләре белән киңәшләшкән. Аңлашыла ки, китапның күләме чикләнгәнлектән, әсәрләрне, аларның авторларын нык сайларга туры килгән. «Әсәрләрне бик яратып тәрҗемә иттем. Аларның һәрберсе үзе бер ләззәт, һәр хикәянең үз тәме бар», – диде ул.

Төркиядән ирешкән хәбәрләргә караганда, «Антология» белән кайбер төрек әдәбият сөючеләре инде танышып та өлгергән. Әйтик, Төркиянең танылган язучысы, тәрҗемәче, галим Өмәр Кучүкмәһмәтоглу басмага кергән хикәяләрнең һәркайсы үзе бер дөнья булуын, аларның бик әйбәт тәрҗемә ителүен, бик җиңел, бер тын белән укылуын әйткән.

Китап шушы көннәрдә Төркиядә сатуга чыгачак. Моннан тыш тиздән әлеге «Хәзерге заман татар хикәяләре антологиясе – XXI гасыр» китабы Татарстан Язучылар берлеге хозурындагы Әдәби тәрҗемә үзәге проекты буларак, Мәскәүдә рус телендә дә дөнья күрер, дип уйланыла.

Сөембикә КАШАПОВА.

1 нче биттә – Казанда Бөтенроссия физкультурачылар көне уңаеннан уздырылган бәйрәм күренеше. Фото: minsport.tatarstan.ru

Тарихи биналарга яңа тормыш

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казан буйлап чираттагы сәфәрендә Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карамагындагы төгәлләнмәгән төзелешләрне, мәдәни мирас объектларын һәм башка биналарны карап, эш барышын тикшерде.

Татарстан җир һәм милек мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әһлиуллин объектлар турында аңлатма биреп барды. Эшлекле сәяхәттә Татарстан Президенты ярдәмчесе Олеся Балтусова да катнашты.

Президент маршрутындагы биналарның берсе – 25 нче Октябрь урамы, 5 нче йорт адресы белән урнашкан мәдәни мирас объекты. XIX гасыр азагы, XX гасыр башында төзелгән административ бина дәүләт тарафыннан саклана. Хәзер резервланган хәлдә. О.Балтусова хәбәр иткәнчә, хәзер бинаны алга таба эксплуатацияләү һәм оешмаларга, предприятиеләргә куллану өчен тапшыру мәсьәләсе карала.

Р.Миңнеханов башкала үзәгендәге Зур Кызыл урамда урнашкан әһәмиятле шәһәр төзелеше объектлары белән танышты. Әлеге урамның 11 нче йортындагы «Республика клиник тире-венерология диспансеры» бинасы тәмам тузган, ярым җимерек хәлдә һәм хәзер файдаланылмый. Бинаны тулысынча реконструкцияләү һәм яңадан торгызу (Республика клиник тире-венерология диспансеры башка бинага күчәчәк) күздә тотыла.

Зур Кызыл урам, 68/25 адресы белән урнашкан икенче объект «Казан хореография училищесы» карамагында. Хәзерге вакытта бу мәгариф учреждениесе мәйданнарын зурайтып, бинаны реконструкцияләү мөмкинлеге карала. О.Балтусова бинаның тарихи һәм архитектура ягыннан кыйммәткә ия булуын һәм Зур Кызыл урамда урнашкан фасадларны саклап калу күздә тотылуын ассызыклады.

Р. Миңнеханов төзелеп бетмәгән ике объектны карады: профессор Мөхәммәдьяров урамындагы бер бина «Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы» һөнәри белем учреждениесенә беркетелгән, икенче бина – Ясеневая урамы, 60 йорттагы (Константиновка бистәсе) административ-көнкүреш корпусы. Ике бинаны да, төзекләндергәннән соң, Казан шәһәре ихтыяҗлары өчен тапшыру турында карар кабул ителде – аларда социаль-мәдәни оешмалар, спорт һәм балалар үзәкләре урнаштырылачак.

Димитров ур., 6 адресы буенча урнашкан «Халыкара сервис көллияте» бинасы да авария хәлендә. Әлеге объект буенча түбәндәге карар кабул ителде – бина сүтеләчәк, ә җир участогы фондның торак төзелеш программалары кысаларында файдалану өчен Дәүләт торак фондына тапшырылачак.

Мунчәли укулары

Иртәгә Чүпрәле мөхтәсибәтенең Мунчәли авылында унбишенче тапкыр «Мунчәли укулары» дини фәнни-гамәли конференциясе узачак. Быелгы «Мунчәли укулары» «Авыллардагы рухи-мәдәни мирасны һәм гореф-гадәтләрне саклауда һәм үстерүдә дини кыйммәтләрнең әһәмияте» темасына багышлана.

Укуларга күренекле татар җәмәгать эшлеклесе, язучы, мәрхүм Туфан ага Миңнуллин башлангыч биргән. Әлеге дини җыенга нигез салыну тарихы турында Чүпрәле районы башлыгы урынбасары Илмир Измайлов болай дип сөйләде: «Туфан Миңнуллин, беренче тапкыр 1998 елда Мунчәли авылында җирле халык белән очрашып, аны якын итеп, яратып китте. Халык та Туфан аганы үз итте. Шуннан соң ул әлеге авылга еш кайта башлады. 2008 елда беренче тапкыр Авыл бәйрәме дини җыенын - Мунчәли укуларын оештыру да Туфан аганың фикере булды». Чүпрәле районы брендына әйләнгән әлеге бәйрәм, шушы җирлектә сакланып, Туфан Миңнуллинның якты истәлеге булып, ел саен үткәрелеп килә. Чарада һәр елны Туфан абыйны искә алалар. Ул төзергә ярдәм иткән мәктәп бинасы диварында барельеф белән эшләнгән мемориаль тактага чәчәкләр салып, дога кылалар.

Мунчәли укуларының масштабы да киңәя. Хәзер ул төбәкара дәрәҗәдә уза һәм быелгы чарада Чуашия, Мордовия, Марий Эл республикаларыннан, Ульяновск, Самара, Түбән Новгород өлкәләреннән дә күренекле дин әһелләре, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре катнашыр дип көтелә.

«Мунчәли укулары» кысаларында мөселман балалары арасында районкүләм шәкертләр бәйрәме - «Гыйлемпиада» да оештырылачак. Программада – Коръән уку, азан әйтү, вәгазь сөйләү буенча бәйгеләр, викториналар, төрле уеннар.

Эльмира СИРАҖИ.

Якташларны җыйды Наҗытамак

Башкортстанның Дүртөйле районы Наҗытамак авылында Россиянең атказанган укытучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны Әхкәметдин Зиннәт улы Зиннәтовның тууына 100 ел тулуга багышланган «Саумысыз, авылдашлар!» бәйрәме үтте.

Авыл халкы илнең төрле төбәкләрендә хезмәт салган якташлары, мактаулы авылдашлары белән очрашты, кунаклар кабул итте. Кичәне Әхкәметдин Зиннәт улының оныклары – Казанда яшәп иҗат итүче, эстрада артисты һәм композитор, «Яңа татар җыры», Ваһапов фестивале лауреаты – Мурат Гайсин, Башкортстан Республикасының атказанган артисткасы Гөлшат Гайсина, Наҗытамак авылы кызы – шагыйрә Фәния Габидуллина, Башкортстанның атказанган артисты Радик Динәхмәтов, Дүртөйле районы һәвәскәрләре чыгышлары бизәде.

Наҗытамаклыларны бәйрәм белән котларга Дүртөйле районы хакимияте башлыгы Риф Йосыпов, Россия Федерациясе Үзәк банкының Урал баш идарәсе начальнигы Рөстәм Мәрданов та килгән иде. Наҗытамаклылар кунакларны ихата-йорт алларында табын корып каршылады. Бик матур төзекләндерелгән кое суыннан чәй белән сыйладылар. Аннары, бергәләшеп зиратка үтеп, әрвахлар рухына дога кылдылар. «Ак калфак» хатын-кызлар иҗтимагый оешмасының Дүртөйле бүлекчәсе һәм «Әллүки» халык фольклор ансамбле чыгышын тамашачы җылы кабул итте.

Светлана ВАСИКОВА.

Казахстанда искиткеч мәчет

Казахстанның беренче президенты Нурсолтан Назарбаев башкалада республиканың төп мәчетен ачты.

«Мин 2019 елның мартында дәүләт башлыгы буларак вәкаләтләрем тукталуга бер көн кала, әлеге мәчеткә беренче кирпечне салдым. Ул вакытта минем белән илнең хәзерге президенты Касым-Жомарт Токаев булды. Мәчет дин, мәгариф һәм мәдәният үзәге булыр дип ышанабыз», – диде Назарбаев җомга көнне ачылу тантанасында.

Аның сүзләренчә, яңа мәчет шәһәргә аерым бер төс бирәчәк һәм туристларны җәлеп итү үзәге булачак. «30 ел мөстәкыйльлек дәверендә безнең аерым гражданнар иминлеккә иреште, һәм мин әлеге мәчет төзелешенә ярдәм итәргә кирәклеген әйттем. Төзелешкә дәүләт акчасы сарыф ителмәгән», – диде беренче президент.

Яңа мәчет башкаланың сул ярында, Кабанбай батыр һәм Мәңгилик Ел проспектлары арасында урнашкан. Мәчет 235 мең кешене сыйдырышлы, ягъни бер үк вакытта шулкадәр дин тотучы намаз укый ала: 35 мең кеше бинаның эчендә һәм 200 меңгә якын кеше – тышкы ягында. Шул рәвешле, Нур-Солтандагы әлеге мәчет дөньядагы иң зур мәчетләр унлыгына керә.

Мәчет һәм аның тирәсендәге территорияләр урнашкан җир кишәрлегенең гомуми мәйданы 10 га тәшкил итә, бина үзе 57 мең кв. метр мәйданны алып тора. Мәчетнең дүрт манарасы 130 метр биеклеккә күтәрелә, төп гөмбәз биеклеге 83,2 метр тәшкил итә. Аның ишеге дөньяда иң биек агач ишекләрнең берсе булып санала. Ишекләр тропик Африкада үсә торган каты ироко агачыннан кулдан ясалган. Аның биеклеге 12,40 метр, авырлыгы 1,5 тонна. Ишекләр шулай ук казах бизәкләре белән бизәлгән.

Моннан тыш, мәчетнең эчке пыяла ишекләре дә биек. Мәчет астында автобуслар өчен махсус туннель һәм 405 автомашинага исәпләнгән паркинг төзелгән.

Төп гөмбәзгә 20 тонналы авырлыктагы 27 метр диаметрлы люстра эленгән. Моннан тыш, дүрт якта 8 әр метрлы тагын дүрт люстра куелган. Мәчетнең кыйбла тарафы Аллаһ исемнәре белән бизәлгән, бу диварга төрле төстәге 25 миллион пыяла кисәге ябыштырылган.

Гыйбадәтханәнең намаз уку залы 15,5 мең кв. метр тәшкил иткән келәм белән капланган. Бу – дөньяда кулдан тукылган иң зур келәм булып тора.

● Татарстанда 2013 елдан бирле барлыгы 1134 спорт мәйданчыгы, шул исәптән 40 хоккей тартмасы һәм 43 блок-модульле база төзелгән. Быел тагын 11 объект файдалануга тапшырыла. Төзелеш белән беррәттән, спорт объектларын ремонтлау да актив бара. Республика программасы буенча спорт объектларының матди базасын ныгыту һәм аларны капиталь ремонтлауга ел саен 500 миллион сум акча бүленә. Хәзер инде 440 объектка капремонт таләп ителми, бу спорт мәйданчыкларының гомуми санының 88 процентына тәңгәл.

Хәния Фәрхи безнең йөрәкләрдә

Татарстан һәм Башкортстан халык артисты Хәния Фәрхинең арабыздан китүенә 5 ел булды, әмма ул халыкчан җырлары белән күңелләрдә һаман яши. Узган ел Башкортстанның Тәтешле районы Югары Тәтешле авылында аның истәлегенә музей ачылган иде. Ә быел, җырчының туган көнендә, музей янында һәйкәл куелды. Музей ачылгач та, инде һәйкәл куелгач та төрле сүзләр йөрде. Йөрәккә тия торганнарын аеруча җырчының бертуган сеңлесе Фирүзә Ибәтуллинага күп ишетергә туры килә. Югыйсә, боларның барысын да башлап җибәрүдә күпме тырышлык, вакыт, бар җанын биргән бит ул. Музей мөдире вазифаларын да үзе башкара. Без Фирүзә ханым белән әңгәмә кордык.

– Фирүзә ханым, Хәния Фәрхи музеена кеше күп киләме?

– Кояшымның (Фирүзә ханым апасына шулай дип яратып эндәшкән) музее узган елның 1 октябрендә ачылды. Бик күп халык килде һәм кешенең бүген дә өзелгәне юк. Җәйге айларда ерак җирләрдән Хәния апаның үзен күргән кебек булырбыз дип килгән кешеләр дә бар. «Хәнияне бик ярата идем», – дип ишекне ачып керү белән елый-елый керәләр. Хәтта ир-атлар да күз яшьләрен тыймый. Хәния апа арабыздан киткәч, тамашачы тагын да күбәйде. «Бөтен концертында булдым», – дип яратып киләләр.

– Монда Хәния апаның әйберләрен яхшылап карарга була, алар пыяла эчендә түгел. Музейлардан танылган кешеләрнең әйберләрен урлап чыгу кебек күренешләр ишетелгәләп тора.

– Музейда әйберләрне урнаштыру мәсьәләсенә килгәндә, һәр кергән кеше «залың нурлы, зәвыклы», дип китә. Хәния Фәрхинең үзен хәтерләтә, дип әйтүчеләр дә шактый. Алда эшләр бар әле. Барлык күлмәкләрен куеп бетермәдем. Манекенга дип сайлап алган күлмәкләрен халык бик ярата. Күбесенчә Хәния апаның үзе яратып кигән күлмәкләрен куйдым. Киләчәктә бар киемнәрен, әйберләрен башка музейлардагы кебек пыяла эченә урнаштырырга кирәклеген аңлыйм. Калган эшләрен дә җайлап кына башкарып киләбез. Аллага шөкер, кеше күзенә музей матур күренә. Кайбер урыннары эшләнеп бетмәгән дип үземә килеп әйткәннәре юк. Киресенчә, бик күп эшләр башкарылган, диләр. Киләчәктә музей янында Хәния апага багышлап сквер эшләргә уйлыйбыз. Кояшымның тагын бер тормышы булыр дим. Һәйкәл янында эскәмияләр куелды. Тротуар җәячәкбез. Кеше килеп, ял итеп, Кояшыма карап, сөйләшеп китәр, дигән өметтә калабыз.

– Музей янында ачылган Хәния Фәрхи һәйкәле турында нинди генә сүзләр йөрмәде. Бертуган сеңлесе буларак, сезгә негатив фикерләр ишетү авыр булгандыр.

– Һәйкәл ачылышына кайдан гына, нинди генә мәртәбәле кешеләр килмәде. Һәйкәлнең эшләнешен яратып, Хәниябезне яратып киттеләр. Таштан кеше образын эшләү – пластилин әвәләү түгел. Хәния апаның үзенә җан өреп булмаган кебек, ташны уеп, нәкъ үзе кебек эшләп булмый. Районыбыз җитәкчеләренә, ярдәм иткән егетләргә мең рәхмәтлебез. Фотодан күреп, төрле мәгънәсез сүзләр язганчы, килеп карап, кешенең хезмәтен күрә белергә кирәк. Аны үз эшенең осталары эшләде. Алла боерса, көзгә кадәр тротуары җәелер, тирә-ягы да матур булыр. Һәйкәлне беренче тапкыр карарга Тәтешле хакимияте хезмәткәре белән бергә бардык. Аның чәчләре, иягендәге нәни чокырына кадәр үзенә охшатып эшләнелгән. Кул куешы, нәфис бармаклары да нәкъ аныкы. Ул эшләнеп беткәнче үк, таш булса да, аннан җылылык бөркелә иде. Бер яктан горурлык булса да, икенче яктан әле генә күкрәгеңә кысып яраткан газиз кешең урынына таш сынны кочаклау йөрәк өзгеч бер халәт иде. Һәйкәл куярлык якты эзләр калдырган сөекле апамның рухлары шат булсын!

– Хәния апаның вафат булган көнендә үзе яшәгән йортка мемориал такта да куелды бит әле.

– Әйе, Казанда Кояшым яшәгән йортка мемориал такта куелды. Әмма мин бара алмадым. Уйласаң, уелырсың, башларны башларга бәрерсең дә... Аны кире кайтарып булмый. Бик авыр... Кояшымнан башка яшәүләр бик авыр. Көн кояшсыз, төн айсыз кебек. Әмма яшәргә кирәк. Хәния апа үзе «балам, балам» дип яшәде. Җизни Габделхәйгә, балаларга бик зур рәхмәт. Администраторы Раил Нуриевкә, «Бәйрәм» ансамбле егетләренә чиксез рәхмәтләремне җиткерәм. Чын мәгънәсендә, бу йортта Хәния Фәрхи яшәгән, дип сокланып, карап китәрләр. Ә мин ул көнне Кояшымның соңгы сулышы чыккан җирләрдә булдым. Коръән укыттык. Тәтешле район мәдәният сараенда иртәдән кичкә хәтле Хәния апаның җырлары яңгырады. Кояшымны искә алып, музейга килделәр, һәйкәленә чәчәк салдылар. Хәния апамның Тәтешледә рухы яши, җырлары яңгырап тора. Үзе төшләремә керә.

Аш үткәрер алдыннан гына төш күрдем. Кояшым шулай ихлас елмая! Чыннан да, бу дөнья белән теге дөньяның җепләре тоташкан дип уйлыйм. Кояшым безнең белән, гел янәшәбездә!

Эльза ГАЗИЗОВА.

Туган якта очрашулар...

Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова туган якларында очрашулар уздырып кайтты. Теләче район китапханәсендә аның китапларыннан «Милләтебез анасы» дип аталган күргәзмә оештырылган иде, бу якташ язучы белән ихлас очрашу булды. Аңа тирә-юньдәге авыллардан китапханәчеләр, төбәк тарихын өйрәнүчеләр, милли һәм дини оешма вәкилләре килде.

Җирле китапханәләр директоры Ризидә Дәүлиева язучының үзе һәм киңкырлы, бай иҗаты белән таныштырды. Ф.Бәйрәмова исә халык каршында язучы-тарихчы буларак та, милли сәясәтче буларак та чыгыш ясады, төбәк тарихына зур игътибар бирде. «Теләче-Саба төбәге үзенең иң борынгы тарихы, кабер ташлары, хәзәр-суар кабиләләре яшәгән Нырсуарлары, мең еллык Сатышлары, Өтернәс-Калатаулары, Сәхибгәрәй хан ярлыгы табылган Мамалайлары, көчләп чукындыруларга каршы күкрәк куеп көрәшкән Елыш һәм Кибәхуҗалары, дворяннык статусын кире кайтару өчен патша хакимияте белән судлашып йөргән Ямбулат һәм Шыңар морзалары, олы юлга исем биргән олы тарихлы Җөриләре, милләт тарихына кереп калган шәхесләре белән дә аерылып тора», - диде ул.

Алга таба Ф.Бәйрәмова «Күчем хан», «Кырык сырт», «Һиҗрәт», «Гөләйза» романнарының язылу тарихы турында сөйләде. «Татар язучысының зур әдәби дөньяга чыга алмавының бер сәбәбе – ул үзенең әсәрләре өчен материалны урыннарга барып өйрәнми, архивларның ишеге кайсы якка ачылганын белми. Мин бары тик Вахит Имамовның гына шулай эзләнеп язганын беләм, аның Пугачев явында катнашкан татар яугирләре турында хезмәтләре шундый. Милли үзаңны тәрбияләүдә, үстерүдә, тарихи хәтерне уятуда мондый әсәрләрнең роле искиткеч зур!»

Теләче турында да соңгы вакытта бербер артлы ике документаль китап дөнья күрде – быел Сәлмән Гыйльмиевнең «Теләче. Үткәне һәм бүгенгесе» китабы һәм автор-төзүчесе Ризидә Дәүлиева булган «Тарих битләрендә Теләчем» китаплары. Теләчедә күп еллардан бирле урыслар да яшәвен истә тотып, беренче китап ике телдә дөнья күргән һәм алар турында бай мәгълүмат бирелгән. Сәлмән Гыйльмиев Теләче авылының барлыкка килүен, археологик тикшеренүләргә нигезләп, «Алтын Урданың соңгы чоры, Казан ханлыгының беренче еллары» белән бәйләп яза, ә рәсми кабул ителгән датаны «1560 елда Теләче элеккеге Казан ханлыгының үзәк өлешендәге рус колониясе үзгәнә әверелә», дип бәяли. Китап бик бай эчтәлекле, анда төбәктәге башка татар һәм рус авыллары тарихы, Казан ханлыгы беткәннән соң барлыкка килгән авыллар исемлеге дә бирелгән, алар арасында рус һәм керәшен татарлары авыллары да шактый. Ә «Югалган авыллар» исемлегендә исә рус авыллары күбрәк, татар авыллары да бар. «Шушы исемлекләр буенча гына да төбәк тарихын күз алдына китерергә була, анда татар язмышы күзгәдәге кебек күренә... С.Гыйльмиев бу китапны язарга күп көч куйган, эзләнүләрен Казан архивларыннан башлап, хәтта ташландык авыл зиратларында да алып барган, бик күп кешеләр белән очрашкан. Һичшиксез, аның бу китабы Теләчегә зур бүләк, кыйммәтле бүләк!» - дип, Ф.Бәйрәмова китапка зур бәя бирде. Китапны рус теленә Сәлмән әфәнденең кызы Ания Гыймаева тәрҗемә иткән.

Р.Дәүлиева җитәкчелегендә чыккан икенче китап Теләче районы авыллары тарихына багышланган, урыслар турында – урысча, татарлар турында татарча мәгълүмат бирелгән. Шунысы кызыклы, һәр авыл тарихын шунда яшәүче һәм эшләүче китапханәчеләр үзләре язган. Ф.Бәйрәмова фикеренчә, әлбәттә, бу архивларда утырып язылган зур тарих түгел, әмма ул авыл тормышын һәм кешеләрен өйрәнеп, алар сөйләгәннәргә таянып язылган тарих, шунысы белән кыйммәтле. Монда, кыскача гына булса да, мәчет-мәдрәсәләр тарихы да, муллалар исемлеге дә, шәхесләр тормышы һәм язмышы да, колхоз-совхоз чорлары да чагылыш тапкан. Халык үзе язган, китап, дияргә була. Теләче төбәгенә багышланган өченче китап та әзерләнеп беткән, аның авторы – Олы Нырсы авылының ветеран-укытучысы, җирле тарихчы-язучы Нурания Гыйльметдинова, алдагы көннәрдә ул китапны да күрергә насыйп булыр!

«Нырсуар, Нырсы җире – шанлы изгеләр иле» һәм «Йөз ел элек...» китаплары авторы, әдәби бәйгеләр җиңүчесе Н.Гыйльметдинова үзе дә очрашуда катнашты. Нурания ханым татар әдәбиятын тирәнтен белә, ул тарихи әсәрләрнең кеше аңына ни дәрәҗәдә көчле тәэсир итүен, әмма аларның бик аз булуын әйтте...

Шул ук көнне Теләче Үзәк мәчетендә дә Ф.Бәйрәмова белән очрашу узды, анысында мәчеттә ислам лагерендә укучы кыз балалар катнашты. Балаларның яше 4-тән 15-кә кадәр булса да, уртак темалар тиз табылды, язучы апалары аларга үзенең балачагы, туган як табигате, балалар әдәбияты, Аллаһка һәм кешеләргә мәхәббәт, телебезнең һәм динебезнең кадере турында сөйләде, аларны сакларга чакырды.

Ф.Бәйрәмованың соңгы очрашуы үзенең туган авылы Сабайда булды, ул Саба районына карый. Сабайда 2012 елдан бирле «Авыл көне» уздырыла, анда хакимият катнашмый, бу бәйрәмне үзенә-үзе халык оештыра. Быел да шулай булган, ике ел пандемия сәбәпле уздырылмый торса да, халык «Авыл көне»н яңадан торгызырга уйлаган. Елдагыча, хәйриячеләр дә табылган, оештыручылар да нык тырышкан. Бу бәйрәмне уздыруда тумышлары белән Сабайдан булган, хәзер Чаллы шәһәрендә яшәүче Дәүлиевлар нәселе күп көч куя, алар ел да авылга җыелып кайтып, халыкка бәйрәм ясый. Бәйрәмгә тирә-күрше авыллардан да төялеп килгәннәр, Казан-Чаллы кебек шәһәрләрдән дә күп кунаклар кайткан иде. «Авыл көне»н Фәрхулла хәзрәт Коръән белән башлап җибәрде, дога кылып, бәйрәмгә үзенең фатихасын бирде. Клуб мөдире Дания Хәкимова, Чаллы кунагы Зөбәрҗәт Кашапова-Дәүлиева, күршедәге Миңгәр тумасы, Казан кунагы Нияз Рахман авыл бәйрәмен чын тамашага әйләндерен алып барды. Авыл үзешчәннәре дә чыгыш ясады, төрле уеннар да оештырылды, бүләкләр дә бирелде.

Үзенең авылдашлары каршында чыгыш ясап, Ф.Бәйрәмова аларга зур рәхмәтләрен әйтте. «Минем барлыгым да, холкым да, әсәрләремнең теле дә Сабайдан, сездән, - диде ул. – Мин авылдан 15 яшемдә, ун сум акча белән чыгып киттем, менә хәзер 72 яшемдә кабат сезнең каршыгызда басып торам. Мин Сабайга кайтып, алтын сарайлар сала алмадым, әмма шушы гомер эчендә 53 китап язып бастырдым, туган авылыма куйган һәйкәлем, милләтемә алтын мирасым шул булыр. Авылыбыз бик борынгы, тарихи, ул Казан ханлыгы чорларында ук барлыкка килгән. Сабай зиратында күп затлы шәхесләр ята, композитор Рөстәм Яхинның да әби-бабалары шушында җирләнгән. Безнең авылда бу нәсел Гыйльмановлар фамилиясен алган, минем әнием дә шул фамилияне йөртә иде».

Сабай авылы элек тә зур булмаган, ишле гаиләләр хисабына гына кеше күп күренгән. Хәзер ул хәл юк, балалар саны аз, шул сәбәпле, авылда хәтта башлангыч мәктәп тә юк. Авыл уртасына Бөек Ватан сугышында катнашучыларга стела куелган, анда 121 кеше исеме язылган. Мәрмәр һәйкәлгә Фәүзия ханымның атасы – Бәйрәмов Әүхади Бәйрәмгали улының да исеме уеп язылган, анда атасы һәм анасы ягыннан башка ир туганнары да теркәлгән... Заманында Рөстәм Яхин һәм Ф.Бәйрәмованың мулла бабайлары тезләнеп намаз укыган иске мәчет бинасын да сүткәннәр, элек анда башлангыч мәктәп булган, Фәүзия ханым үзе дә шунда укыган. Авылда яңа мәчет бар, әмма анда йөрүчеләр аз. Шушы хәлләргә карамастан, Сабай яшәргә тырыша, халык үз көнен үзе күрә, зарланып, теләнеп йөрми.

«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге.

Уян әле, шигырь, талпын, юргам, Сызгырып бер очыйк юллардан!..

(Шагыйрь һәм әдәбият галиме Зәет Мәҗитовның тууына 95 ел)

УРМАНДА

Яфраклар шаулаша җилләрдә.
Яфраклар, әйтерсең сөйләшә.
Әйтерсең мең төрле телләрдә
Яфраклар сүз куша, эндәшә:

– Кайлардан килдең син, әй, юлчы,
Кем син һәм кайларга үтәсең?!
Белепме барасың, белмиме –
Сукмагың кайларга илтәсен?!

Яфраклар шаулаша җилләрдә
Йөз төрле, мең төрле телләрдә.
Мин торам юлымнан тукталып,
Шул серле аһәңне тыңланып.

– Белепме барасың, белмиме
Тормышның мәңгелек канунын:
Чиге бар һәртөрле сукмакның,
Соңы бар һәртөрле баруның?!

Мәһабәт агачлар башында
Яфраклар шаулаша җилләрдә.

Мин торам имәннәр каршында,
Йотылып шул серле өннәргә.

– Чиге бар, әйе, һәр сукмакның,
Күзе бар җирдәге һәр гөлнең.
Тик бармы ахыры зур юлның?!
Тик бармы картлыгы күңелнең?!

Яфраклар шаулаша җилләрдә
Йөз төрле, мең төрле телләрдә.

– Шаулама син, урман, шаулама,
Моңайтма яфраклар койганда.
Сукмагым зур юлга кушыла,
Югалмас минем дә эз анда.

ЙӨРӘК

Армый көннәр, армый төннәр,
Ул һаман тора тибеп,
Таш астыннан ургып чыккан
Тынмас бер чишмә кебек.

Алсу таң алы белән ул,
Айлы кич яме белән,
Кешеләр рәхәт йөрсен дип,
Хисләрдән чигә келәм.

Бал корты кебек тырыш ул,
Мәсләге – илгә хезмәт.
Шуңа шул аның түрендә –
Бетмәс җыр, бетмәс ширбәт.

Ә түрдә, иң саф урында,
Кабер юлына хәтле,
Йөртәчәк ул гел тирбәтеп
Икенче бер йөрәкне.

* * *

Белмим, белмим, нинди ашкыну бу, –
Бу йөрәгем кая омтыла?..
Бер минутка тынып кала алмыйм,
Күзләремә килеп моң тула, –
Бу йөрәгем кая омтыла?..

Зәет МӘҖИТОВ

Белмим, белмим, нинди юксыну бу, –
Бу йөрәгем кемен югалткан?
Биек таулар, ерак юллар аша
Кемне эзли үрелеп ерактан –
Бу йөрәгем кемен югалткан?

Белмим, белмим, нинди шәфкатьле җил
Хисләремне аңа житкерер?
Ялкын салып, аның йөрәген дә
Минекедәй ярсып типтерер? –
Нинди җилләр, белмим, җиткерер?!

ИЮНЬ КИЧЕНДӘ

Әнвәр Әфләтунов истәлегенә

Урман буе.
Аяз.
Июнь киче.
Күк фонаре – Айның нурында
Коенган җир...
Әйтерсең лә Айдан
Көмеш яуган бөтен урынга.

Карт имәннәр тирән уйга чумган.
Ак каеннар тора килешле;
Озын толымнарын салындырып
Су коенып чыккан кыз төсле.
Төз наратлар баскан тезелешеп,
Гүя ыспай сакчы егетләр.
Юл читендә тора ромашкалар
Сөрмә тарткан озын керфектән.

Аттан төшеп, көмеш үләннәргә
Сузылып яттым тәмам күмелеп.
Йолдызларга карыйм.
Ә күңелдә
Хисләр кайный тулып, түгелеп.

Ниләр уйлыйм?
Атап әйтү кыен.
Барлык хисләр бергә уянган:
Яшәү яме...
Дөнья мәңгелеге...
Кайгы-шатлык... Гашыйк булганнар...

Яланаяк үткән малай чаклар...
Уйланулар...
Елау, көлүләр...

Бу тормышның дусы, дошманнары...
Иң беренче татлы үбүләр...

Барсы-барсы бергә хәтерләнә
Бу сихерле июнь кичендә.
Син ятмыйсың гүя күккә карап,
Күңелең – серле әкият эчендә.

Әй никадәр бай соң җир әкияте,
Бәхетле соң адәм баласы!
Никадәрле яме бар дөньяның
Күңелләргә җыеп аласы...

...Июнь киче.
Күккә карап ятам,
Көмеш үләннәргә күмелеп.
Бөтен уйлар гүя бергә ага,
Күкрәгемнән минем түгелеп.

– Син китәрсең, дөрес, бу дөньядан.
Синең гомер, кеше, кечкенә.
Ләкин эзең июнь киче төсле
Язылып калыр җирнең өстенә.

Кыскалыгы өчен гомернең син,
Юк, үкенмә, кеше, үкенмә.
Син яшәүнең еллык ямен-тәмен
Татыдың бер июнь кичендә.

Философтай уйчан бу имәннәр,
Зур толымлы кыздай каеннар,
Ыспай егет төсле бу наратлар
Кала икән, әйдә калсыннар,
Килер буыннарга без кичергән
Яшәү рухын алып барсыннар!

* * *

Үткән иде инде август яшеннәре,
Сүнгән иде аҗаганнар да офыкта.
Күнгән идек инде салкын янгыр сибеп
Күкне каплап көн дә йөзгән күк болытка.

Кинәт кенә әллә кайдан исте бер җил
Һәм, җәйгечә куе болыт күтәрелеп,
Йөрде күктә сискәндереп бар халыкны,
Утлы чыбыркысы белән җирне телеп.

Ләкин беркем ямь тапмады бу күкрәүдән,
Уянмады чәчәкләр дә йокысыннан...
...Кайда йөрде юл тапмыйча мәхәббәтең,
Ник кичектең соңга калган күкрәү сыман?!

* * *

Су буеннан табып кайттым
Кыр казының канатын.
Кыр казлары кайткан чакта
Сагышымны тараттың.
Әй, канатым, канатым,
Чынлап, ахры, яраттым.

Сәлам хатлар язасым юк
Кыр казы канатыма.
Өегез күршемдә генә –
Тәрәзәң карап тора.
Әй, канатым, канатым,
Якыннан гына таптым.

Су буеннан табып кайттым,
Югалтмам шул канатны.
Юк сине алыштырасым
Соңгы сулышка чаклы.
Әй, канатым, канатым,
Гомерлеккә яраттым!

КӨЗГЕ АЯЗ КИЧЛӘРДӘ

Көзге аяз кичләрдә,
Кырда беткәч эшләр дә,
Ай чыга тулып кына,
Яп-якты булып кына.
Тулган ай кебек кенә
Син дә чык көлеп кенә.

Тулган айлы төннәрдә
Нурлар уйный күлләрдә,
йөрәрбез икәү генә,
Серләшеп иркә генә.
Тулган ай кебек кенә
Чык, иркәм, көлеп кенә.

Көзге аяз төннәрдә
Без серләшеп йөргәндә,
Ай йөрер юлдаш булып,
Күңелдә булмас болыт.
Тулган ай кебек кенә
Чык, иркәм, көлеп кенә.

Көзге таңнар атканда,
Тулган айлар батканда,
Вәгъдәләр бирешербез,
Кич тагын күрешербез.
Чык, иркәм, көлеп кенә
Тулган ай кебек кенә.

АК ИДИЛЛИЯ

Агыйделдә ак көймә,
Ак көймәдә ак җилкән.
Ак җилкәнле ак көймәдә –
Ап-ак күлмәкле иркәм.

Ап-ак күлмәкле иркәмнең
Иңнәре иңнәремдә.
Ак көймәбез иркәләнә
Агыйдел җилләрендә.

Агыйделнең ак дулкыны
Акрын гына тирбәлә.
Аксыл чәчләрен иркәмнең
Битләремә җил бәрә.

Агыйделдә – ак җилкәнем.
Ак шомыртлар – ярында.
Ак көймәдә – аклы күлмәк:
Ак чәчәгем – янымда.

* * *

Әгәр булсам эшчән бал корты мин,
Үбеп йөрер идем мең гөлне.
Кешеләргә ширбәт җыйган җирдә
Ятып калыр идем бер көнне.

Әгәр булсам шифалы бер чишмә,
Һәр тамчысы булса сулышым,
Кибеп бетәр идем, тамчыларның
Кешеләргә биреп соңгысын.

Чүпрәлегә

● Үби авылы мәктәбендәге тукучылык остаханәсе.

● Чуаш фольклор ансамбле «Хельгем».

Эше барның ашы бар

Чүпрәле – республиканың иң көньяк-көнбатышында, Чуашия һәм Ульян өлкәләре белән чиктәш район. Белемәләре буенча 43 район арасында 39 нчы урында тора, халкы 21 меңнән артык. Шуның 5 меңгә якыны район үзәге Иске Чүпрәледә яши. Милли яктан караганда, Чүпрәледә төп ике халык: 41 процент халкы – чуашлар, 48 процент – татарлар, калган милләтләр унбер процентка сыеп бетә. Чем-кара уңдырышлы җирләре белән Чүпрәле электән саф авыл хуҗалыгы районы саналган. Ләкин хәзер аз халыклы, казылма байлыкларга да ярлы, җитмәсә башкаладан ерак урнашкан бу районда сәнәгать өлкәсен үстерү, кешеләрне эшле итү юлында да шактый гамәл башкарыла. Чүпрәленең сәнәгать паркы белән танышып йөргәндә, шундый фикергә килдек. Менә «Формпласт» ширкәтенең чит ил җиһазлары куелган цехлары. Монда каһвә, куертылган сөт ише ризыкларның калай банкаларына пластмасса капкачлар ясала. Өч станок тәүлегенә 60 мең капкач ясый һәм аларны Мәскәү, Краснодар, Омск һ.б. калаларга, Казахстанга төяп китеп тә баралар. Җитештерү бер минутка да туктап тормый, ясалган товар да складта ятмый…

Күршедәге бинада «Технотрейд» ширкәте урнашкан. Бирегә бөтен республикадан полиэтилен калдыкларын ташыйлар. Шул чүпне яңадан эшкәртеп, заводларга алып китәләр. Бусы – табышлы эш кенә түгел, әйләнә-тирә мохитне саклау да. Табигатькә зыянлы калдыклардан арынырга ярдәм һәм район халкына эш урыннары, бюджетка салымнар да дигән сүз бу.

Сәнәгать паркының тагын бер бинасында ял һәм спорт мәйданчыклары өчен дистәләгән төр җиһазлар ясыйлар. «Солнечный круг» ширкәте җитештергән продукция Татарстанга гына түгел, күрше-тирә өлкәләргә дә тарала. Күршедә – сөт эшкәртүче «Исток» кооперативы урнашкан. Өр-яңа җиһазлар белән эшләүче комбинат быелның май аенда гына ачылган һәм тәүлегенә 20 тонна сөт эшкәртә. Монда атланмай һәм башка ризыклар эшләп чыгарыла.

Район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Эльмир Измайлов безне сәнәгать паркы һәм инвесторлар белән таныштыра. Мәскәү, Казан, Ульян, Чуашстан инвесторлары… Димәк, районда эшмәкәрләргә эшләр өчен шартлар тудырыла дигән сүз бу.

● Шамил Мубинов.

Җиләк басулары

Сезнең офыкка кадәр сузылган җиләк басулары күргәнегез бармы? Бер тарафта – чиксез җиләк кыры, икенче якка борылсаң, караш җитмәслек алмагач бакчалары җәйрәп ята. Чүпрәленең алтын башаклар гына тибрәлгән, чөгендер җәйрәгән кырларында бүген җиләк-җимеш үстерүчеләр дә табылган. Альфред Хәйруллин Иске Дуван авылына шәһәрдәге төзелеш бизнесын ташлап кайткан һәм «Дуван бакчалары» кооперативын оештырган. Башта алты гектар җиргә бакча җиләге утыртып караганнар. Бүген исә аның җирләре 505 гектарга җиткән, анда хәзер бакча җиләге дә, карлыган да, кура җиләге дә үстерәләр. Хуҗаның иң зур өмете һәм горурлыгы исә 280 гектарлы алма бакчасында. Быел ул беренче уңышын бирергә тулышып утыра. Уңышны саклар өчен инде бина да төзелеп ята. Шунда ук кайнатмалар ясау цехы да булачак. Җиләк-җимешне катыру цехы эшне җиңеләйтәчәк. Бу кадәр бакчаларны сугарырга да кирәк бит, шуңа күрә дә иске сазлыкка әйләнеп яткан буаны чистартып, тирәнәйтеп, зур буа да ясап куйганнар. Киң колач белән майтарылган бу эшләрен Алфред үзе «хобби, яраткан шөгыль» дип атый. Җир белән, бакчачылык белән шөгыльләнү теләге барлыкка килгәч, аңа республиканың бер билгеле бакчачысы Чүпрәлегә барырга киңәш итә, анда яшь, куәтле башлык, ул сиңа эшләргә ярдәм итәр, ди. Ул Альфредның шушы як кешесе икәнен дә белмичә, шундый киңәш бирә. Ә җирне сагынган ир-егет кайта да җиң сызганып эшкә тотына: башта булган кадәр үз акчасын сарыф итә, аннары хакимият ярдәме белән төрле программаларга керә, грантлар ала. Бүген җитештерелгән җиләкне минутында алып китеп баралар. Альфредның бу «яраткан шөгыле» үзенең татлы җимешләрен бирә. 1979 елның зәмһәрир салкын кышы Татарстанны алма бакчаларсыз калдырган иде, ә Альфред кебек җирне яраткан, хыялга да бай үҗәт егетләр туган җирдә икмәк кенә түгел, җиләк тә, алма да үстереп, шул эштән табыш та алып булганны исбатлый.

Рухи тараф ни хәлдә?

Чүпрәле төбәге татар дөньясына шактый асыл затлар биргән. Артистлардан Ренат Таҗетдинов, Һидаят Солтанов, Шәүкәт Биктимеров, Алсу Гайнуллина, җырчылардан Рафаэль Ильясов, Илсаф, язучылар-шагыйрьләрдән Нурмөхәммәт Хисамов, Рәмис Аймәт исемнәрен генә атау да җитәдер. Монда гомумән үз туфракларыннан чыккан шәхесләр белән нык горурланалар. «Туган якны өйрәнү» музее хезмәткәре Рәдиф әфәнде Субаев алар хакында сәгатьләр буе сөйли ала. Ахырда ул кулыбызга саллы бер китап тоттырды – Чүпрәледә туган каләм әһелләренең иҗатлары, биографияләре тупланган антология чыгарганнар икән. Монда 500 ләп якташлары хакында мәгълүмат тупланган. Ватанны яратуның үз туган төбәкләре белән горурланудан башланганын аңлыйлар монда, димәк.

Чүпрәле үзенең 15 елдан артык үткәрелеп килгән Мунчәли укулары белән дә татар дөньясына яхшы билгеле. Бу бай эчтәлекле рухи чарага чит төбәкләрдән дә киләләр. Ул фәнни-гамәли-дини белемнәр алу, фикерләшү, рухи азык бирү юнәлешендә бик кирәкле чара булып тора.

Чын байлык сакчылары

Фольклор коллективларын шулай атыйсы килә, чөнки нәкъ менә алар халык авыз иҗатын, гореф-гадәтләрен, уен-җырларын саклый, сәхнәдән безгә күрсәтә. Районда шундый 28 коллектив бар, аларның 12 се халык коллективы исемен йөртә. Сәфәр барышында шуларның берничәсе белән танышырга да насыйп булды. Аларның беренчесе һәм күңелләребезне яулаганы «Хельгем» чуаш ансамбле иде. Күз явын алырлык зәвыклы милли киемнәре, уен кораллары, дәртле җыр-биюләре белән алар нур чәчеп тора, теләсә кайсы сәхнәгә чыгарып бастырсаң да, үз халыкларының визит карточкасы булып торачак, билләһи. Чуаш артистлар татарча да сиптерә. Коллективның җитәкчесе – ут

баруларым...

● «Мишәр» фольклор ансамбле.

кебек ханым Людмила Сердцева, исеменә җисеме туры килеп тора. Ун ел элек оешкан бу коллектив районда гына түгел, республика күләмендәге барлык фестивальләрдә, чараларда катнашып килә. Милли сәхнә костюмнары турында сүз киткәч, үзешчәннәр затлы аяк киемнәрен тектерергә Олег атакайның акча бирүен әйтеп куйды. Әлегә кадәр бер генә хәзрәтнең дә фольклор ансамблен финанслаганын күргән юк иде, кызык бу...

Шланга авылына без «Гөлҗамал» фольклор ансамбле белән танышырга килдек. Исеме сәер булса да, бу – саф татар авылы. Кызу эш өстенә карамастан, кызлар мәдәният йортына килеп, чигүле алъяпкычлары, бәби итәкле күлмәкләре белән үз репертуарларын күрсәтте. Коллектив 1996 елдан бирле эшли. Унике кеше йөри, араларында авыл советы секретаре да, укытучылар, почта хезмәткәрләре, медик, китапханәчеләр бар. Ансамбль республикадагы күп ярышларда, фестивальләрдә даими катнаша. Шушы төбәккә хас йолаларны сәхнәләштереп күрсәтәләр. Печәнгә төшү, мунчала басу, майның унбише кебек үз якларының йола-бәйрәмнәрен сәхнәгә күтәргәннәр. Башкаларын ишеткән булсак та, Майның унбише бәйрәме яңалык иде. Бу бәйрәм борын-борыннан бары тик Шланга авылында гына уза, ул хәзер 28 майга туры килә, элек исә 15 майга туры килгән, исеме дә шуннан. Ул язгы чәчүдән соң үткәрелә, барлык авылдашлар кайта. Таңнан торып урманга баралар, иң нык, матур имәнне кочаклап, Ходайдан имән кебек саулык, ныклык сорыйлар. Аннары ятып җирдә ауныйлар. Бу көнне дару үләннәре җыялар, сабан туендагы кебек ярышлар да була. Менә шундый кызыклы халык бәйрәме.

«Мишәр» дип аталган балалар фольклор коллективы район үзәгендәге мәдәният йортында 2018 елдан бирле эшли. Монда балалар сәнгать мәктәбенең төрле сыйныфларында укучы 9-14 яшьлек утызлап бала йөри. Кая барсалар да, җиңеп кайталар. «Уен-фест»тан былтыр гран-при алып кайтканнар, быел «Созвездие»дә җиңгәннәр. Татарстан һәм Россия президентларының да грантларына ия булганнар. Репертуарлары шушы төбәккә хас йола җырларыннан, җырлы уеннардан, халык авыз иҗатыннан тора. Матур милли киемнәре, читекләре бар, уен коралларында уйныйлар, оста бииләр. Әлбәттә, бу балалар күңеленә җырлаган җырлары, бәетләре, уеннары гомерлек байлык булып сеңеп калачак.

Оста куллы «Ак калфак»лар

Чүпрәле үзәк китапханәсенә кергәч, матурлыктан башлар әйләнде. Аллы-гөлле чигүле мендәр тышлары, калфаклар, бизәүле хәситәләр, муенсалар, беләзекләр… – ни генә юк! Бу матурлыкны үз куллары белән «Ак калфак» оешмасына йөрүче кызлар, ханымнар тудырган. Алар арасында төрле һөнәр ияләре бар. Җыелышып төрле мастер-класслар үткәрәләр, үзләре белгәнне башкаларга өйрәтәләр. Бергәләп шулай мендәрләр чиккәннәр, изү ясаганнар, намазлыклар, алъяпкычлар чиккәннәр. Шифалы үләннәр җыеп, киптереп чәйләр ясыйлар. «Ак калфак»ның авылларда 200 ләп әгъзасы бар. Китапханәче Резеда ханым безгә күргәзмәне горурланып күрсәтеп йөрде. Осталыкларына исең китәрдәй сандыклар күргәзмәсе. Үз куллары белән нәрсәдән генә ясамаганнар аларны! Бер читтәрәк – күз явын алырлык дисбеләр. Хөрмә төшен 2 сәгать сөттә кайнатасы, аннары без белән тишәсе… Кече Чынлы, Яңа Кәкерле, Мунчәли, Шлангада халык кул эшләре белән бик яратып шөгыльләнә икән.

Гармуннар патшасы

Түбән Чәке авылында гармуннар патшасы яши, диделәр, барып күрергә булдык. Шамил абый гаражында нидер эшли иде, мондагы гармуннарына күрсәтеп: «Болары җиңгәгез өйгә кертмәгән гармуннар гына аның, әйдәгез, калганнарын күрсәтим», – дип өйгә чакыргач, аңа иярдек. Шамил Мубинов шушы авылның гап-гади кешесе, шофер, гараж мөдире, озак еллар баш инженер булып эшләгән. Колхозлар тарала башлагач, районда газ буенча инженер булып урнаша. Йорттан йортка газ җиһазларын тикшереп йөргәндә, күзенә гел чормада йә шкаф башында тузан җыеп яткан гармуннар чалына башлый. Хәзер алар беркемгә кирәкми… Алып кайта да ремонтлый Шамил. Шулай итеп, гармуннарның саны 32 гә җитә. «Гармуннарны бер генә температурада сакларга кирәк, суыкта уйнарга ярамый», – ди оста. Температура үзгәреп торса, гармун тутыга, аның тембры үзгәрә икән. Шамил абый үзенең гармуннарында өздереп уйный да, үзе дә көйләр язгалый. Ватык гармуннарын алып килүчеләргә шунда ук төзәтеп тә бирәм, ди. Хакын да алмый, уйнасыннар гына, ди. Кайчагында гармуннарын күтәреп, мәктәпкә дә бара икән. Гармуннарны кешегә бирергә, бүләк итәргә яратмый: алар бит минем дуслар, җәллим, ди. Берсеннән-берсе матур тавышлы гармуннарында уйнап, безгә нәни генә концерт та куйды әле. Сөбханалла, аңа беркем дә 73 яшь бирмәс. Гармун уйнауның сихәте бар, ахры.

Курыкмагыз: без Убей авылында…

Чүпрәледәге сәер авыл исемнәренә колак ияләнә башласа да, монысы аеруча зәһәр тоелды – Үби (Убей). Чуаш авылы. Авыл мәктәбендә чуаш милли һөнәрчелеге – тукучылык музее

● Чүпрәленең иң өлкән кешесе Федора Никифоровнага 103 яшь.

● «Гөлҗамал» фольклор ансамбле.

оештырганнар. Борынгыдан калган тукылган сөлге, милли киемнәрне җыйганнар һәм бу һөнәрне тергезергә уйлаганнар. Бүген Үби авылы мәктәбендә тукучылык түгәрәге эшли, анда балалар милли бизәкләр белән тукырга өйрәнә. Грант акчасына яңа туку станоклары кайтартканнар. Укытучылары җитәкчелегендә балалар үз куллары белән сөлгеләр суга хәзер...

Үби авылында районның иң өлкән кешесе Федора Никифоровна яши икән, аның белән күрешеп чыктык. Әбигә 103 яшь, теттереп чуашча сөйләшә. Хәтере таң калырлык. Гомере буе колхозда эшләгән. Әле узган елга кадәр кайнар мунчага мөкиббән булган, быел керә алмый инде, олыгайдым, ди. Шулай да үз киемнәрен үзе юу җаен карый икән. Федора Никифоровнаның иң олы кызына да 83 яшь. Бүген әби оныклары белән яши, зарланмый, көр күңелле. “Озак яшәүнең сере нидә?” – дип сорагач, «Нинди сере булсын аның, эшләдем дә эшләдем», – дип җавап бирде. Без исә аңа саулык теләп хушлаштык.

Эльмира СИРАҖИ.

Автор фотолары.

Атнаның сәяси мизгелләре

Уңышсыз тактика

БМО Куркынычсызлык Шурасы 12 августта Россия тәкъдиме белән ашыгыч төстә җыелган утырышында Запорожье АЭСы тирәсендә соңгы көннәрдә бик кискен төс алган хәлләрне тикшергән. Россиянең БМО каршындагы даими вәкиле В.Небензя андагы хәлне: «Преступные атаки Киева на объекты ядерной инфраструктуры толкают мир на грань ядерной катастрофы, сопоставимой по масштабам с чернобыльской», - дип аңлаткан. Әмма АКШ һәм Көнбатышның башка илләре дипломатлары АЭС тирәсендә туган кискен хәл өчен бөтен җаваплылыкны Россиянең үзенә йөкләгән. Атом энергиясе буенча халыкара агентлык (МАГАТЭ) башлыгы Р.Гросси исә үз чыгышында, бу мизгелдә Запорожье АЭСында атом-төш иминлегенә турыдан-туры янау булмавы, ә инспекторларның сәфәре сәяси һ.б. сәбәпләр белән булмый калуы турында белдергән. Украинаның БМО каршындагы даими вәкиле С.Кислица исә АЭСны утка тотуда Россия хәрбиләрен гаепләгән, моның Украинаны дискредитацияләү өчен эшләнүен дә әйткән.

Игътибарны ЕС һәм дөньяның 42 иле исеменнән ясалган белдерү дә җәлеп итә. Запорожье АЭСындагы хәлне җайга салу өчен, алар Россиядән аны Украина контроленә кире кайтаруын таләп итә. БМО секретариаты исә, МАГАТЭ белән берлектә, Украинаның Запорожье АЭСына МАГАТЭ миссиясе сәфәрен логистика һәм куркынычсызлык ягыннан да тәэмин итү мөмкинлеген исәпкә алып, Россия һәм Украина ризалыгы белән ул сәфәрне Киев аша оештырырга карар кылган.

Сәяси аналитиклар Запорожье АЭСы тирәсендәге ыгы-зыгыны бөтенләй башкача аңлата. Алар фикеренчә, Украинада килеп чыккан кыенлыклар Мәскәүне тизрәк Киев белән сөйләшүләрне башлап җибәрергә мәҗбүр итә. Шуңа ул, дөнья җәмәгатьчелеген яңа атом-төш фаҗигасе белән өркетеп, Көнбатышның бу мәсьәләдә Киевкә басым ясавына ирешмәкче һәм аны сөйләшүләр өстәле янына утыртмакчы, имеш. Әлбәттә, билгеле бер мантыйк монда бар. Бу җәһәттән, элегрәк булган охшаш хәлне искә төшерү дә урынлы. Хәтерләвебезчә, февраль ахырында илнең тыеп тору көчләре сугышчан кизү торуның махсус режимына да күчерелгән иде. Әмма Көнбатыш җавапның нинди булачагын яхшылап аңлатты һәм хәтта 2 километр тирәнлектәге бункерларны юк итә торган коралга ия булуларын да яшермәде. Ул чакта кизү торуның махсус режимы шуның белән тәгәлләнде кебек. Ә бу атнада Мәскәүдә халыкара иминлек мәсьәләләре буенча үткән конференциядә ясаган чыгышында саклану министры С.Шойгу Украинада атом-төш коралы куллану зарурлыгын бөтенләй дә кире какты.

Фоат УРАЗАЙ.

ИДЕГӘЙ мирзаның шанлы көннәре

(Дәвамы. Башы 29, 30, 31 нче саннарда).

7

Тарихи чыганаклар күрсәткәнчә, бу сугышта егермедән артык рус һәм литва кенәзе һәлак була. Идегәй мирза дошманны биш йөз чакрымлап куа бара, шулай Киев каласына килеп җитә. Аның капкалары каршында үзенең зур чатырын кордыра. Киевтән 3000 сум йолым акчасы түләттерә. Татарлар бөтен Киев, Подолия җирләренә тарала, аннан зур байлык, меңнәрчә әсирләр җыеп кайта. Әле 1363 елда ук, Литва кенәзе Ольгерд, Буг елгасының түбән агымын яулап, үзенә Кара диңгезгә чыгу юлын тәэмин итүгә ирешкән була. 36 елдан соң Бурсыклы сугышында җиңү нәтиҗәсендә бу җирләр кабат Алтын Урдага кайтарыла, далалар кабат татар атлары утлап йөргән көтүлекләргә әверелә. Шулай Идегәй мирза тырышлыгы аркасында Алтын Урданың чикләре киңәя, дәүләт ныгый, бер йодрыкка туплана башлый.

Бурсыклы сугышы, күпме низаглардан, өч-дүрт дистә ел буе барган тарткалашулардан соң да татар дәүләтенең әле һаман көчле, гайрәтле булып калуын бик ачык күрсәтә. Идегәй мирза үз язмышының иң биек ноктасына күтәрелә. Ул теләгәнә тулысынча ирешә, хыяллары тормышка аша. Хәзер аның алдында татар дәүләтен ныгыту, аның элекке данын кайтару максаты тора. Әмма ул шушы изге эшкә керештем дигәндә генә дәүләттә тагын низаглар башланып китә – бәкләр, әмирләр, угланнар баш күтәрә, һәркайсы тәхет дауларга тотына. Аларның нәфесен бастыру өчен, Идегәй мирзага кабат кулына корал алырга туры килә.

Бурсыклы сугышында тар-мар ителеп, шактый җирләрен югалткан һәм хәлсезләнеп калган Литва кенәзлегендә яшәүнең мәгънәсе беткәнгә, Туктамыш хан үз тарафдарлары белән Себергә барып урнаша, анда үзенә яңа олыс төзи. Алай гына да түгел, хәтта Сәмарканд әмире Аксак Тимер белән элемтәгә дә керә, уртак дошманнары Идегәй мирзага каршы көрәшү өчен аның белән сүз дә берләшә. Әмма 1405 елда Аксак Тимер, яу белән Кытайга барырга чыккач, үпкәсенә суык тидереп, үлеп китә. Туктамыш ялгызы торып кала.

Идегәй мирзаны дошманын тынычлыкта калдыра торган затлардан дип әйтүе кыен. Ул Туктамыш ханның кайда, ни хәлдә икәнен даими белешеп тора, еш кына үзара бәрелешләр дә булгалый. Бер бәрелештә Идегәй мирза, уңышсызлыкка очрап, далага качып китә. Тарихчылар күрсәтүенчә, бу алар арасындагы унбишенче бәрелеш булган! Туктамыш хан, үзен кабат Алтын Урданың төп хуҗасына әверелдем дип уйлап, тынычланып кала, уяулыгын югалта. Шулай гамьсез рәвештә кәеф-сафа корып ятканда кинәт яу белән Идегәй мирза килеп чыкмасынмы? Шунда ул кан дошманы Туктамыш ханның башына җитә. Тарихчылар фикеренчә, бу хәл 1405 елда Төмән каласы тирәсендә булган. Күрәсең, Туктамыш хан Аксак Тимер вафатыннан соң үтерелгәндер. Томски каласы тирәсендә «Туктамыш курганнары» дип аталучы курганнар да бар икән. Гомумән, ул тирәләр элек «Туктамыш йорты» дип атап йөртелгән. Литвадан киткәч, ул шушында килеп урнашкан, үзенә яңа «Йорт» корган. Туктамыш ханның үлемен рус елъязмалары да теркәп куйган. Мәсәлән, Архангелогорск елъязмасында 1406 елда Туктамыш ханның Себер җирендә, Төмән тирәсендә үтерелүе теркәп куелган.

Туктамыш ханнан котылганнан соң да Идегәй мирза тәхеткә үзе теләгән чыңгызыйларны утыртып, татар дәүләтен саклап калырга тырыша. Шулай тәхеткә бер-бер артлы Шадибәк, Булат, Тимер ханнар утыртыла. Соңгысы 1399 елда, Бурсыклы сугышыннан соң үлеп киткән Тимер Котлык ханның улы була.

1411 елда яшь Тимер хан белән агасы Идегәй мирза арасында зур низаг чыга, бәрелешләр булып ала. Әлбәттә, Тимер хан артында башка кешеләр торган, яшь хан алар кулында уенчык кына булган. Алар үзара көрәшкән арада Сарай каласын Туктамыш хан улы Җәләлетдин тартып ала, тәхеткә чыга. Күп тә үтми, яшь Тимер хан Җәләлетдин тарафыннан үтерелә (1411).

Шулай тагын да аяусызрак көрәш башланып китә. Бу юлы инде Идегәй мирзага каршы Туктамыш ханның бүтән уллары күтәрелә. Җиңелгән саен алар йә Кырымга, йә Литва кенәзе Витовтка барып сыена. Бераз көч туплагач, бәрелешләр дәвам итә. 1417 елда Идегәй мирза, ниһаять, Туктамыш улларын Алтын Урдадан кысрыклап чыгара. Әмма 1419 елда Туктамыш хан улы Кадыйрбирде кенәз Витовт ярдәме белән Кырым тәхетенә утыра. Шул ук елны Кадыйрбирде Кырымда тупланган зур гаскәр белән Иделгә әйләнеп кайта, аннан Җаек буена юнәлә. Сарайчык каласы янында (соңрак Нугай Урдасының башкаласы) Идегәй мирза белән Кадыйрбирде арасында каты бәрелеш була, кан коела. Кадыйрбирде үзе үтерелә, аның кешеләре кайсы кая качып бетә. Идегәй мирза да күп яралар ала. Сугыш шундый каты була ки, хәтта кайсы як җиңгәнне дә белә алмыйлар. Ике гаскәр дә таралып бетә.

Яраланган Идегәй мирза бер аулак урында туктап, яраларын бәйләмәкче, хәл алмакчы була. Бераздан бер нөгәрен хәлләрне белешер өчен разведкага җибәрә:

– Бар әле, хәлләрне белешеп кайт. Безнекеләрдән берәрсен очратсаң, монда җибәр, – ди.

Теге сугышчы юлда бер татар әмирен очрата да, аның элек Туктамыш ханда әмир булганлыгын белмичә, Идегәй мирзаның яралы килеш кайда ятуын сөйләп бирә. Әмир сугышчылары белән Идегәй мирзаны эзләп таба. Идегәй мирза аны күреп алу белән сүгәргә тотына. Теге исә:

– Көн безнең файдага тәгәрләнде. Без үз эшебезне башкардык. Син хәзер берни дә майтара алмыйсың, – дип, сугышчыларына Идегәй мирзага һөҗүм итәргә боера. Тегеләр карт мирзаны шундук тураклап ташлый. Шулай итеп, гомере дәһшәтле көрәшләрдә узган Идегәй мирза 67 яшендә сугыш кырында һәлак була. Бу хәл 1419 елда Җаек елгасы тирәсендә була.

* * *

Идегәй мирза – татар тарихында аерым урын алып торучы атаклы шәхес. Ул бик катлаулы тормыш юлы уза, үз гомерендә дәүләткүләм әһәмиятле бик күп вакыйгаларда катнаша, еш кына аларны теге яки бу якка борып җибәрүчеләрдән була. Шуңа күрә аның язмышы гаять катлаулы, бик тә каршылыклы. Гомеренең бер дәверендә ул, аралары бозылышкан кан дошманы Туктамыш ханнан үч алу белән мавыгып китеп, татар дәүләте Алтын Урданы хәлсезләндерү, аны җимерү эше белән шөгыльләнсә, картаймыш көнендә исә, хакимиятнең иң биек баскычына күтәрелеп, олуг мәмләкәтнең бәкләрбәге (асылда – ханнарны тәхеткә утыртучы) дәрәҗәсенә ирешә, таркалуга йөз тоткан татар дәүләтен бер йодрыкка туплау, хөкүмәтне ныгыту, дәүләтнең элекке данын, абруен кайтару өчен көрәшә. Бу эштә ул зур тырышлык күрсәтә, күп көч түгә, әмма күпме генә тырышмасын, хәтта бөек бәкләрбәк Идегәй мирза да таркалуга барган дәүләтне коткарып кала алмый. Тарихта башланган процессны туктатырга әллә нинди гайрәтле шәхеснең дә кодрәтеннән килми шул. Андый шәхес бу процессны бары тик беразга тоткарлый гына ала. Идегәй мирзаның бу омтылышы, шәмнең сүнәр алдыннан балкып куюы кебек, соңгы талпынуны хәтерләтә. Бу вакытта тарихи процессның аяусыз канунлары бөек татар дәүләтенә үз хөкемен инде чыгарган була. Таркала барган Алтын Урда җирләрендә бераздан яңа татар дәүләтләре – Казан, Касыйм, Әстерхан, Себер ханлыклары, Нугай Урдасы, Алтын Урда кыйпылчыгы рәвешендә яшәвен дәвам иткән Олы Урда барлыкка килә, халкыбыз үз тарихының яңа дәверенә аяк баса.

Солтан ШӘМСИ

Быел – 20 августта күренекле җырчы-композитор, режиссёр, педагог, Татарстан һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены иясе Илгиз Габидулла улы Мәҗитовның тууына 90 ел тула. Моннан биш ел элек аны Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә «Илһамият» клубы филармония сәхнә ветераннары катнашында чәй өстәле артында искә алган идек.

Күпкырлы шәхес

2019 елда И.Мәҗитовның исемен мәңгеләштерү йөзеннән филармония скверында аның истәлегенә исемле чыршы утыртылды. Хөкүмәтебез белән берлектә аның истәлегенә ул яшәгән йорт диварына мемориаль такта (авторы – скульптор Фәнил Вәлиуллин) эленде. Күренекле композитор истәлегенә такта ачылган мәлдә И.Мәҗитовның Дамир Гыйсметдинов сүзләренә язылган, халык арасында зур популярлык казанган «Гомер уза» җыры яңгырап торды. Аның тормыш юлы, иҗат еллары дә бик бәрәкәтле узган, аның чордашлары, күренекле сәнгать әһелләре дә шул хакта хәтер яңарта.

Илгиз Мәҗитов Казанда туып-үсә. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан төзүчеләр институтына укырга керә. Институтны тәмамлаган елны «Казанның яшь талантлары» дигән концертта җырчы буларак катнаша һәм аны Казан консерваториясенең ректоры Н.Җиһанов күреп, укырга чакыра. 1960 елда консерваторияне тәмамлап, Татар дәүләт филармониясендә дүрт ел солист-җырчы булып эшли. 1967-1972 елларда Мәскәүдә А.Луначарский исемендәге театр сәнгате институтында режиссерлар әзерли торган факультетта белем ала һәм М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында режиссер булып эшли башлый. 1973 елдан И.Мәҗитов Татар дәүләт опера һәм балет театрының баш режиссеры итеп билгеләнә. Опера театры сәхнәсендә ул «Дон Жуан» (В.Моцарт), «Любовный напиток» (Г.Доницетти), «Риголетто» (Дж. Верди) операларын, «Фиалка Монматра» (И.Кальман) оперettасын, «Мәкерле мәче» (Л. Хәйретдинова) дигән балалар операсын, «Волшебная свирель» (Г.Ротт) һәм башка спектакльләрен куя.

1975-1992 елларда И.Мәҗитов Г.Тукай филармониясенең сәнгать җитәкчесе вазифасын башкара. Ул республикабызда үткәрелгән барлык бәйрәм концертларының программаларын төзи, аларның режиссеры буларак Мәскәүдә, Каракалпак, Чуашстан, Башкортстан республикаларында, Әстерхан, Ульяновск өлкәләрендә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадалары концертларының баш режиссеры буларак танылa. Шулай ук мәркәзебездә төрле концертлар, әдәби-музыкаль кичәләр оештыра.

И.Мәҗитов композитор буларак, бик матур җырлар иҗат итә. Аның «Ак каеннар шаулый болында», «Урман юлында», «Яшьлегем сукмаклары», «Кайтырмын», «Гомер уза», «Акбүз атлы егеткә» һ.б. җырларын бик күп җырчылар репертуарларына кертә.

Илгиз Мәҗитов 2004 елның 14 июнендә вафат була, Казанның Яңа бистә Татар зиратында җирләнә.

Аның турында җылы хатирәләр:

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов:

«Ул бик акыллы егет иде, җырчы буларак консерваторияне тәмамлады, аннары Мәскәүдә режиссерлыкка укыды. Үзенең күңел байлыгын гел үстерә иде. Филармониядә эшли башлагач, аның белән бер бригадада гастрольләргә чыктык. Безнең белән баянчы, композитор Ганс Сәйфуллин да бар иде. Безне төрле өйләргә урнаштырдылар. Бер концерт вакытында мин программаның азагында идем, юлдан килеп арыган, күрәсең, бераз ятып торам әле дип, йоклап киткәнмен. Берзаман кемдер тәрәзәгә шакый, ул Илгиз Мәҗитов икән. «Эмиль, тор, концерт бетте бит!», – ди. Шулай миннән башка гына узып киткән иде ул концерт. Шундый кызык хәлләр дә булгалый иде кайчакта. И.Мәҗитов Опера һәм балет театрында режиссер булып эшләгәч, сәнгать җитәкчесе булып янә филармониягә килде. Ул җырчыларны сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтә, татар телен бик ярата иде, Тукайның бигрәк тә «Теләнче» шигырен яратып сөйли иде. Композиторлардан Рөстәм Яхинны бик хөрмәт итте. И.Мәҗитов сәнгать җитәкчесе булганда, филармония артистлары бик күп җирләргә гастрольләргә йөрде. Мәскәүләргә бергә бара идек. Кайда гына булмады филармония ул елларда. Бик матур җырлар язды, аның күп җырларын башкардым».

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Айдар Фәйзрахманов:

«Илгиз абый күңелемә Опера һәм балет театрында «Наемщик» спектаклен куйганда килеп керде. Мин анда – Гәрәй ролендә идем, Зөбәрҗәт партиясен Венера Ганиева башкарды һәм баш рольләрне башкаручы Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллиналар белән дә бик матур, дустанә, чын иҗади мөнәсәбәт белән бу спектакльне дөньяга китергән идек. Аннары И.Мәҗитов дигәч, аның туганы, танылган композитор Шакир Мәҗитов та искә төшә. Иҗади сәләт аңа да бирелгән иде. Илгиз абыйның җырларын бик яратып башкаралар иде, соңгы елларда гына бик ишетелгәне юк. Ул озак еллар Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе булды. Бу елларда Илгиз абый тагын бер күркәм эш башкаруга ирешә: дәүләт дәрәҗәсендәге күп кенә концертлар, бигрәк тә авыл хуҗалыгы эшчәннәре алдындагы концертларны Опера һәм балет театрында оештырып чыга торган иде. 80 нче елларда мин сәхнәгә килгәч, Илгиз абый мине дә шул концертларга чакыра торган булды. Луиза Батыр-Болгариның «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Кайту» җырларын башкаргач, халык тагын сәхнәгә чакырып җырлата торган иде. Илгиз абыйны бик хөрмәт итә идем, ул ике телдә дә камил сөйләшә, җырлый иде. Татар халкы өчен җан атып йөргән профессиональ режиссер иде. Ул килеш-кыяфәте белән, кешеләргә карата мөнәсәбәте белән дә, сөйләшү дәрәҗәсе белән дә бик матур, тәрбияле шәхес булып истә калган».

Татарстанның халык артисты Фердинанд Сәлахов:

«И.Мәҗитов – иҗат биографиямдә аерым урын алып тора. Консерваториядә ул операга әзерләүче укытучым иде. 1981 елда мине Римма Ибраһимова бригадасына тәкъдим итте, бу вакытта мин консерваториянең өченче курс студенты гына бит. Ул профессиональ сәхнәгә этәрүче, баскыч ясаучы булды. Кызыклы шәхес, заманы өчен алдынгы шәхес. Чөнки Илгиз ага ул чакта кесәсендә өч югары белем турында диплом йөрткән кеше – бик зур шәхес. Милли җанлы, татар җанлы кеше иде. Ул чын татар гаиләсендә үскән. Әтисе җырлар иҗат итә, һәвәскәр композитор, әнисен бик ярата иде. Әнисе чиста татарча сөйләшә иде, гәрчә ул заманда татар теленнән китү, руслашу модада булса да. Аның җанында татар сәнгатенә җылы мөнәсәбәт бар иде. Ул дәүләт күләмендә узган чараларның режиссеры булды, шунда ул үзенең татарлыгын күрсәтә белә иде. Көчле шагыйрьләрне – Гәрәй Рәхим, Ренат Харисларны, Айрат Арсланов, Нәҗия Минкина, Рәшит Сабиров, Гүзәл Мостафина кебек нәфис сүз осталарын чакыра иде. Аннары яшьләргә бик игътибарлы булды. Яшьләрне үстерде ул. Театр училищесы белән хәбәрдар иде, аннан яшьләр чыга, консерваториядә укытучы буларак та, филармониядә сәнгать җитәкчесе буларак та яшьләргә игътибарлы булды. Гәрчә ул башлангыч белеме белән төзүче булса да, сәнгать өчен туган шәхес иде».

Татарстанның халык артисты Искәндәр Биктаһиров:

«Мин Филармониядә эшли башлагач, ул үзенең җырларын тәкъдим итте. Иң беренче, радиода аның Ә.Ерикәй сүзләренә язган «Ак каеннар шаулый болында» дигән җырын Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле белән яздырдым. Шулай ук Г.Зәйнашева сүзләренә «Көнче күбәләк», И.Юзеев сүзләренә «Яшьлек узган сукмаклардан» җырларын да репертуарыма алдым. Алары әле дә бик яратып башкарам».

Истәлекләрне
Алсу ХӘКИМОВА туплады.

● Фәйзи Йосыпов, Илгиз Мәҗитов.

Ул инде 35 ел татарның төп театры булган Камал театры сәхнәсендә. Аны яратучы тамашачы да, кабул итмәүчеләр дә бар. Шунысы бәхәссез, аны сәхнәдә бер күрсәң, инде онытып булмый. Ул - үзенчәлекле, хисле актриса, табигатьнең иркә баласы. Комик рольләрне дә, тирән кичерешле трагик рольләрне дә бердәй осталык белән тудыра. «Казан егетләре»ндәге Хәбибәсе, «Җанкисәккәем»дәге Шүрәлиясе, «Килә ява»дагы Зәйнәбе, «Җирән Чичән…»дәге Карачәчсылуы, «Ромео һәм Джульетта»дагы Джульеттасы… - хисле, җете рольләр булып хәтергә кереп калды. Тамашачы аны татарча телесериаллардагы образлары өчен дә якын итте. Сүзем Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Тукай бүләге иясе Люция Хәмитова турында. Ышануы да кыен, гел яшь, чибәр, балаларча челтерәп көлеп җибәрүче сөйкемле актрисага шушы көннәрдә 55 яшь тулды. Без аның белән җәен бушап калган Камал театрының грим бүлмәсендә әңгәмә кордык. Бу бүлмәдә алты актриса утыра икән. «Сыябыз, – ди Люция минем сораулы карашымны аңлап, - без, актерлар, үзара бик дус яшибез, бергә бик күңелле». Алда - бер-ике сәгать вакыт. Шул вакыт эчендә героиняң йә сиңа күңелен ача һәм ихлас әңгәмә килеп чыга, яки күңел ишекләрен бикләп куя да, коры җаваплар гына тыңлап утырасың. Актрисаның күңел дөньясына сәяхәтен генә сезнең хозурыгызга тәкъдим итәм.

● «Өзелгән өмет» спектакле. 2009 ел.

«СӘХНӘ

АВЫЛЛЫ БАЛАЧАК

Ул минем өчен шундый кадерле вакыт булып истә калды, әлбәттә, бик тә сагындыра. Безнең балачак күмәкләшеп җыелып уйнап, күңелле итеп үтте бит. Мин Казан кызы, 5-6 яшьләремә кадәр Яңа Бистәдә үстем, үз йортыбыз белән яшәдек. Гаиләдә без ике кыз бала идек, сеңлем миннән 7 яшькә бәләкәй. Көне буе уйнап, өйгә төнлә генә кайта идек! Соңрак без кооператив фатир алып, Мәүлетов урамына күчеп киттек, шундагы 40 нчы мәктәпкә укырга кердем. Аннары җәй буе авылда яшәү! Әти-әнием чыгышлары белән Питрәч районының Татар Казысы авылыннан. Әтием шул авылда туып-үскән, ә әнием шунда җәйләрен Казаннан әби-бабасына кайтып йөргән. Минем дә бөтен җәйләрем шул авылда узды. Кәтү кәтә, бәбкәләр саклый идек. Минем эшем – бәбкәләрне су буена илтү, аларга ипи чәйнәп ашата-ашата авызларым арып бетә. Бабаем авылның беренче тимерчесе, бөтен әйберне ясый. Агач эшен дә, тимер эшен дә белә, кулыннан килмәгән эше юк. Дәү әни ризыкларны төенчеккә төйнәп бирә дә, мин аны алачыкка, бабайга илтәм. Ул печән алып кайтулар, үсә төшкәч клубка чыгулар – бик күңелле булып истә калган. Авылда безнең дәү әниләр нигезе сатылды инде, тик анда туганнар бар. Олыгаю галәмәте микән, бала чаклар бик сагындыра шул…

Әти-әниләрем бик гади кешеләр: әти башта милициядә эшләде, аннары озак еллар машина йөртте, ерак юлларга йөрде. Әнием гомере буе шәфкать туташы булып эшләде.

СӘХНӘ ХАКЫНА ОЯЛЧАНЛЫКНЫ ҖИҢДЕМ

Үземне хәтерли башлаганнан бирле артист булам, дип йөрдем. Беренче класска кергәч үк, үзем әзләп барып, бию түгәрәгенә язылдым. Әти асылы белән авыл кешесе булып калган, шактый кырыс, безгә артык ирек бирми иде. Үзенең күңеле бик йомшак. Ул минем бию белән шөгыльләнгәнемне бер дә җитдигә алмый, нинди бот болгап йөрү ул, ди иде. Шуңа күрә мин биюгә йөргәнне аңа әйтмәдем, ул мине тегүгә йөри дип белә иде. Әти белән әни гади эш кешеләре булса да, театрны бик яраттылар. Гел Камал театрына йөриләр, мине дә үзләре белән ияртәләр. Мин исә сәхнәдә уйнаган актрисаларга карап,

● «Зәңгәр шәл» спектакле. 2000 ел.

үземне алар урынына куеп, хыялланып утырам. Биюләр белән гел чыгышлар ясап торгач, сәхнәгә мәхәббәтем тагын да арта барды.

Ул чакта театр училищесының татар бүлегенә ике елга бер генә курс җыялар иде, ул минем тугызынчыны бетергән елыма туры килде. Каникулларны гел авылда үткәргәч, әти-әни белән дә өйдә татарча сөйләшкәч, татарчам яхшы гына, документларымны татар бүлегенә тапшырдым. Татар мохитен тоеп үстем бит, тик мәктәптә татар теле факультатив кына иде. Шуңа күрә без шәһәр балаларының шул ягы китек калды: русча уйлыйбыз, телебез камил түгел… Мәктәптә чакта ук имтиханнарга әзерләнү өчен, Мехчылар мәдәният сараендагы халык театрына йөри башладым. Аны Рифкать абый Ибәтов җитәкли, үзе дә театр училищесын тәмамлаган кеше. Ул миңа күп ярдәм итте, әсәрләр сайлашты, репетицияләр ясадык, кыскасы, ул мине укырга керергә әзерләде. Аңа бик рәхмәтлемен. Хәзер мәрхүм инде, иртәрәк китте.

Табигатем буенча мин тормышта бик оялчан. Тик сәхнәдә уйнау теләгем шундый көчле булган ки, өйрәнгән әсәрләремне яхшы гына сөйләп чыктым. Миндә нәрсәдер күргәннәрдер инде, алдылар. Марсель Хәкимович курсына эләктем. Уку чоры бик күңелле үтте. Марсель абый – курс җитәкчесе, Наил Дунаев, Илдар Хәйруллин – укытучыларыбыз булды. Безнең курста Рөстәм Галиев, Олег Фазылҗанов, Рамил Төхвәтуллин, Миләүшә Нәҗмиева, Гөлгенә Зәкиева,

● «Алдым-бирдем» спектакле. 1994 ел.

Фарил Вафиев, Альфред Камилевскийлар укыды.

ТЕАТРДАН КИТӘ АЛМАС ИДЕМ

Безнең курстан Камал театрына бер Рамил Төхвәтуллинны гына алдылар. Мине исә соңрак кына, ярдәмче составка гына кабул иттеләр… Театрга килеп керүгә үк рольләрем барлыкка килде. «Күк капусы ачылса» һәм «Ай тотылган төндә» безнең диплом спектакльләре иде. Без театрга килгән елны ук Илдар абый Хәйруллин «Күк капусы ачылса»ны куя башлады, мине шул ук Рәмзия роленә кертте. Аннары Башкортстаннан Вәлиев дигән режиссер килеп «Ай тотылган төндә»не куярга алынды һәм тагын безне шул ук рольләргә алды: мин анда Зөбәрҗәтне уйнадым. Дебют ролем Празат Исәнбәтнең «Таһир-Зөһрә»сендә Зөһрә роле булды. Менә шулай баштан ук рольләрем күп булды, шөкер.

Театрда безне җылы каршыладылар, өлкәннәрдән бер кырын караш та сизмәдем. Театрыбызның аурасы искиткеч яхшы бит, элеккеге артистлар шундый нигез салып калдырган. Гаилә мохите монда. Хәзер килгән яшьләргә дә шундый дустанә мөнәсәбәт.

Үзем уйнаган рольләрдән мин бик канәгать! Төрле жанрларда уйнадым: драматик та, комик та рольләрем булды. Иҗат язмышым өчен Аллаһыма бик тә рәхмәтлемен.

Әгәр дә язмыш шундый сынау алдына куеп, сәхнә белән гаилә арасында сайлау алдында калсам да, мин театрдан китә алмас идем, мөгаен. Сәхнәне сайлар идем. Башка юлны күз алдыма китерә алмыйм. Юк, хуҗабикә булып өйдә утыра алмас идем мин. Тик Аллаһка шөкер, мондый сайлау аша узарга туры килмәде...

ҮЗ ЯШЕМНЕ КАБУЛ ИТӘ АЛМЫЙМ

Тышкы матурлыкны саклар өчен көч куям, әлбәттә. Сәхнәне һәм үзен яраткан һәр актриса шулай эшлидер дип беләм. Сәхнәгә тазарып, ямьсез кыяфәт белән чыгудан бик куркам. Яшьрәк чакта гел бию белән шөгыльләндем, олыгая төшкәч, фитнес клублар ачылды, шуларга йөри башладым. Хәзер исә Фәрит белән дөрес тукланырга тырышабыз. Катгый диеталар булмаса да, яшелчә, парда пешкән ризыкка өстенлек бирәбез. Яшь барган саен авырулар да барлыкка килә башлый, шуңа күрә саулыкны кайгыр-

● «Җирән Чичән белән Карачәчсылу» спектакле. 1999 ел.

ЯШЬЛЕКНЕ ЯРАТА...»

● «Гөлҗамал» спектакле. 2007 ел.

тырга кирәк. Дөресен әйткәндә, мин үз яшемне кабул итә алмыйм. Кызлар белән дә бу хакта сөйләшкәлибез. Хәзер бит кеше яшәрергә тырыша. Әйтик, «Җанкисәккәем»дә без бер үк состав белән инде 20 ел буе 18 яшьлек шүрәлеләрне уйныйбыз, бер-беребездән көләбез дә.

Хәзер мин 6-7 спектакльдә уйныйм. Бу минем яшь өчен күбрәктер дә. Сәхнә бит ул барыбер яшьләрне ярата. Кайсы сәхнә әсәрен генә алсаң да, күпчелеге – яшь рольләр, арада бер-ике әби-бабай була. Мин хәзер ни яшь түгел, ни карт түгел. Яшь кызларны инде уйный алмыйм, ә әбиләр өчен туры килеп бетмим. Шулай да минем «әбиләрем» бар инде. «Килмешәк»тә әби ролем, «Бию пәрие»ндәге әбиләрнең дә берсе мин. Ул ролемне шулкадәр яратам, гомумән, бу спектакльдә уйнавы җанга рәхәт.

ЛЮЦИЯ-ЭМОЦИЯ

Холкым белән бик хафаланучан кеше мин. Кәефемне күп нәрсә төшерә ала. Бик тиз борчуга төшә алам. Бөтенләй тыныч яши белмим дияргә була! Театрда миңа Радик Бариев «Женщина-стресс» дигән кушамат та такты хәтта. Администраторыбыз Фәридун Нуретдин углы исә «Люция-эмоция» дип кенә дәшә иде. Юк кына нәрсә өчен дә борчылам кайчагында. Йосыф өчен дә кирәксә дә, кирәкмәсә дә борчылам, югыйсә, ул яшьтән бик мөстәкыйль булды, 18 яшендә үк студентлар өчен программа белән Кытайга ук чыгып китте. Нишләтәсең инде, холкым шундый. Күпмедер вакыт узгач кына үзеннән-үзе суынам, тынычланам.

ҮКЕНЕЧЕМ БАР

Тагын бер бала тапмадым – иң зур үкенечем шул. Безнең яшьлек 90 нчы елларга туры килде, билгесезлек чоры, болганчык вакытлар, бәлки шуңа бер бала белән калганбыздыр. Хәзер исә яшьләр курыкмый, икене дә, өчне дә табалар. Артистларыбызның һәркайсында ким дигәндә икешәр бала. Бердәнбер улыбыз Йосыф гомерле булсын да, теләкләренә ирешсен иде дип телим. Ул башта театр училищесына керергә теләгән иде, тик без аны башта мәктәпне тәмамларга күндердек. Аннары ул КФУга керде, кытай телен өйрәнде. Аны тәмамлагач, 1-2 ел әзерләнеп, ГИТИСка керде, анда ике ел укыгач, Казанга кайтты. Хәзер ул музыка белән җенләнә. Театрыбыздагы бер-ике тамашаны музыка белән бизәүдә катнашты. Кариев театрында куелган «Йосыф» спектаклен тулысынча музыка белән ул бизәде. Күпләр аның бу эшен уңышлы дип бәяләде. Аңа хәзер 29 яшь. Үз насыйбы очрар әле, хәерлесе булсын, дим. Иң мөһиме, улым бүген җаны теләгән эш белән шөгыльләнә!

ИҢ ЯХШЫ ЯЛ - СӘЯХӘТ

Без сәяхәт итәргә бик яратабыз. Дөнья буйлап шактый йөрергә насыйп булды, күбесенчә – гастрольләр белән. Колумбиягә хәтле бардык бит. Норвегиядә, Чехия, Берлин, Парижда булганыбыз бар. Фәритнең туганнан туган энесе Америкада яши, анда да кунакка бардык. Словениягә ял итәргә барабыз, андагы тынычлык, табигать бик ошый.

Бәрәскәдәге йортыбызга кайтып, тыныч кына авылча ял итәргә дә яратабыз. Фәрит гомумән авылга гашыйк, пенсиягә чыккач, торырга кайтып китәм, ди. Минем исә котым чыга, анда озак тора алмыйм. Мин бит шәһәр кешесе, миңа цивилизация кирәк. Берүзем генә фатирыбызда калып ял итәргә дә яратам...

ИХЛАС БУЛЫРГА КИРӘК!

Үз эшемне үлеп яратам. Безнең эштә ихласлык кирәк. Әгәр син чыннан да бу һөнәрне яратасың икән, эш сине үзе үстерә, күтәрә, аның авырлыкларын да сизмисең. Миңа эшемнең ниндидер читенлекләре дә авыр булып тоелмый. Андагы бөтен нәрсә ошый: гастрольләре, интегеп эшләгән рольләрем, репетицияләр… Үзеңнең хыялларыңа, теләкләреңә хыянәт итмәскә кирәк. Ихласлык - артист өчен бик мөһим сыйфат ул. Үзең булып калырга кирәк. Шул чагында тамашачы мәхәббәте дә, алкышлар да, иҗади канәгатьлек тә үзеннән-үзе киләчәк.

Эльмира СИРАҖИ
әзерләде.

Нәкый Исәнбәт – татар мохитендә хаклы рәвештә «халык академигы» дигән мәртәбәле исем белән атап йөртелгән олпат шәхесебез. Шуңа күрә дә «Шәхесләребез» («Знаменитые личности») сериясендә ушбу ардаклы классигыбызга багышланган фәнни-популяр җыентыкның чыгуын республикабыз җәмәгатьчелеге зур вакыйга итеп каршылады (Нәкый Исәнбәт / төз. М.Хәбетдинова. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2021. – 735 б. Фәнни мөхәррире –Фәнзилә Җәүһәрова).



«Халык академигы»

Шунысы мөһим һәм аеруча калкулатуга лаек: әлеге китапның күпчелек өлеше моңарчы беркайда да басылмаган архив материалларыннан тора. Алар – авторның тәрҗемәи хәленә, четерекле чорларга туры килгән тормыш һәм сикәлтәле хезмәт-иҗат юлына багышланган алтын бәясенә торырлык фактик материаллар. Авторның үзе туплап калдырган шәхси архивын ике ел буена өйрәнгән һәм, аерым махсус җыентык итеп төзеп, җәмәгатьчелек хөкеменә тапшырган Миләүшә Хәбетдинова кереш мәкаләсендә әлеге хезмәтнең нәкъ менә үзе шаһит булган һәм, үзе кичереп, беренче заттан язылган реаль истәлекләргә, шулай ук аналитик уйлану-бәяләнүләргә корылганлыгына басым ясый: «Безнең максат, – ди ул.– Н.Исәнбәтнең үзе турында һәм үзе яшәгән чор турында аның туры һәм чын сүзен җиткерү».

Китапта урын алган материалларны, эчтәлекләренә карап, өч төркемгә яки бүлеккә аерырга мөмкин: 1) Н.Исәнбәтнең турыдан-туры тормыш һәм хезмәт-иҗат юлына арналган, төрле вариантларда машинкада басылган текстлар. Аларда әдипнең сәяси биографиясе, социаль-эстетик мәсләге һәм үзе якыннан белгән яки аралашкан аерым чордашларына мөнәсәбәте чагылыш тапкан. 2) Күпкырлы иҗатчының традицион һәм профессиональ культурабыз, шул исәптән тел-авыз иҗаты һәм җыр-музыка сәнгатебезнең язмышы һәм киләчәге турында кайгыртып язган фәнни-публицистик мәкаләләре. Боларга янә авторның социаль чыгышына һәм иҗатына да кагылган, иң мөһиме, билгеле бер тарихи чорларның иҗтимагый-мәдәни тормышында, агарту-мәгърифәт өлкәсендә зур роль уйнаган, әмма тарих һәм әдәбият фәнендә үзенең тиешле һәм чын-дөрес бәясен алмаган хезмәте килеп ялгана. Бу фәнни-публицистик хезмәт яңарыш-реформаторлык (үз исеме белән әйткәндә,«җәдитчелек») хәрәкәте турында җитди уйлануларга һәм үтә үзенчәлекле нәтиҗәләргә корылган. 3) Әдип һәм галимгә кайбер каләмдәшләреннән һәм хезмәттәшләреннән килгән, шулай ук төрле оешмаларга яки җитәкчеләргә үзе язган хатлар, авторның биографиясенә, иҗатына бәйләнешле аерым рәсми документлар.

Нәкый ага (Мин Нәкый аганы якыннан беләидем. Ул минем шигырь төзелеше турында язылган кандидатлык диссертациясен яклауда катнашып, хезмәтемне хуплап чыгыш ясады. Соңыннан миңа үзе исән вакытта «Балалар фольклоры» (Казан, 1984) дигән китабына рецензия ясарга насыйп булды (Казан утлары, 1985, №3) үзенең шәхси биографиясен кайта-кайта, өстәмәләр белән тулыландыра-тулыландыра эшләгән. Чөнки аның язмышы һәм иҗат юлы, алда искәртелгәнчә, гаҗәеп катлаулы һәм четерекле чорларга туры килгәнлектән, көтелмәгән, хәтта хәвефле борылышлар һәм шәхесне бинахак кимсетә һәм изә торган социаль каршылыклар белән уралган. Менә шул авыр сынаулар һәм тоталитар режим корган «сират күпере» һәм «кызыл террор» аша үтеп, ул исән калган. Алай гына да түгел, чәмләнеп һәм гадәттән тыш түземлек-тырышлык күрсәтеп, әдәбият һәм халык иҗаты мәйданында үзенең лаеклы урынын яуларга ирешкән. Классик язучы булу өстенә, искиткеч бай фольклор мирасы туплап, киң җәмәгатьчелеккә тапшыручы каһарман булып танылган. Шуңа күрә дә язмабыз үзәгендә каһарманыбызның үтә аянычлы һәм гыйбрәтле, шул ук вакытта җиңүле-героик биографиясе булачагы бик табигый.

Тәрҗемәи хәлен Нәкый ага җиденче бабасы Исәнбәтнең «Казан ягындагы милли изелүдән качып, башкорт арасына сыенып, шунда үзләренә авыл корып утырган татар типтәрләренең берсе» булганлыгы белән таныштырудан башлый. Әтисе Сираҗетдинның укымышлы нәселдән чыгуына һәм хөр фикерле «җәдит» мулла булганлыгына басым ясый. Үзе әйтмешли, абыстай әнисеннән «сәкедә терсәкләнеп укыргаязарга өйрәнгәч», башлангыч белемне дә ул Мәләвез авылында (хәзерге Салават районы) әтисе салдырган һәм үзе тоткан «җәдит мәдрәсәсендә» ала. Өйрәнчек шигырьләрен дә шунда укыган чагында, 9-10 яшьләрендә «чыгара» башлый.

Булачак әдипнең моннан соңгы мәдрәсә тәрбиясенә бәйле уку еллары башта Уфада урнашкан «Хәсәния» мәдрәсәсендә, аннары Казандагы «Мөхәммәдия»дә үтә. Бу мәдрәсәләрдә укыту дөньяви белем бирү белән аралаштырылып, яңача ысулда алып барылса да, «шигырь җене» кагылган яшь егет күңеле белән муллалыкка түгел, гел иҗатка тартыла. Беренче басма шигырьләрен дә Казанда нәшер ителгән «Ак юл», «Сөембикә», «Аң» журналларында чыгара.

Ә ары таба, дөньяви тормышка ашкынган җилкенчәк егет мәдрәсәдә укуын бөтенләй ташлый һәм, туган ягына кайтып, татар мәктәпләрендә әдәбият укыту, күңеле яткан мөгаллимлек эше белән дә шөгыльләнә башлый. Октябрь революциясен дә Башкортстанда каршылый. Гарасатлы һәм болгавыр егерменче елларда Халык мәгариф институтында укырга керешү һәм ачлык аркасында яшәү урынын алмаштырулар булып алса да, ахырда ул Уфага килеп урнаша һәм кырык елдан артык бергә гомер итәчәк Гөлсеменә өйләнеп, 1929 елга хәтле өзлексез татар урта мәктәпләрендә әдәбият укытучысы булып эшли. Шул ук вакытта, әлбәттә, язучылык эше белән шөгыльләнүен дә ташламый.

Күрәсең, татарларның төп мәркәзе булган калада да, насыйп булса, акрынлап әдәбият мәйданында үз урынымны яуларммын дип өметләнгәнгә күрәдер инде, каһарманыбыз 1929 елның ахырында Казанга килә һәм, гаиләсен дә шунда күчереп, театр техникумына тел-әдәбият укытучысы булып эшкә урнаша. Әмма монда ул иҗади рух хөкем сөргән даирәгә түгел, ә 30 нчы елларда башланган низаглы һәм гаугалы мохиткә килеп эләгә. ТАПП дип аталган язучылар оешмасы шул чорда «сыйнфый уяулык» күрсәтеп, партия сафында тормаган һәм завод-фабрикалар белән тыгыз бәйләнеше булмаган язучыларны революцион пролетариаттан аерылуда, «буржуаз юлаучы»лыкта гаепләү юлына баса. Ушбу «пролеткультчылык» тозагына, нахак яла ягылып, бернинди гаебе булмаган Н.Исәнбәт тә эләгә. Тыйнаклык саклап үзе кистереп әйтмәсә дә, әлбәттә, монда Башкортстанда шактый танылып өлгергән язучыдан көнләшү, үзләреннән өскә чыгармау ниятенә бәйле мәкер дә катнашкан булуга охшый. Аны һәм үзе кебек бернинди дә оешмада тормаган җиде язучыны «Җидегән» (бу язучыларның исемнәре: Кутуй, Исәнбәт, Ченәкәй, Минский, Агиш, Сәйфи Кудаш. Соңгы ике язучы, Башкортстанга китеп, эзәрлекләүдән котылып кала) дигән яшерен «контрреволюцион оешма» төзеп, совет идеологиясенә, «пролетар культурага» каршы астыртын эш йөртүдә гаепләп чыгалар һәм дә шул төркемне фаш итү, эзәрлекләү кампаниясе башлап җибәрәләр.

Н.Исәнбәт ясалма һәм ялган яла рәвешендә оештырылган әлеге сәяси ыгы-зыгыдан котылып калу теләге белән, үз сүзләре белән әйткәндә, «интригантлар мине табалмаслар әле» дип уйлап (димәк, үзен математик дигән нейтраль профессия алырга җыенучы кеше итеп күрсәтергә ниятләп), педагогика институтының физика-математика факультетына керергә гариза бирә. Ләкин 1931 елның февралендә «җидегәнчеләр» кушаматы тагылган Минский, Исәнбәт, Ченәкәй һәм Кутуйны кулга алалар. Боларның баштагы икесе (берсе, димәк, Нәкый Исәнбәт) «Черек күл» төрмәсендә ике ай ярым утырганнан соң, дәлилләр җитмәү сәбәпле, иреккә чыгарыла. Ә калган икесе сигез айдан соң азат ителә. Шулай итеп, әлеге язучыларны бинахак яшерен «буржуаз контрреволюцион оешма» төзүдә гаепләү, күрәләтә яла ягуга нигезләнгән «эш» пыран-заран килә.

Мәгәр «җидегән» маҗараларының шаукымы, Н.Исәнбәтнең ишле гаиләсе өстенә төшкән мораль һәи матди бәла-каза шактый гомерле булып чыга. Гаилә башлыгы матбугатта бер-бер артлы чыгып торган мәкаләләрдә үзенә тагылган «контр», «буржуазия калдыгы»,«мулла токымы», «хәзрәтчик» кебек мыскыллы исемнәр күтәрү өстенә, театр техникумындагы укытучылык эшеннән китәргә мәҗбүр була. Аннары, хәзерге укучы өчен иң гаҗәбе – заман һәм дә ТАПП хуп күргән пролетариат дөньясына якынаю, эшчеләр сыйныфыннан аерылмавын раслау өчен, «хезмәт биржасында» белешеп, «Спартак» фабрикасына җыештыручы-себерүче булып «кара эшкә» барып керә. Билгеле, тырышлыгын һәм эшенә җаваплы караганын күреп, берничә айдан аны итекләр парлау цехына күчерәләр. Әмма эшче һөнәрен үзләштергән ишле гаилә башлыгын монда да тынычлыкта калдырмыйлар. ТАПП идарәсе әгъзалары фабрика клубында махсус җыелыш ясап, «Җидегән» буржуаз оешмасының «тетмәсен тетеп», җидегәнчеләрне хурлый, мыскыллый торган җырларга корылган концерт оештырып китә.

Шул чордагы тормыш турында Н. Исәнбәт үзе «әдәби биографиясендә» менә ничек яза: «Минем хәлемә килгәндә, бу вакыт өем тулы бала, үземә үз тапканым гына җитмәгәч, төнге сменага хатыным белән төшеп эшлибез. Ягарга утыныбыз булмаганлыктан, [фабрика чүплегеннән] стелькадан киселгән йомычкалар ташып, шуны ягып җылынабыз. Аякта сары ботинка, ертык үкчәле оек... Үзем вакыт-вакыт «Спартак» трагедиясен яза идем. Белүебезчә, биш пәрдәлек бу драма әсәрен әдип 1931-1932 елларда яза. Димәк, коточкыч авыр шартларда яшәргә дучар ителсә дә (үзе әйтүенчә, ул кайбер көннәрне 16-шар сәгать эшләгән) һәм «пролетар культура» сагында торучылар тарафыннан аны әдәбият мәйданыннан сөреп чыгаруга юнәлдерелгән ямьсез адымнар ясалып торса да, Нәкый ага кулыннан каләмен төшермәгән.

1933 елда күренекле телче, соңрак «кызыл террор» корбаны булган Галимҗан Шәрәф Исәнбәтне химия-технология институтының «рабфагына» тел-әдәбият укытучысы итеп эшкә чакырып ала. Ләкин тиздән, нәкъ шул чорларда, тоталитар режимга бәйле репрессияләр, «халык дошманы» дигән исем белән тамгаланып, кулга алулар һәм Себергә сөрү, хәтта үлем җәзасына хөкем итүләр башлана.

Нәкый Исәнбәт

Әдипнең биографиясендә конкрет исемнәрдә күрсәтелгәнчә, шактый күп татар язучылары, культура-сәнгать өлкәсендә эшләүчеләр шул елларда шәхес культы, «кызыл террор» корбаны була. Үз вакытында «Интернационал»ны татарчага тәрҗемә итүчеләр арасында беренче урынны алган, ә әлеге чорда Октябрь революциясенең 10 еллыгына багышлап, «Октябрь» исемле пьесасын тәмамлап килгән Н.Исәнбәтне гарасатлы давыл кыл өстендә тотса да, бөтереп алырга өлгермичә кала.

Сәяси эзәрлекләүләр басыла төшкәч, көн тәртибенә 40-нчы елда Мәскәүдә узачак татар сәнгате декадасына әзерлек мәсьәләсе килеп баса. Мәртәбәле милли эпик герой таләп ителгәнлектән, драматург буларак үзен танытып өлгергән Исәнбәтне «Идегәй» трагедиясен язарга утырталар. Гомәр Бәширов белән Муса Җәлилнең уңай рецензияләрен алып һәм Александр Фадеев җитәкчелегендәге Мәскәү комиссиясенең хуплавына лаек булганнан соң, әлеге трагедия һәм авторның моннан алда тәмамлаган «Хуҗа Насретдин» комедиясе башкала тамашачыларына күрсәтелергә тиеш дип табыла. Ләкин, Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, декада булмый кала.

Татарда «кара сакалың, кая барсаң да, артыңнан калмас» дигән мәкаль бар. Н.Исәнбәт моның мәгънәсен болай аңлата: «Кара сакал – кара бәхет яки күрәчәгең, яки яманатың үзең белән йөри, дигәннән». Әгәр 30 нчы елларда әдипне контрреволюцион «җәдитче»лектә, «пролетар культура» дошманы булуда гаепләгән булсалар, 1944 елда Н.Исәнбәт исеменә һәм иҗатына кагыла торган тагын бер сәяси җәнҗал чыга. Анысы сәнгать декадасына әзерлек барган чорда, ягъни 1940 елда Нәкый аганың кереш сүзе белән «Совет әдәбияты» журналында (№11, 12) басылган һәм С. Липкин тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүгә җибәрелгән «Идегәй» дастанына мөнәсәбәтле ВКП (б) Үзәк Комитетының карары белән бәйле.

Белүебезчә, 1944 елда чыгарылган әлеге карарда җыйнама тексты Н. Исәнбәт тарафыннан төзелгән һәм эшкәртелгән халык дастаны «Идегәй»гә фәкать сыйнфый күзлектән чыгып кына бәя бирелә һәм ул «феодаль ханнарны идеаллаштыра торган зарарлы эпос» дип игълан ителә. Гәрчә әлеге әсәрнең җыйнама тексты Партия Өлкә Комитеты белән килешеп, тел, әдәбият, тарих фәнни-тикшеренү институты карары нигезендә төзелгән булса да, Үзәк Комитет тарафыннан «ачылган гаепне» бары Исәнбәт өстенә генә өеп калдыралар. Әдипнең хатыны Гөлсемнең өлешчә «Казан утлары»нда, өлешчә «Азат хатын» журналында басылган истәлекләрендә бу хакта ачыктан-ачык болай диелә:«Аны җыючы без түгел, аны Исәнбәт эшләде» дип, аны гына гаепләделәр. Хөкүмәт кушуы белән башкарылган бу эштә Исәнбәт ялгызы гаепле булып калды».

Бер килсә, килә бит ул. Ир уртасы чоры гарасатлы заманга туры килгән Нәкый аганы тагын бер һәлакәт сагалап торган икән. Моңа авторның 1953 елда «Комедия һәм драмалар» дигән җыентыгында басылган «Миркәй белән Айсылу» драмасы сәбәп була.«Кызыл террор» чорыннан калган гадәт буенча, әләк-шикаятьләр язып, бер-берсен чагу һәм көндәшләрен батыру эшенә алынган кайбер әдәбиятчылар (атап әйткәндә, Р.Ишморат белән Баян Гыйззәт) Нәкый аганың әлеге пьесасында идеологик «крамола» табып, янәсе, «драматург «җәдитчелек»не яклый, панисламистлык печәте яга» дигән ялган һәм мәгънәсез бәла ягып, сәхнәдә бара торган әлеге драманың куелуын туктатырга ирешәләр. Хәтта басылган җыентыкны, сатуга чыгармыйча, яндырырга тәкъдим итәләр.

Ләкин 30 нчы еллар өчен хас булган яла ягу, батыру нияте һәм ысулы барып чыкмый. Өлкә партия оешмасының Н.Исәнбәтнең «гаебен» тикшерүдә катнашуына һәм Республика язучылар союзының идарә утырышында әлеге «эшнең» махсус рәвештә каралуына карамастан, С.Хәким, Ф.Хөсни, Ә. Фәйзи һәм кайбер башка әдәбиятчылар тикшерү барышында Нәкый аганы, нигездә, яклап чыга. Ә «гаугалы» драманың авторы исә үзенең чыгышында, курыкмыйча, Өлкә Комитеты бюросының үзен милләтчелектә, панисламчылыкта гаепләгән карары белән килешмәвен кистереп әйтә.

Ә инде соңыннан, шушы урынсыз гаеп тагу, эзәрлекләүдән соң, өзлегеп, ике ай урын өстендә ятып аякка баскач, буш урында чыккан гауганың нәрсә белән бетүен без Н.Исәнбәтнең хатыны Гөлсем ханымның язмасыннан укыйбыз: «Улыбыз Булат Нәкыйның таякка тотындырып, Мәскәү Үзәк Комитетына алып китте. Үзәк Комитет «Миркәй белән Айсылу» әсәрен русчага тәрҗемә иттереп, тиешле рецензияләр алганнан соң, гаепле нәрсә тапмыйча, Нәкыйне аклап кайтарды. Гадел хөкемне шунда күрдек».

Нәкый аганың «Җәдитчелек турында» дип исемләнгән катлаулы теманы өйрәнергә алынуы да үзен тетрәндереп аяктан еккан шушы гаугалы хәл белән бәйләнгән. Чөнки ул чын галимгә хас уяулык һәм сизгерлек белән татар милләте даирәсендә барган җәдитчелек хәрәкәте белән мәгърифәтчелек хәрәкәтенең үзара тыгыз үрелгәнлеген абайлаган; бер үк милләт, бердәм агым төшенчәләре астында үзара керешә, бергә берләшә торган әлеге юнәлешләрне, сыйнфый күзлектән карап, ясалма рәвештә прогрессив-демократик һәм реакцион-буржуаз агымнарга бүләргә ярамаганлыгын аңлаган. Ә менә язучылар идарәсенең махсус карарында исә «җәдитчелеккә уңай характеристика бирүдә», «социалистик реализмнан читләшүдә» гаепләнүче Нәкый агага мондый шаккатыргыч бәя бирелә: «Вопреки исторической правде, Н.Исанбет стирает всякую грань между выдающимся просветителем-демократом Каюмом Насыри и буржуазно-дворянским ученым-богословом [Шигабетдином] Марджани, он показывает просветителя в качестве ученика Марджани, таким образом отождествляет просветительство реакционным течением джадидизма».

Төрле чорларда үзенә аралашырга насыйп булган һәм күренекле әдипләр булып танылган шәхесләрдән Шәехзадә Бабич һәм Галимҗан Ибраһимов турында Нәкый ага язып калдырган истәлекләр дә бүгенге укучыга һәм әдәбият белгечләренә кызыклы яңалыклар алып килә, шул исәптән Бабичның моңарчы имеш-мимеш версияләрдә аңлатылган үлеменә ышанычлы ачыклык кертә.

Н.Исәнбәтнең, яңалык-үсешкә омтылучы күпкырлы шәхес һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, турыдан-туры милли культурабызны, әдәбият-сәнгатебезне үстерү турында кайгыртып язган фәнни-публицистик мәкаләләре шулай ук җитди игътибарга лаек. Шундыйлардан, әйтик, көйләм шигыреннән (музыкаль ритмлы гаруз традициясеннән) сөйләм шигыренә күчкән чорда Сәгыйть Рәмиев белән Бабичның силлабик һәм иреклe ритмлы формаларны үз итә башлавын үрнәк итеп китерүе, үзенең дә табигый басымнарга һәм сөйләм интонациясенә корылган шигырь язганлыгын искәртүе моңа характерлы мисал була ала. Янә килеп, үз сүзләре белән әйткәндә, бөек Тукай мәктәбе традицияләрен дәвам итеп, шул ук егерменче елларда автор аерым шигырьләрен һәм җыр текстларын (мәсәлән, киң танылган «Уракчы кыз» җыры) халык җырлары вәзенендә һәм үрнәгендә иҗат итә.

Ә инде Нәкый аганың Татарстанның 50 еллык уңае белән Республика язучылар союзы идарәсенә адресланган хаты үзәгендә күпләрне борчыган, әдипнең гаҗәп урынлы һәм, төптән каерып масштаблы фикер йөртүен раслаучы җитди мәсьәләләр чагылыш тапкан. Атап әйткәндә, анда соңрак язучылар съездында да, шау-шу тудырып, стихияле төстә күтәрелгән яшьләр журналы булдыру кирәклеге зарури таләп рәвешендә көн тәртибенә куела. Әлеге хатта шулай ук илгә 300 миллион тонна нефть биргән республикабызда театр журналы булдыру һәм башкалабызда кино студиясе ачу соралганлыгы һәм халкыбызның моңа, һичшиксез, хаклы булганлыгы да нигезләнә. Бу инде, димәк, бүгенге көндә тормышка ашкан бу бик вакытлы һәм урынлы таләпләрне беренче булып рәсми рәвештә күтәргән кеше әлеге дә баягы тынгысыз һәм чын милли җанлы Нәкый ага Исәнбәт булган дигән сүз.

Әлбәттә инде, җыентыкта атакалы фольклорчы булып танылган Нәкый аганың яшьтән үк һәм гомер буенча халкыбызның тел-авыз иҗаты белән кызыксынуы һәм аны җыю, бастырып чыгару белән шөгыльләнүе турында сөйли торган фактлар да урын алган. СССР Фәннәр академиясенең Башкортстанны өйрәнү җәмгыяте тарафыннан 1928 елда бирелгән таныклыгында, мәсәлән, яшь язучының тел һәм фольклор экспедициясенә җибәрелүе күрсәтелә. Ә менә егерменче елларда язылган «Бер дәрвишнең юл дәфтәре» исемле язмасында исә автор Башкортстанның башкорт һәм типтәр-мишәр авылларында ничек фольклор үрнәкләре җыюы (җөмләдән, Урал-Өйрәндек төбәгендәге Сәет авылында халык җырчысы Фәйзулла карттан иллеләп көйнең җырларын, тарихын язып алуы) турында кызыклы һәм мавыктыргыч истәлекләр теркәп калдырган. 1960 елда «Минем язучы булуым һәм халык иҗаты өйрәнүем» дип исемләнгән һәм Казан радиосында ясаган чыгышында «илле ел буена төрле шигырьләр, драмалар һ.б. әсәрләр язуым белән бергә, халык иҗатын җыю һәм өйрәнүне дә бер вакытта да ташламадым» дип белдерә һәм фольклор мирасының ничек тупланганлыгына һәм ничек җыярга кирәклегенә дә кат-кат басым ясый. Гөлсем ханымның истәлек язмасында «җәйләрен капчык асып, авылларга чыгып фольклор җыю Нәкый Исәнбәтнең яраткан эше иде» – дип ассызыклаган сүзләре әдипнең югарыда әйткәннәрен, вөҗданә һәм характерына хас асыл сыйфаты булганлыгын, тагын бер мәртәбә, калкуландырып, игътибарыгызга ирештерә. Ә инде фольклорчы галимнең җыентыкта бирелгән «Татар фразиологик әйтемнәрендә тарихилык һәм үткән белән хәзергенең чагылышы» дигән мәкаләсенә килсәк, ул авторның фәнни стилен һәм аналитик фикер сөрешен кузалларга мөмкинлек бирә торган үрнәк буларак кабул ителә.

Йомгаклап әйткәндә, әдәбият белгече Миләүшә Хәбетдинова тарафыннан фәнни кулланышка кертелгән архив материалларының гамәли һәм теоретик әһәмияте, ачыклап әйткәндә, энциклопедист галим, фольклорчы, тел белгече, күренекле татар язучысы Н.Исәнбәтнең катлаулы һәм сикәлтәле тормышын, иҗат юлын яңача аңларга һәм дөрес бәяләргә мөмкинлек бирүе бәхәссез. Бер үк вакытта, бу материаллар XX гасырның «Хрущев җепшеклеге» чорына кадәр сузылган әдәбиятыбыз тарихын тулырак аңларга һәм танып белергә дә нык ярдәм итәчәк. Җыентыкны төзүченең астөшермәләрендә бирелгән күпсанлы аңлатмалар һәм өстәмәләр исә белгечләр һәм сизгер әдәбият сөючеләр тарафыннан шушы юнәлештә ясалган башлангыч адымнар рәвешендә кабул ителәчәк.



Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы,
КФУ профессоры.

Чүлмәк сәнгатен



«Тормыш өслүбе – мәдәни код» II Этно-fashion халык иҗаты һәм гамәли бизәү сәнгате фестивале кысаларында Казанда узган кызыклы чаралар арасында керамикага багышланган «түгәрәк өстәл» дә бар иде. Ул Муса Җәлил урамында урнашкан «Ишморат» керамика остаханәсендә үткәрелде.

Оештыручысы – туган як мәдәниятен өйрәнүче Римма Кашапова. Остаханә Профсоюз һәм Кремль урамнары арасында шәһәр үзәгендә бик җайлы җирдә урнаша. Җитәкчесе – Риза Ишморатның оныгы Снежана Хәйруллина. Биредә күзләре күрүдән мәхрүм оста Илгизәр Хәмидуллин, керамист Лилия Сафуанова һәм тагын берничә яшь белгеч иҗат итә. Берничәсенә күптән түгел ике атнага Үзбәкстанга барып балчык эшләнмәләр иҗат итүдә осталыкларын камилләштерү насыйп булган. Аларга хыялларын тормышка ашырырга Мәдәният министрлыгы каршындагы Татар мәдәнияте ресурс үзәге ярдәм иткән. Кечкенә генә «Ишморат» галереясы осталарына Үзбәкстанга бару мөмкинлеге тудырылгач, укучылар республикабызда керамика сәнгате чәчәк ата, дип уйларга мөмкин. Әмма кызганыч ки, бу – ялгыш фикер.

Казан фәнни-тикшеренү техник университетының дизайн факультеты деканы профессор Винера Хамматова шәкертләрен кызганып еламый гына. Анда керамика бүлеге уникe ел элек оештырылган булса да һәм ел саен аны 15-20 керамика остасы тәмамлап чыгуга карамастан, аларны эшкә урнаштыру мәсьәләсе әлегә кадәр хәл ителмәгән. Шуңа күрә дипломлы белгечләребез Мәскәү, Санкт-Петербургка китеп югала. Республикабызда чын талантлар бик аз кала. Күбесе – йә балчыктан әвәли, яисә рәсем ясый белми. Институтта рәсем ясарга да, тарих катламнарын актарып иҗат итәргә дә, конструкцияләүгә, проектлауга, әзер балчык эшләнмәсен интерьерга «утыртырга» да өйрәтәләр. Институтка уку урыннарын Россия Мәдәният министрлыгы бүлә һәм урын бүлгәндә яшь белгечләрнең эшкә урнашуы төп күрсәткеч булып тора. Шәхси эшмәкәр яисә үзмәшгульләр булып теркәлсәләр, институт җитәкчелегенә шәкертләренең язмышын күзәтеп бару мөмкин әле. Ләкин бүгенге вәзгыятьтә күбесе керамика буенча эшләми, бөтенләй бүтән һөнәрләр сайларга, мәсәлән, фрилансқа кереп китәргә мәҗбүр. Киләсе елдан Министрлык уку урыннарын тагын да киметәчәк, дип кайгыра Винера ханым. Шулай икән, бик кирәкле, мөһим һөнәрләр юкка чыгарга мөмкин. В.Хамматова күптәннән инде керамика, дизайн, костюм, гамәли бизәү сәнгате һ.б. юнәлешләре берләштергән иҗат йорты кирәклеге турында чаң суга. Ул эшсезлек мәсьәләсен дә хәл итәр, туризмны да җанландырып җибәрер, өстәвенә, яшь осталар да бер-берсе белән аралашып иҗатларын камилләштерер иде. «Безнең буын исән чакта оештырып каласы иде шундый үзәкне, чөнки яшьләрнең бу мәсьәләдә кыл кыймылдатулары бик икеле», – ди Винера ханым. Керамика күп чыгым сорамый. Бина, аренда, салым мәсьәләсе хәл ителгән очракта бу сәнгатьне югары күтәрергә мөмкин дә бит. В.Хамматованың сүзләренә караганда, институтны тәмамлаган яшьләр арасында Париж халкы кызыксынырлык осталар бар.

Чыннан да, бездә балчык сәнгатен үстерү өчен шартлар бик чикле. Бар нәрсә конкурс һәм грантларга кайтып кала. Балчык осталары тарих катламнарын актарып иҗат итсенме, әллә кирпеч калынлыгында грант кәгазьләре тутырсынмы? Грантка кәгазь тутырам дисәң, башта юрист белгечлеге алып чыгу кирәк. Балчык осталарының моңа вакыты бармы? Аларга бүген аренда хакын түләргә кирәк ләбаса!

Бөтендөнья татар конгрессы корылтаена делегат буларак Үзбәкстаннан килгән Фирганә мәдәни-мәгърифәти үзәк җитәкчесе Альбина Кәримова сөйләгәннәрен тыңлаганда барысы да шаккатты. Үзбәкстанда халык сәнгатен үстерү буенча дәүләт дәрәҗәсендә махсус программа тормышка ашырыла. Һәр районда өч-дүрт катлы биналар салганнар һәм теләге булган һәркем шунда килеп балчык әвәләргә,

● Керамика остасы Илгизәр Хәмидуллин.

келәм тукырга, чигәргә, агач уярга, һ.б. төр һөнәрләргә өйрәнергә мөмкин. Мәсәлән, Фирганә өлкәсендә уникe район булса, һәркайсында берәр һөнәрчелек йорты эшли. Шулай итеп эшсезлек мәсьәләсе дә берникадәр хәл ителә, чөнки һөнәрчелеккә өйрәнергә эшләре булмаган авыр хәлдәге кешеләрне җәлеп итәләр. Иҗат йортларының туристик маршрутларга кертелүе акча эшләргә дә мөмкинлек бирә. Атаклы Риштан керамикасына, Бохараның атлас һәм әдрәс үзәкләрендә, Маргилан келәмчеләрендә бәяләр югары булса, һөнәрчелек йортларында юнь генә бәядән сувенир сатып алырга мөмкин. Иң мөһиме, иҗат үзәкләрендә осталар салымнардан азат ителгән. Риштан керамикасын, әйтик, гасырлардан килгән традицияләргә таянып иҗат итсәләр, һөнәрчелек йортларында яшьләр шуннан этәрелеп үз әсәрләрен иҗат итә һәм араларыннан Алишер Нәзиров кебек танылган балчык осталары да чыгарга мөмкин әле.

«Иҗат йортлары булса, мин орнамент осталары белән аралашып үз эшләнмәләремне үзем үк бизәргә дә өйрәнер идем», – дип сүзгә кушыла Алишер Нәзировта осталыгын камилләштереп кайткан Илгизәр Хәмидуллин. Күзләре күрмәсә дә, егет иҗатка ашкынып тора. Әмма Казан буенча эзли китсәң, күзле кешегә дә бер татар орнаменты очрамас. Илгизәр кебекләргә балчык савыт-сабаны бизәкләргә кайда, ничек өйрәнергә соң? Бу уңайдан Әзәрбайҗандагы атаклы келәм музее искә төште. Анда борынгы келәмнәрне, элеккеге технологияләрне торгызу өстенә, сукырлар өчен махсус программа эшләгәннәр, әйтик, бөтен мәгълүмат Брайль шрифтына күчерелгән. Казандагы берәр музейга килеп, экспозициядәге чүлмәкне яисә тәлинкәне кулыңа алып кара син! Хәзер ата каз сыман ысылдап килеп җитәчәкләр. Әзәрбайҗандагы келәм музеенда исә хәтта 2,5 мең еллык тарихы булган атаклы Пазырык келәмнәренең күчермәләрен дә сукырларга күңелләре булганчы тотып, капшап карау мөмкин.

Чүлдән чыгарыйк!

● Керамика остасы Абделвәкил Хәмидуллин.

Республикабызда керамика сәнгате ни хәлдә дигән сорауга җавап итеп тагын бер мисал китермичә мөмкин түгел. Шушы ук очрашуда керамика остасы Абделвәкил Хәмидуллин белән танышу бәхете елмайды. Алтайда дөньяга килгән бу егет ярты Россияне йөреп чыккан. Алтайда сәнгать училищесын, Красноярскида институт тәмамлаган. Беренче һөнәре – дизайн, тагын берсе – керамика. Чиләбедә башта балалар сәнгать мәктәбендә укыткан, аннары ун елдан артык Чиләбе сәнгать училищесында белем биргән һәм шунда ук керамика бүлеге ачкан. Уралны аркылыга-буйга йөреп чыгып, археологлар белән бергә Аркаимда казу эшләрендә катнашкан. Абделвәкилнең бабалары 1930 елларда репрессияләнгән була. Чыгышлары – Мордовиядәге татар авылыннан. Кан тартып, егет Саранскига кайткач, дизайнер булып та эшли, биш еллап милли мәдәният институтында да укыта, Мордовиянең Дубенский районына кергән Ламат авылында яшәгәндә район үзәгендә мәдәният йортында балаларга керамика сәнгатен өйрәтә. Мәдәният башлыгы ярдәмендә шәп остаханә булдыра. Интернетта борынгы чүлмәкче әйләнәсе сызымнарын эзләп табып, аларны камилләштереп, шулар үрнәгендә үзенекен эшли. Шундый зур белем-тәҗрибә туплаган шәхеснең Казаныбызга килеп чыгуы үзе могҗиза. Әмма Абделвәкил бүген шәһәребезнең иң кәттә югары уку йортында укытадыр дип уйлаучылар бик ялгыша. Чыннан да, А.Хәмидуллин бер ел халык һөнәрчелеге техникумында укытып ала, бер курс керамика осталары чыгара. Әмма бездә кешенең кадерен беләләрмени? Бүген Абделвәкил әфәнденең эшен Красноярскида институт тәмамлаган шәкертләре дәвам итә. А.Хәмидуллин исә хәзер Саба районында. Анда ничек барып чыккан, диярсез. Анда Абделвәкилне күн эшләнмәләр остасы дусты Фәрит Вафин чакыра. Район башлыгы белән таныштыра. Районда сувенир сәнгатен үстерү кирәклеген яхшы аңлаган башлык чүлмәкләр остасына иҗат өчен шартлар тудыра. Бүген А.Хәмидуллин район үзәгендә балалар сәнгать мәктәбендә эшли. Мордовиядә буш җирдә остаханә корган кебек, Сабада чүлмәкче әйләнәләре булдырып бала-чага белән мәш килеп яткан чагы. Бу хикәяттә Фәрит Вафин кебек һөнәрчеләрнең бер-берсен кайгыртуы һәм Саба районы башлыгының иртәгәсе көнгә карап яши белүе, мирас калдыру турында уйлавы сөендерсә дә, күңелне һаман бер сорау кимерә. Чиләбе училищесында керамика бүлеге ачкан, үзе үк шуның җитәкчесе булган, Аркаимда казынган А.Хәмидуллинның урыны Татарстан районының нәни генә бер балалар сәнгать үзәгендә булырга тиешме? Шундый дәрәҗәдәге оста ник Казанга сыймаган? Балчык әвәләүче осталар чат саен тезелеп басмаган ләбаса!

Алтайдан ярты Россияне урап туган ягына кайткан Хәмидуллин Сабада да сынатмас, Алласын, мулласын, ата-бабасын онытa барган хәзерге буыннар исә Хәмидуллин кебек осталардан башка асылга ничек кайтыр? Керамика ул – балчык, тәлинкә генә түгел лә, борынгыдан килгән сәнгать. Чүлмәкче божрасы – үзенә бер фәлсәфә. Чүлмәк кенә булса, бүгенге заман психологлары әвәләү ярдәмендә психиканы тынычландыру, балаларның фикерләүләрен үстерү программаларын уйлап тапмас иде.

Нәни генә «Ишморат» остаханәсендә булып узган сөйләшү нинди зур мәсьәләләр күтәрде. Чүлмәк ташка бәрелсә дә, чүлмәк ватыла, таш чүлмәккә бәрелсә дә, чүлмәк ватыла, дигән халык мәкален истә тотып, өрфиядәй нәфис, тиз уалучан сәнгать төрен үткәннәргә таш атучылардан саклау кирәклеге бәхәссез.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

20 август (шимбә). ***Мөхәррәм аеның 22 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 21.49 сәгатьтә калка, 16.26 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.44 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Кычытканлы әрекмән

Үкчә шпорыннан, шулай ук терсәк һәм тезләр сызлаудан котылу өчен, кычытканны иттарткычтан чыгаралар да, әрекмән яфрагының аскы ягына сылап, авырткан җиргә ябалар, полиэтилен белән җылытып, компрессны төнгелеккә калдыралар.

21 август (якшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 23 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 22.22 сәгатьтә калка, 17.25 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.39 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Тын бетү җәфаласа

5 баш сарымсак һәм кабыгы белән, ләкин төшсез 5 лимонны иттарткычтан чыгарып, ярты кило бал кушалар, әледәнәле болгаткалап, 1 атна тоталар, аннан соң суыткычта саклыйлар. Көненә 3 тапкыр, ач карынга, 1 әр чәй кашыгы кабалар. Дәва курсы – 2 ай. Сулыш кысылу туктамаса, 2 атнадан соң кабат дәвалаunion.

22 август (дүшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 24 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 23.08 сәгатьтә калка, 17.52 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.35 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

23 август (сишәмбе). ***Мөхәррәм аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Кысла йолдызлыгында, 18.08 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.30 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Анар сихәте

Анар кабыгын киптереп, ваклыйлар, шуның 2 чәй кашыгын 1 стакан кайнар суда ярты сәгать пешерәләр, сөзәләр, уртлар канаганда, 10 көн рәттән тәүлегенә 2-3 тапкыр чайкыйлар.

24 август (чәршәмбе). Мөхәррәм аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 0.09 сәгатьтә калка, 18.38 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.26 сәгать.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Кул тиресе кытыршыланса

1 әр аш кашыгы бака яфрагы, ромашка, тырнак гөлне 1 стакан кайнар суда 2 сәгать төнәтәләр, сөзеп, 1 аш кашыгы глицерин, 1 чәй кашыгы бал һәм 30 г атланмай кушып болгаталар да, көненә 2-3 тапкыр сөртәләр. Куллар тупасланса, кызарса, 1 чи кишерне уып, 1 аш кашыгы каймак, 1 чәй кашыгы зәйтүн мае кушалар да, кулга сөртеп, кәгазь капчык һәм җылы бәяләй кияләр, 40 минуттан җылы су белән юалар.

25 август (пәнҗешәмбе). ***Мөхәррәм аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 1.22 сәгатьтә калка, 18.59 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.21 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Дегет дәвалый

Уртлар ялкынсынганда, пародонтоз булганда, даруханәдә сатыла торган каен дегете булыша. Ялкынсынган урынга иртән һәм кичен сөрткәч, бераз яндырачак билгеле, әмма 2-3 көннән соң ук авырту басылачак, чөнки дегет микробларны бик тиз үтереп бетерә.

26 август (җомга). ***Мөхәррәм аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 2.40 сәгатьтә калка, 19.13 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.17 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Аджика

200 әр г ачы борыч һәм сарымсак, 2,5 кг помидор, 1 әр кг татлы борыч, кишер һәм алма, 1 стакан үсемлек мае, өчтән ике стакан шикәр, 2 аш кашыгы тоз, 15 әр г петрушка һәм укроп кирәк. Кузаклы ачы борычның орлыгын алмыйлар, ә татлы болгар борычының эчен бушаталар. Алманы дүрткә бүлеп, төшләрен алалар, кабыгын әрчиләр. Помидорларны кайнар суга тыгып алып, кабыгын чистарталар. Татлы борыч, помидор, кишер һәм алманы иттарткычтан чыгаралар, чуен казанга салып, өстен капламыйча, 40-60 минут пешерәләр. Шуннан соң петрушка белән укроп яфракларын, борыч кузакларын һәм сарымсакны иттарткычтан чыгарып өстиләр. Май, шикәр һәм тоз кушып, яхшылап болгаталар, кайнатып чыгаралар һәм сүндерәләр. Стерильләнгән банкаларга тутырып, тимер капкач белән ябалар.

Киңлекләр югалмасын!

Мөхәммәт Мирза – җырлы да, моңлы да Актаныш ягында туып-үскән, халыкның бәгыреннән чыккан әдип. Аның иҗаты – халыкчанлык хисләре белән сугарылган интеллектуаль поэзия. Саллы-саллы поэмалар, тирән фикерле шигырьләр белән бергәттән тарихи-фәлсәфи робагыйлар, газәлләр, гыйбарәләр һәм татар әдәбияты өчен зур яңалык булган, «Адәм баласы» дигән циклга берләшкән бишьюллыклар бу сүзләрне раслый.



М. Мирзаның 1994 елда дөнья күргән «Кәккүк тавышын санадым» дип аталган тәүге шигырь китабының сүз башында Татарстанның халык шагыйре Рөстәм Мингалим: «...шагыйрь киң карашлы – дөнья күләмендә төпле фикер йөртә ала, фикерен ачык итеп, укучыга җиткереп әйтә белә», – дип яза. Каләм иясенең хезмәт юлы да мәдәният, әдәбият белән турыдан-туры бәйле. Аның бигрәк тә Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып эшләгән чоры хәтердә яңара. Нәкъ менә шул вакытта ул татар әдәбиятын рус теленә тәрҗемә итү эшен җанландырды, проза һәм шигърият буенча Казанда, Мәскәүдә күләмле антологияләр басылып чыкты, язучыларыбызның әсәрләре, төрек теленә тәрҗемә ителеп, аерым китаплар булып дөнья күрде... Аның яшь каләм ияләренә хәерхаһлы мөнәсәбәте, остазлыгы бүгенге көндә дә дәвам итә. Бу – М.Мирза башкарган эшләрнең нәтиҗәле бер өлеше.

Каләм иясе – егермегә якын китап, шул исәптән биштомлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Әсәрләре татар, рус, төрек, инглиз телләренә тәрҗемә ителгән. Бу үзе үк алда телгә алынган киң карашлылыктан килә.

Татарстан китап нәшриятында әле яңа гына дөнья күргән «Мәңгелек юлында» дип аталган китабында М.Мирзаның соңгы елларда язылган шигырьләре, поэмалары, «Адәм баласы» циклының дәвамы һәм «Мохтар» шигъри трагедиясе урын алган.

Җан исәп ала ил
Ун елдан ун елга.
Адәм баласының
Юкса бар исәбе
Бер Аллаһ кулында.

Әлеге юлларда шагыйрь хакыйкатьне искәртә, иманга чакыра. Җанисәп нәтиҗәләре милләт файдасына булмаса да, татар дөнья тутырып яшәвен дәвам итә, аның үз тормышы, үз мәшәкатьләре...

Татарстанның йөз еллыгы уңае белән язылган «Мәңгелек юлында» поэма-кыйссасы меңьеллык тарихны колачлый, ә Ерак әбисенә багышланган «Хәбибҗамал» поэмасы кеше язмышларын берләштергән ил һәм милләт язмышын бәян итә.

«Мохтар» – әдәбиятыбызда беренче мәртәбә татар халкының бөек трагик артисты, режиссёр, репрессия корбаны Мохтар Мутин (1886–1941) шәхесен сурәтләгән, аның рухын рәсми рәвештә генә түгел, ә тарихи хакыйкать киңлегендә аклый һәм югары күтәрә торган зур әсәр. Нахакка рәнҗетелгән һәм, кызганыч, инде онытылып бетә язган талантлы, туры сүзле татар улы, бүгенге көн шагыйре М. Мирза әсәреннән соң, күңелләрдә кабат яңарыр дигән өмет бар. Дөрес, шәхесләр күп, ләкин Мутин кебекләр юк, андыйлар һәр халыкка бирәү генә бирелгән.

Эзләрне кар күмә,
Юлларны ком баса...
Адәм баласының
Эзләре югалмас,
Хәтерен җуймаса...

Шагыйрь хак әйтә, безгә мәңгелек юлында хәтерне, милли үзаңны җуймау бик тә кирәк, чөнки гасырлар буе тупланган мирасны, ата-баба ышанып тапшырган әманәтне, туктамыйча, армыйча, ерак-ерак офыкларга алып барасыбыз бар.

Без Кояштан яралганбыз,
Илаһиның нурыннан.
Нур очында мәңгелек сер –
Без мәңгелек юлында,
Без мәңгелек юлында!

М.Мирзаның соңгы еллар иҗаты, данлы тарихны барлау белән бергәттән, иманга кайту, тәүбәгә килү, ахыр чиктә, Аллаһка якынаюга тиң. Иң мөһиме, чиксез мәңгелек юлында халкыбыз ирешкән рухи киңлекләр югалмасын! Шагыйрь үзе дә шул юлда.

Ленар ШӘЕХ.

Хатлар яздым утырып

Өметләр акланмады

Бөтендөнья татар конгрессының 30 еллыгына багышланган корылтай турындагы фикерләрем белән уртаклашырга телим.

Безнең милләтебезнең телен юкка чыгаруга багышлап алып барылган мәкерле сәясәт – мәктәпләрдә балаларга үзебезнең телдә укуларның тыелуы белән без беркайчан да килешә алмабыз. Мәгариф министрлыгы вәкиленең үз чыгышында: «Туган тел дәресләрен хәзерге күләмдә саклап кала алдык, якшәмбе мәктәпләрендә, махсус курсларда татар теле укытыла», – дигән сүзләре сәер тоелды. Туган тел дәресләре хәзерге күләмдә сакланып кала дигән сүзләр нәрсәгә нигезләнеп әйтелгәндер, хәзер туган телдә укулар тыелган вакытта, аны ничек саклап калып була икәнлеге аңлашылмады. Якшәмбе мәктәпләре, андый курсларны оештыручылар, милләт энтузиастлары эше булып, аптыраганнан гына булдырылган гамәлләр бит ул.

Телне саклау стратегиясе турындагы сүзләр күп булса да, анда телне саклап калуга багышланган гамәлләрнең булмавын күреп торабыз.

Корылтайда чыгыш ясаган берничә кешенең генә чыгышын телевизорда күрсәтеп алдылар. Үзбәкстаннан килгән, андагы татар һәм башкорт Аксакаллары шурасы рәисе Рим Гыйниятуллин әфәнде Казанда 700 урам булуы, Кирпичный, Силикатный атамалы сәер исемнәр булуга карамастан, күренекле татар милләтеннән булган шәхесләрнең исемнәре азлыгын телгә алды. «5 млн нан артык татар бар, ә Думада тавышыбыз юк. Мәченең дә үз теле бар, татарныкы юк. Корылтайда татар телен саклау турында закон кабул итәргә кирәк», – диде ул. Анысы кабул ителмәсә дә, Корылтай резолюциясендә бөтенләй татарга кагылышсыз пунктлар бар.

Бездә дә бар ул Аксакаллар шурасы, аның рәисе Рәүф әфәнде Ибраһимов. Корылтайда катнашырга 3 кешенең исемен тәкъдим итеп караса да, бу тәкъдим кабул ителмәде.

Казахстаннан килгән өлкән яшьтәге абзый: «Мактанырга яратабыз, без – эзле халык, дибез. Әйе, элеккеләр эзләрен калдырган, ә без нәрсә калдырабыз, университеты да булмаган нинди татар була инде ул?» – диде. Татарстанның беренче илбашы Минтимер Шәймиев яһүд милләтенең үзенчәлеген өйрәнергә кирәклеген белдерде. Аның: «Үз сүзебезне әйтә алабыз, дин, телебезне саклау безнең кулыбызда», – дигән сүзләре һич ышандырмады. Үз кулыбызда булгач, нишләп татар мәктәпләрен һәм милли университетны бетердек икән?

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов: мәчетләрдә дин дәресләре генә түгел, башка милли үзенчәлекләр, гореф гадәтләребез дә өйрәтелергә тиешлегенә игътибар юнәлтеп, Корылтай эше белән канәгать булып бетә алмавы турында әйтте.

Йомгаклап шуңа басым ясарга телим: бөтен дөньядан килгән милләттәшләребезнең җыелу мәҗлесендә – Корылтайда телебезне саклап калуга багышланган карарлар кабул ителмәс микән дигән өметләребез акланмады.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.
Казан шәһәре.

Бәхетен моңда тапкан

(Мирсәет Сөнгатуллин иҗаты турында уйланулар)

Күренекле җырчыбыз Мирсәет Сөнгатуллинны тәүге тапкыр кайчан һәм нинди залда тыңлаганымны тәгаен әйтә алмасам да, аның табигать биргән, көнләштерерлек төз, мәһабәт гәүдәсе, Ходай Тәгалә һәм ата-анасы иңдергән яңгыравыклы да,ниндидер серле-моңлы да тавышы, бар тамашачыларны иңләгән җылы карашы әсир итүе һаман да хәтер түремдә. Аның белән шәхси танышканчы, олы һәм кече залларда, тантаналы җыелышларда аны шактый тыңларга насыйп булды. Аралашып китүебез исә үзенчәрәк килеп чыкты. Үзе сәхнә тотмаган, минем кебек үк, тамашачы-тыңлаучы буларак кына утырган бер кичәдән соң, яныма килеп, «Тәлгат абый, без бит якташлар», – дип кулын бирде.

Сөйләшеп киттек. Чыннан да без бер төбәк кешеләре икәнбез. Миңа сулыш өргән Кычытканлы авылының иң якын күршесе Әлки вилаятенә кергән Татар Борнае авылында туып-үскән егет икән ул.

Чуаш халкының классик шагыйре Педер Хузангайның Чуаш Борнае авылыннан икәне миңа мәгълүм иде. Шул хакта кызыксынуыма да тулы җавап алынды.

– Әйе, ике Борнай авыллары янәшә тора. Берсендә чуашлар, икенчесендә татарлар яши. Белүемчә, икесе дә бик борынгы. Бер-беребезнең телләрен белеп, гөрләшеп яшибез!

Мирсәет аралашуга җиңел, ачык күңелле кеше булып чыкты. Икенче очрашканда инде күптәнге танышлар кебек, ике куллап күрештек, дуслашып та киттек.

Нәкъ менә шуңа күрә мин аны алтмыш яшьлегемә туган авылыма чакыруга җөрьәт иттем. Ул, кайберәүләр кебек, эрелек касәфәтенә ирек бирмичә, Кычытканлыга килеп, җылы мөнәсәбәте, җырлары белән сөендереп, мәҗлесне күркәм нурда коендырды. Аның беләнме, мөстәкыйль рәвештәме, авылыбызга башка кунаклар белән бергә, күренекле лирик шагыйрә, популяр җырлар авторы Шәмсия Җиһангирова да килгән иде. Иҗат шундый серле могҗиза: атналар, айлар буе кәгазьгә төшерә алмый интегеп йөргән әсәреңне кайчак бер-ике сәгать эчендә язып куясың! Авылыбызны иңләгән инеш, чишмәләр, төрле яктан «колачлаган» урман һәм кешеләре белән танышкан арада, шагыйрәбез «Кычытканлы» исемле әсәрен язып, Мирсәет баянчысы белән икәүләп көен дә язып өлгергәннәр иде. Экспромтның һәммәбезнең күңеленә хуш килүе авылдашларымны, кунакларны таң калдыруы турында әйтеп тә тормыйм. Әле генә «табадан төшкән» җыруын ул вакытта Мирсәет баянга гына кушылып башкарса, соңрак аны оркестрга кушылып җырлагач, моңы аеруча сокландырырлык, туң йөрәкләрне дә «эретерлек» көчкә ия булуы ачыкланды. Ул аны еш башкармаса да, репертуарыннан төшермәгән икән. «Хәзерге акылыбыз» белән тыңлап карап, без әлеге җырның башка татар авылларына багышланган, эфирдан еш яңгыраган әсәрләрдән кайтыш түгел дигән нәтиҗәгә килдек.

Туган авылымда очрашуларда Мирсәет белән икебезнең арасында гасырлар түрендә туган кавемлелек хисләре уртаклыгы тойдым. Ул үзенең аралашуга һәвәс, мөмкин булган тәкъдирдә кайгы-хәсрәтеңне уртаклашуга әзерлеге, вак-төяк гайбәтләргә, буш сөйләшүләргә вакытын сарыф итмичә, эчтән сызланса да, дан-шөһрәт дип даулап йөрмәве һәм гадилеге белән абруй яулый алды дип фаразлыйм. Яшь иҗади көчләргә җәһәт кенә теләкләренә ирешүе, үзләрен раславы җиңел булмавы мәгълүм. Бу табигый хәл мәдәниятебезнең, мәгърифәтебезнең тамырлары ерак-еракларга барып тоташуына һәм аның сыйфат дәрәҗәсен билгеләүче шәхесләребезнең булуына бәйле бер үзенчәлек. Әүвәл мисалны үземә якынрак өлкәдән китерәм. Әйтик, без яшьрәк чакта, Х.Туфан, Ә.Еники, С.Хәким, Г.Бәширов, М.Мәһдиев, А.Гыйләҗевләр янында, сүз сәнгатенең сыйфат дәрәҗәсен алар билгеләгән дәвердә, язма-басма сүзеңне уйланып, «як-якка карanып» кына әйтергә мәҗбүр идең.

Бу хәл сәхнә әһелләре иҗатына да тарала. Мирсәет Сөнгатуллин дигән затның тавышы ачылып кына килгән чорда аңа җыр сәнгате йолдызлары Әлфия Авзалова, Илһам Шакировлар янәшәсендә үзен раславы ай-һай кыен, сират күперен чыгу белән бер икәнен күзаллау кыен булмастыр.

Гөнаһ шомлыгына каршы, Батулла оештырган бер шоуда, И.Шакиров «булып» кыйлануы Мирсәеткә кыйммәткә төште бугай. Тукай исемендәге премиягә тәкъдим ителсә дә, бүләк аңа килеп җитми. Мирсәетнең үсеп җитмәгән мыеклары гына чыланып кала. Чынлыкта бит ул ихтыяҗи халәттә халык күңелен яулаган олуг җырчыларыбызны көндәшләре дип түгел, ә олы юлга алып чыгучы остазлары буларак санады. Чөнки ул үзе дә - элгәрләре шикелле үк, милли сәнгатебезнең үсеше, халык рухына якынаюы өчен җан атып йөрүче шәхесләрнең берсе.

Көчле тавышына әүвәл табигый эчке җылылык җитешмәгәндәй тоелса да, моң дулкыны сине әллә кайларга үз артыннан иярте китә, кешелек сыйфатларыңны баета, бер мизгелгә булса да, дөнья мәшәкатьләрен оныттыра. Җыр кеше йөрәгенә йөрәктән чыгып, тыңлаучыны ихласлык дулкынында коендырганда гына максатына ирешә, диләр. Җыеп кына әйткәндә, аның җырларына салынган моңы тынычландыру, яшәүгә дәрт, мәгънә бирү сәләтенә ия. Чын сәнгать шундый гына булырга тиештер дә.

Нәселдән килгән интеллекты һәм белем дәрәҗәсе Мирсәетне күренекле татар зыялылары белән бер рәткә куя. Аерым алганда, әзерлек курсларын да санаганда, сигез ел данлыклы Казан консерваториясендә белем ала. Табынган остазы-кумиры да күренекле педагог Ишбүләков үзе була. Затлы, югары белеме һәм лирик баритон тавышы, дөнья сүз-җыр сәнгате казанышларына, үзебезнең бай милли мирасыбызга таянуы аның зәвыгын калыплаштыра, шуңар да ул арзанлы, «шырды-бырды» такмакларны репертуарына якын да китерми. Мине күрмиләр, тиешенчә бәяләмиләр, дип уфтанмаган әдәбият-сәнгать әһеле юктыр. Бу юнәлешне сайлаган һәркайсыбызда «амбициозность» булырга тиеш. Ул – иҗади үсешнең бер терәге. Дөрес, М.Сөнгатуллинны бүләкләр, ул теләгәнчә үк булмаса да, «әйләнеп» үтмәде кебек. Ул – Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Россия сәнгать әһелләре арасында уздырыла торган рекордлар бүләгенә ия җырчы. Репертуары бик бай, аның башкаруына, тылсымлы тавышына лаек булып, Мирсәет «канат куйган» меңнән артык җырлары арасында татар, рус һәм башка халыкларның иҗат җимешләрен күрәбез.

Бөтен барлыгын сәнгатькә биреп, шәхси тормышына хилафлык китермәдеме икән дигәнрәк сорауның тууы да табигый. Чынлыкта, бу яктан да борчылырлык түгел, гомер кишәрлегенең кадерен белеп яши икән ул. Турылыклы гомер юлдашы Кадрия ханым белән дус, тату гомер сөреп, мәхәббәт җимешләре – Алмаз исемле улларына да җырчылык сәләтен иңдереп, аны Мәскәүгә һәдия иткәннәр.

Ә Мирсәет озак еллар дәвамында бәхетен татар моңында эзли. Андый фидакарьләрнең «Җаны җырлый», диләр. Шул ук вакытта ул аякларын бөкләп, башын айкап утыручы дәрвиш түгел, аңлавымча, ул дөньялыкка гашыйк романтик. Шәхсән минем өчен аның белән һәр очрашу – «яңа» кешене тану кебек. «Казан утлары» журналының 100 еллыгына багышланган кичәдән дә бергәләшеп, сөйләшә-сөйләшә кайттык. Шагыйрә хатыным Фәүзия җыр текстларының сыйфат дәрәҗәсе, сүз белән көй арасындагы ярашу-ярашмау турындагы сораулары белән Мирсәетнең башын катырса, мин күбрәк көндәлек тормыш низаглары, милли мәнфәгатьләр турында гәпләшүне мәгъкульрәк күреп, аның фикерләү сәләтенең бер үзенчәлегенә – юмор хисе булуына игътибар иттем. Ә ул кешене бизи, авырлыкларны җиңелрәк уздырырга ярдәм итүче сыйфат.

Ошбу аралашуларның «иманасы» да озак көттермәде, ул безгә күпчелек җырларын туплаган дискларын бүләк итте. Вак-төяк кайгы-хәсрәтләр, җитдирәк мәсьәләләр «бугазга килеп терәлгәндә «Мирсәетне куеп», кайгы-хәсрәтемне, сөенечемне аның белән уртаклашкандай булам. Шул мизгелләрдә без китсәк тә, җыр, моң кала, алар – мәңгелек дип тынычланам.

Минем «үзешчән» уемча, Мирсәет – халкыбызның әлегә тиешле бәясен алмаган олуг сәнгатькярләребезнең берсе. Артистлар белән язучылар, аларның иҗаты үзебезнең генә милли мөлкәтебез, байлыгыбыз. Җир асты, җир өсте нигъмәтләребез кемнәр беләндер уртак яисә бөтенләй безнеке түгел. Шуңа күрә әлеге рухи вә рухани, иҗади байлыгыбызга игътибарлырак булыйк.

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН.

Шикәр акылны зәгыйфьләтә

Лондон Империя колледжы галимнәре канда шикәр микъдары күп булу хәтта икенче тип диабеттан интекмәүчеләрнең дә акылын зәгыйфьләндерүгә булышуын ачыклаган. Тикшеренү 2002 елдан бирле алып барылган. Галимнәр ун ел дәвамында 50 яшьтән өлкәнрәк 5189 кешенең сәламәтлеген күзәткән. Аларның когнитив (танып белү – игътибар, сөйләм, интеллект, хәтер) сәләтләрен бәяләгәннәр һәм кандагы шикәрнең озак вакыт эчендәге уртача концентрациясе турында мәгълүмат бирә торган HbA1c гликогемоглобины микъдарын контрольдә тотканнар. Картая барган саен, сынауда катнашучыларның барысының да когнитив сәләтләре кимегән, әмма каннарында гликогемоглобин микъдары югары булганнарның акыл сәләте һәм хәтере тагын да начаррак булган. Икенче тип диабетның Альцгеймер авыруына китерү ихтималы зур икәне тикшерүчеләргә инде мәгълүм булган, әмма нейродегенератив чирләрнең турыдан-туры кандагы шикәр микъдарына бәйле булуы әле беренче тапкыр дәлилләнгән. Икенче тип шикәр чире булганда, тукымаларның инсулинга сизгерлеге кимү нәтиҗәсендә канда глюкоза арту күзәтелә. Ул симерүдән интегүчеләрдә башланырга яки нәселдән килергә мөмкин. Дәвалауның бер ысулы – шикәрсез диярлек диета.

(“Science Alert”).

Эзсез югалган

1908 елның 17 июнендә Ташасты Тунгускасы елгасы янында башта утлы шар очкан, ул 7-10 чакрым биеклектә 40-50 мегатонна куәт белән шартлаган, аннары 5 сәгать буе магнит давылы котырган. Шартлау 2100 квадрат километр мәйдандагы бөтен агачны еккан, 200 чакрымлы радиустагы бөтен тәрәзә пыяласы ватылган, тавышы исә 800 чакрымгача ишетелгән. Әмма метеорит үзе табылмаган. Ул төшкән урынны да 20 елдан соң гына чамалаганнар. Шунлыктан хәзергә кадәр, Тунгус метеориты булганмы соң ул, дигән сорауга җавап табылмаган. Төрле фаразлар китерелә: чит планетадан килүчеләрнең космик корабле шартлаудан алып үтә яшерен яңа энергетик коралны сынауга кадәр, әмма аларның берсен дә фән дәлилли алмый.

(“Die Presse”).

Ниһаять, фотолы булган!

Бик биек агачларны тулысынча фотога төшереп булмый, чөнки буйлары объективка сыймый . “Президент” исә – биекләр янында да гигант агач. Әлеге алып секвойяның биеклеге 76 метр чамасы, үзенә 3200 яшь! Кәүсәсенең диаметры 8 метрга тәңгәл, куәтле ябалдашында исә ике миллиардлап энә бар – планетада башка бер генә агач та аның белән тиңләшә алмый. Ул әле һаман елына бер кубометрга үсә һәм секвойяның дөньяда иң тиз үсә торган агач булуын дәлилли. “Президент” һәм аннан бераз тәбәнәгрәк “Ак йорт” белән “Сенат” кебек гигантлар Калифорниядәге Сьерра-Неваданың көнбатыш итәгендә генә, диңгез өсте тигезлегеннән берничә мең метр биеклектә үсә. National Geographic телеканалының төшерү төркеме исә “Президент”ның фотосын ясаган. Агачны 32 көн буе өлешләргә бүлеп төшергәннәр дә, соңыннан барлык 126 фотосурәтне тоташтырганнар – гаҗәеп секвойяның менә дигән фотопортреты килеп чыккан.

(“Interesnik.com”).

83 яшендә Тын океан кичкән

Япониядә 83 яшьлек яхтсмен Кэнити Хория бер дә туктамыйча һәм берьялгызы Тын океанны кичкән дөньяда иң карт кеше булып танылган. Быел 27 мартта ул Американың Сан-Франциско шәһәре портыннан чыгып киткән һәм Кояш панельләре куелган алты метрлы Suntory Mermaid III яхтасында 8,5 мең километр ара үтеп, Хонсю һәм Сикоку

утраулары арасындагы Кии бугазына барып җиткән. Әлеге сәяхәтен ул инде икенче тапкыр кабатлаган – 1962 елда, 23 яшендә, Кэнити портларга кермичә Тын океанны 90 көндә берьялгызы кичкән беренче яхтсмен булып рекорд куйган. Хәзер шул ук юлны кирегә таба үткән. Кыю Кэнити әле үзенә йөз яшь тулганчы яңадан-яңа сәяхәтләргә чыгарга әзер булуын белдергән.

(“Kyodo”).

Сыңар күперсез ...Амазонка

Амазонка - дөньяда иң мул сулы елга. Биредә иң экзотик балыклар яши, ерткыч пираньяларның гына да 60 лап төре бар! Амазонкада төче сулыкта яши торган дельфиннар да күп. Әмма аның башка барлык елгалардан аерып тора торган үзенчәлеге – бер күпер дә булмау. Ул өч ил – Перу, Колумбия, Бразилия аша ага, бассейнында 30 миллионнан артык кеше яши, шуңа аның аша бер генә күпер дә салынмавы бик гаҗәп. Мәсәлән, Нил аша Каһирәдә генә дә тугыз күпер салынган. Иделдә хәзер 53 күпер бар (элек тагын да күбрәк булган, шактые җимерелгән). Азиянең төп елгасы Янцзы аша соңгы 30 елда гына да 100дән артык күпер төзелгән. Европадагы Дунайда 113 күпер бар. Цюрихтагы Швейцария технология институты галиме Вальтер Кауфман фикеренчә, күпер булмауның сәбәбе бик гади – аңа зарурлык юк. Амазонка ярларында яшәүчеләр аны йә паромда, йә көймәдә кичә, кирәкле товарларны да шулай күчерәләр. Кауфман әйтүенчә, биредә күпер төзү өчен табигать каршылыкларын җиңәргә туры килер иде. Мәсәлән, ярдагы зур сазлыклар һәм йомшак туфрак бик озын виадуклар һәм бик тирән фундамент таләп итәр, бу исә зур чыгымнар сорар иде. Елгадагы су күләме дә бик төрле. Коры сезонда Амазонканың киңлеге 3-10 чакрым булса, яңгырлар яуганда 48 чакрымга җитәргә мөмкин, шунлыктан йөзмә конструкцияләр, понтоннар да куеп булмый. 2019 елда Бразилия президенты Жаир Болсонару елга аша күпер салырга вәгъдә биргән, әмма бу буш сүз генә булып калган. Икътисади яктан файдасыз булганга, күперләр киләчәктә дә төзелмәстәр кебек тоела.

(“Популярная наука”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

22 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00, 23.30 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
17.00 «Татарлар». 12+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+
0.20 «Соотечественники». 12+
0.45 «Каравай».

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Зөлфәт турында телеочерк. 6+
15.30 «Ватандашлар». Ренат Акчуринның йөрәкле командасы. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
19.20 «Бердәм булыйк». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.25, 21.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Бог Войны. История отечественной артиллерии». 12+
16.30 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГОДУНОВ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Война и мир великого князя».
7.30 «Первые в мире».
7.45 Легенды мирового кино. Григорий Александров.
8.15 «ВЕСНА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Антонио Ринальди. Ораниенбаум: дворец Петра III, Китайский дворец, павильон Катальной горки.
10.45 Academia. Вячеслав Иванов. «Индоевропейские языки и миграции индоевропейцев».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 95 лет со дня рождения Ирины Скобцевой. Линия жизни.
13.15, 21.25 «СЕРЕЖА».
14.30 «Его Голгофа. Николай Вавилов».
15.05 Моя любовь - Россия! «Рязанские напевы».
15.40 «Наталия Дудинская. Богиня танца».
16.20 Музыкальные фестивали России. Международный фестиваль «Музыкальный Олимп».
17.10, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
19.00 «Секреты живой клетки».
19.45 Письма из провинции. Мурманская область.
20.20 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 Острова. Георгий Данелия.
22.45 Цвет времени. Павел Федотов.
23.00 «Рассекреченная история».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
0.00 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

23 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
23.50 «Видеоспорт». 12+
0.15 «Соотечественники». 12+
0.40 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Родная земля». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Нур сибелгәндә». Дания Нуруллина турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
19.20 «Бердәм булыйк». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+
10.30 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Бог Войны. История отечественной артиллерии». 12+
16.15 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
21.00 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГОДУНОВ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Храбрый воин Мачупан».
7.30 «Первые в мире».
7.45 Легенды мирового кино.
8.15 «ПИРОГОВ».
9.45 Цвет времени. Василий Кандинский. «Желтый звук».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчие Джованни Фонтана, Иоганн Шедель, Гаральд Боссе, Людвиг Бонштедт. Ораниенбаум. Большой дворец.
10.45 Academia. Вячеслав Иванов. «Макросемьи языков и расселение человека из Африки».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 Острова. Василий Шукшин.
13.10, 21.15 «ДВА ФЕДОРА».
14.40 Цвет времени. Леон Бакст.
15.05 Моя любовь - Россия! «В мире уральских сказов».
15.40 «Честь мундира».
16.25 Музыкальные фестивали России. Московский международный фестиваль «Виртуозы гитары». Дмитрий Илларионов, Гайк Казазян, Михаил Татарников и ГАСО им. Е.Ф.Светланова.
17.00, 22.45 Цвет времени. Леонид Пастернак.
17.10, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
18.45 «Забытое ремесло».
19.00 «Секреты живой клетки».
19.45 Письма из провинции. Енисейск (Красноярский край).
20.20 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 Острова. Марлен Хуциев.
23.00 «Танковый Армагеддон».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
0.00 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

24 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Булат Гыйльванов турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
19.20 «Бердәм булыйк». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+
10.30, 21.00 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ТОЧКА ВЗРЫВА». 16+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Бог Войны. История отечественной артиллерии». 12+
16.15 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГОДУНОВ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Беспечный соловей».
7.30 «Первые в мире».
7.45 Легенды мирового кино.
8.15 «ПРИНЦ И НИЩИЙ».
9.40 Цвет времени. Караваджо.
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Чарльз Камерон. Павловский дворец.
10.45 Academia. Вячеслав Иванов. «Этрусский язык: лингвистика, археология, история».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 Острова. Олег Даль.
13.00, 21.15 «ЖЕНЯ, ЖЕНЕЧКА И «катюша».
14.20 «Григорий Пономаренко. Я обязательно вернусь...»
15.05 Моя любовь - Россия! «Псковская земля бога Пеко».
15.40 «История Преображенского полка, или Железная стена».
16.25 Музыкальные фестивали России. Международный виолончельный фестиваль Vivacello. Альбан Герхардт, Олег Каэтани и Российский национальный оркестр.
17.10, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
19.00 «Секреты живой клетки».
19.45 Письма из провинции.
20.20 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 Острова. Владимир Мотыль.
22.40 Цвет времени. Валентин Серов.
23.00 «Рассекреченная история».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА». 16+
21.40 «РИКОШЕТ». 16+
0.00 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

25 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00, 0.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+
0.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Әлфия Авзалова турында телеочерк. 6+
15.30 «Ватандашлар». Муса Җәлил. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
19.20 «Бердәм булыйк». 6+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+
10.30, 21.00 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ТОЧКА ВЗРЫВА». 16+
14.35 «Реки России». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Бог Войны. История отечественной артиллерии». 12+

16.15 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГОДУНОВ». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Ноктюрн о любви».
7.30, 14.45, 23.10 «Первые в мире».
7.45 Легенды мирового кино.
8.15 «ЖУКОВСКИЙ».
9.45 Цвет времени. Валентин Серов.
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Бартоломео Растрелли. Царское Село. Екатерининский дворец.
10.45 Academia. Вячеслав Иванов. «Языки большого города в истории человечества».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 «Зеркало» для режиссёра».
13.00, 21.25 «ЗЕРКАЛО».
15.05 Моя любовь - Россия! «О чем мечтают абазины?»
15.40 «История Семеновского полка, или Небываемое бываетъ».
16.25 Музыкальные фестивали России. Международный фестиваль Мстислава Ростроповича. Лоренц Настурика-Гершовичи и Камерный оркестр Мюнхенской филармонии.
17.10, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
18.50 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
19.00 «Секреты живой клетки».
19.45 Письма из провинции.
20.20 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 Юбилей Маргариты Тереховой. Линия жизни.

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА». 16+
21.40 «РИКОШЕТ». 16+
0.00 «ПЁС». 16+

Җомга

26 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 Хоккей. «Салават Юлаев» - «Нефтехимик». 6+
15.30 «Бердәм булыйк». 6+
15.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Локомотив». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+
0.00 «ЛЕКЦИИ ДЛЯ ДОМОХОЗЯЕК». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Муза... Музыка... Мозаффаров...» Мансур Мозаффаров турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.45 «Бердәм булыйк». 6+
0.40 Спектакль «Урланган бәхет». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+
10.30, 21.00 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПРИВЕТ, ДЖУЛИ». 16+
14.30 «Реки России». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Неизвестный COVID. Постковидный синдром». 12+
16.20 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Бенефис Любови Успенской на фестивале «Белые ночи Санкт-Петербурга». 12+
23.45 «Охотник за головами. В объективе - звёзды». 16+
0.45 «Ирина Скобцева. Мы уже никогда не расстанемся...» 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «МАЙОР ГРОМ. ЧУМНОЙ ДОКТОР». 12+
23.55 «ВТОРЖЕНИЕ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Звезда с Востока».
7.30 «Первые в мире».
7.45 Легенды мирового кино.
8.15, 23.50 «СКАЗАНИЕ О ЗЕМЛЕ СИБИРСКОЙ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.20 Спектакль «Маскарад».
12.55 «Ярославль. Замок Никиты Понизовкина».
13.25, 21.25 «РОЗЫГРЫШ».
15.05 Моя любовь - Россия! «Лики невьянской иконы».
15.40 Музыкальные фестивали России. Международный фестиваль искусств П.И. Чайковского в Клину. Денис Мацуев, Юрий Башмет и Камерный ансамбль «Солисты Москвы».
17.00 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Цвет времени. Василий Кандинский. «Желтый звук».
20.25 «Монологи кинорежиссера. Владимир Меньшов».
23.00 «Запечатленное время».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА». 16+
21.40 «РИКОШЕТ». 16+
23.40 «КОНЕЦ СВЕТА». 16+

Шимбә

27 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Бәллүр каләм - Хрустальное перо-2022».
15.30 «Синең өчен». Зәйнәб Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов концерты,. 6+
16.30 «Бердәм булыйк». 6+
17.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Нефтехимик». 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «ЗАМЕРЗШАЯ ИЗ МАЙЯМИ». 16+
0.35 «КЕКС В БОЛЬШОМ ГОРОДЕ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Җан авазы - шифалы моң». Миңгол Галиев турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
16.55 «Бердәм булыйк». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе. 6+
23.10 Спектакль «Яшь йөрәкләр». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Биосфера. Законы жизни». 12+
5.30 «Карамзин. Проверка временем». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Путеводитель по вселенной». 12+
8.30 «Реки России». 12+
8.55 «ТРИ ЛАНИ НА АЛМАЗНОЙ ТРОПЕ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ОФЕЛИЯ». 16+
15.00 «Звезда и смерть графа Вронского. Сербский гамбит». 12+
15.45 «ДВЕ ЖЕНЫ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БИТВА ЗА ЗЕМЛЮ». 16+
23.00 «КОГДА ЗОВЕТ СЕРДЦЕ 5». 16+
0.30 «МАМА НАПРОКАТ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10, 12.15 «Видели видео?»
13.00 Ко дню рождения Маргариты Тереховой. «Одна в Зазеркалье». 12+
14.05 «СОБАКА НА СЕНЕ».
16.35 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ПОСЛЕДНИЙ ШТУРМ». 12+
18.20 «Азов» головного мозга». 16+
19.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Свои». 16+
22.45 «ГУДБАЙ, АМЕРИКА». 12+
0.45 «Наедине со всеми». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ЗА СЧАСТЬЕМ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «КОГДА МЕНЯ НЕ СТАНЕТ». 12+
0.50 «СЛЁЗЫ НА ПОДУШКЕ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.00 Мультфильмы.
7.55 «ТАЙНА «Черных дроздов».
9.30 «Обыкновенный концерт».
10.00 «Передвижники. Абрам Архипов».
10.25 «ЧАЙКА».
12.25 Черные дыры. Белые пятна.
13.10 Диалоги о животных.
13.55 Легендарные спектакли Большого. Владимир Васильев, Людмила Семеняка, Борис Акимов в балете С.Прокофьева «Иван Грозный».
15.45 Линия жизни. Людмила Семеняка.
16.45 «Энциклопедия загадок».
17.15 «ДОБРЯКИ».
18.35 Искатели. «По следам сокровищ Кисы Воробьянинова».
19.20 К 100-летию Российского джаза. Линия жизни. Даниил Крамер.
20.15 «Здравствуйте, я ваша тетя!» Как сюда попала эта леди?»
20.55 «ЗДРАВСТВУЙТЕ, Я ВАША ТЕТЯ!»
22.40 «Кинескоп». «Художники по костюмам».
23.20 «ВЕСНА».

«НТВ»
4.45 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Восхождение».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.15 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «КАПИТАН ГОЛЛИВУД». 12+
23.20 «Международная пилорама». 16+
0.10 «Основано на реальных событиях». 16+

Якшәмбе

28 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 16+
6.00 «Гомерләр бик сизгер икән». Ринат Мөслимов концерты. 6+
8.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Туган авылым». 6+
8.45 «Эти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Синең өчен». Зәйнәб Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.00 Хоккей. «Локомотив» - «Салават Юлаев». 6+
15.45 «Бердәм булыйк». 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Батырлар». 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ». 12+
0.30 «Галапагосы. На краю земли». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Мин бу җирне матурларга тудым». Әнгам Атнабаев иҗатына багышланган кичә. 6+
9.15 «Йөрәктән-йөрәккә». Алсу Тимергалина турында телеочерк. 6+
10.15 «Туган авылым». 6+
10.30 «Калеб». 6+
10.55 «Бердәм булыйк». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Бәллүр каләм - Хрустальное перо-2022». 6+
14.45 Спектакль «Яшь йөрәкләр».
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты. 6+
23.10 «Шаян хәлләр». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Биосфера. Законы жизни». 12+
5.30 «Карамзин. Проверка временем». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Звезда и смерть графа Вронского. Сербский гамбит». 12+
8.45 «ДВЕ ЖЕНЫ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БИТВА ЗА ЗЕМЛЮ». 16+
14.55 «Путеводитель по вселенной». 12+
15.25 «Реки России». 12+
15.55 «ТРИ ЛАНИ НА АЛМАЗНОЙ ТРОПЕ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОФЕЛИЯ». 16+
23.00 «АВГУСТ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
4.35, 6.10 «СОБАКА НА СЕНЕ».
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь как кино». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
14.05 «Елена Цыплакова. Лучший доктор - любовь». 12+
15.10 «ШКОЛЬНЫЙ ВАЛЬС». 12+
17.00, 18.20 «Михаил Танич. Не забывай». 16+
19.00. 16+
21.00 «Время».
22.35 «КОРОЛЬ НЕЛЕГАЛОВ». 12+
0.30 «Наедине со всеми». 16+

«РОССИЯ»
5.35 «ЧУЖИЕ ДЕТИ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Большие перемены».
12.35 «ЗА СЧАСТЬЕМ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.00 Мультфильмы.
8.10 «НОС».
9.50 «Обыкновенный концерт».
10.20 «ДОБРОЕ УТРО».
11.45 Острова. Татьяна Конюхова.
12.30 Диалоги о животных.
13.10 «Глобальные ценности».
14.20 «Жизнь и путешествия Миклухо-Маклая».
15.10 «Тихо, граждане! Чапай думать будет!»
15.50 «ЧАПАЕВ».
17.25 «Турпутёвка на Луну».
18.05 «Успенский собор. Моздок».
18.35 «Анкета Российской империи».
19.20 «Романтика романса».
20.15 «ТАЙНА «Черных дроздов».
21.50 Большая опера.
23.35 «ДОБРЯКИ».

«НТВ»
5.10 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
6.45 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
10.55 «Чудо техники». 12+
11.50 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Звезды сошлись». 16+
22.00 «Союз чемпионов». 6+
0.10 «БИТВА». 6+

Саклык кенәгәсе, банк карталары булмаган кеше сирәк хәзер. Чөнки акчаны банкта саклау уңайлы. Ләкин андагы байлыкның юкка чыгу очраклары да булгалый. Замана караклары төрле ысуллар куллана.

БАНКТАГЫ БАЙЛЫК ЙОЗАКТАМЫ?

Бөгелмәдә яшәүче өлкән яшьтәге Венир агай Вәлиевнең пенсиясе Россия саклык банкына килә. 2016 елның март аенда ул чакта 73 яшендәге абзый Ленин урамындагы офиска килеп, хәзинәсендә күпме байлык булуын барларга уйлый. Аңа Сергей атлы менеджер хезмәт күрсәтә, өч «пенсионный депозит»ында җәмгысы 635 685 сум акчасы җыелуын белдерә, клиентның рөхсәте белән аларны бер счетка туплап, яңа кенәгә бирә. Шул рәвешле, В.Вәлиев алты ел буе саклык банкына йөри, ләкин анда күпме акчасы булу белән кызыксынмый, исәп-хисапны, туганнары әйтмешли, «картларча», ягъни кәгазьгә язып алып бара. Бары тик быел март аенда ялгызак карт банктагы акча күләмен белергә ниятли һәм офиста аның күпмегә арту мәсьәләсен күтәрә. Бу юлы хатын-кыз оператор аңа барысын да җентекләп аңлата да өлкән агайны аптырашта калдыра. Иң беренче чиратта, В.Вәлиев исемендә нибары 249 мең сум булуы, анысының да кенәгәдә түгел, ә банкомат картасында икәне әйтелгәч гаҗәпкә кала ул. Чөнки аның гомер бакый банкомат картасы алганы, димәк, ошбу җайланмадан файдаланганы юк бит, ә монда акчаның төгәл алты ел элек, димәк ки, ул Сергей дигән менеджерга мөрәҗәгать иткән чорда банкомат аша күчерелүен әйтеп торалар. Барлыгы 350 200 сум акча чәлдерелүе аңлашыла. Әлбәттә, күп еллар буе җыйган байлыгы юкка чыгу абзыйны тетрәндерә. Искәртеп үтик, РФ Саклык банкы клиентка китерелгән матди зыянны кайтара. Бу угры фаш ителеп, аның ул чакта банк хезмәткәре булган зат икәне ачыклангач, соңрак башкарыла, билгеле.

Банкның хәвефсезлек хезмәтенә дә мәшәкать чыга. Иң әүвәл, 1942 елгы В.Вәлиев исеменә банкомат картасы каян килгән дигән сорауга җавап бирергә туры килә. Тикшерә башлагач та, без югарыда телгә алган Сергей Рощупкинга шик төшә. Чөнки 2016 елның 21 мартында абзыйны ул кабул иткән, банк картасын да шушы кеше хәзерләгән, ә В.Вәлиев исеменнән куелган имзаларның ясалма икәне дә күренеп тора. Соңгысын экспертиза раслый. Бу инде әлеге карта белән С.Рощупкин эш иткән дигән сүз. Ул гына да түгел, бу шома егет шул ук 2016 елның февраль-март айларында өлкән яшьтәге җиде кешенең имзаларын сырлап, акчаларын урлап фаш ителгән була. Полиция тикшерүчеләре ул вакытта аның барлыгы 251 781сум акча урлавын дәлиллиләр, әмма В.Вәлиев кесәсенә керү очраклары күләгәдә кала, чөнки агай бу хакта белми әле. Нәтиҗәдә, Бөгелмә шәһәр суды җиде кешене талаган банк хезмәткәрен мошенниклыкта гаепле дип таба һәм тәүбә итүен танып, матди зыянны кайтаруын исәпкә алып, ике еллык шартлы срок белән калдыра. Әлбәттә, әлеге җинаять эше кузгатылу белән эштән чыгарыла ул.

Банкның хәвефсезлек хезмәте хокук саклау органнарына чынлыкта Рощупкинның гаебен энәсеннән җебенә чаклы дәлилләп бирә. Шуңа күрә, тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Айдар Еникеевка биргән беренче күрсәтмәләрендә В.Вәлиевкә банкомат картасы әзерләп биргәнмендер бәлки, әмма бу аның счетыннан акча урлауны белдерми дип, гаебен кире кага, әмма тиздән моның файдасыз икәнен аңлый, барысын да сөйләп бирә, суд башланганчы, саклык банкына китерелгән матди зыянны кайтарырга вәгъдә итә, урланган 350 200 сумны Ришат исемле абзасын җирләргә һәм үз кирәгенә тотуын белдерә.

В.Вәлиевнең банк реквизитлары һәм башка шәхси мәгълүматлары билгеле булгач, эш урынындагы мөмкинлекләрдән файдаланып, аның саклык кенәгәсенә «бәйләнгән» банкомат картасы эшләү зур тырышлык сорамый. Имзаларны тикшереп йөрүче дә булмый. Шулай итеп ун көн эчендә сберкнижка счетындагы 600 000 сум банкомат картасына күчерелә, хуҗага 35 мең сум калдырыла. Банкоматларда кәгазь акчага әйләндерелеп кесәгә кергән һәм хәтта телефонына күчерелгән 200 тәңкә акча 350 200 сумга җиткәч, чираттагы 100 000не алам дигәндә банкоматтагы счет билгесез сәбәпләр аркасында йозакка бикләнә, ягъни акча сыгу мөмкинлеге бетә. Картаны ташларга туры килә. А.И. Еникеев угрыга 600 мең сумны урлауда гаепләү белдерә.

Хөкем утырышлары Венир агайдан башка гына уза. Чөнки шушы хәлләргә кадәр әйбәт кенә йөреп торган ялгызак карт апрель азагында 79 яшендә кинәт вафат була. Зарар күрүче итеп мәрхүмнең бертуган апасының кызы билгеләнә. Әгәр бабай исән булса, судта нык торыр, үзенә мәшәкать вә зур борчулар чыгарган оятсыз егеткә кырыс җәза таләп иткән булыр иде кебек. Ләкин безнең законнар икътисади җинаять кылучыларга, ягъни угры-бурларга карата бик мәрхәмәтле. Бу юлы да Бөгелмә шәһәр суды Сбербанкка китерелгән зыянны каплап өлгергән 30 яшьлек С.Рощупкинны 3 еллык шартлы хөкем белән калдыра.

Банк хезмәткәрләренең фаш ителү мөмкинлеге зур булган мондый угрылыкка баруы сирәк хәл. Читтән торып кесәгә керү очраклары башлыча хуҗалар саксызлыгы яисә беркатлылыгы аркасында килеп чыга. Буа районындагы мисал зур акчалар чәлдерү турында түгел, ә бәлки укучы малайның заманча алымнар кулланып, чит кеше картасын «чистартуы» турында.

Тәтеш якларында яшәүче Халисә Габдуллина (кайбер исемнәр үзгәртелә) 15 февральдә банк счетыннан 118, 119 һәм 72 сум акча чигерелүе турында өч смс хәбәр ала. Анда «Garena» интернет кибете дигән һәм инглиз телендәге башка язмаларны күрә, әмма бай кеше булмаса да, моңа игътибар биреп тормый, әйтүенчә, ялгыш җибәрелгән дип уйлый. Ә менә ун көннән соң Буа районындагы бер авылда дусты Алиядә кунакта чакта бер-бер артлы шундый ук эчтәлекле 14 хәбәр килеп, күчерелгән акча күләме биш мең сумнан артып китеп, балансота 5 тәңкә дә 44 тиен байлык калгач шөбһәгә төшә.

Бу галәмәтне өйдәгеләр генә түгел, Саклык банкының Буадагы офисында да юньләп аңлата алмыйлар, банкомат счетын бикләп куялар да нинди дә булса мәгълүмат алынса, хәбәр җибәрергә вәгъдә итәләр.

Халисә Буа Эчке эшләр бүлегенә ике айдан соң гына бара. Әлбәттә, анда ошбу хилафлыкның хатын-кызның үз тирәсендәге кешеләр эше икәнен чамалыйлар, банк картасын кемнәргә биреп торуын белешәләр. Х.Габдуллина 25 февральдә, ягъни 14 смс хәбәр килгән көнне кунакта чакта хуҗабикәнең 8 нче сыйныфта укучы малае Денисны кибеткә җибәрүен исенә төшерә.

Бу инде мәктәп абруена да тап төште дигән сүз була. Шул көнне үк анда ике полиция хезмәткәре килеп керә, директор кабинетында малайның телефоны алынып, беркетмә төзелә. Денис укытучылары алдында мәсьәләгә ачыклык кертә, беренче өч очракны телгә алмаса да, 14 смс хәбәрнең кайдан килүен сөйләп бирә, димәк, угрылык кылуын да таный. Әгәр әлеге заманча бурлык бернichә ай алданрак кылынса, эш зурга китмәс тә иде, әмма 14 яшен тутырып өлгергән үсмергә карата җинаять эше кузгатыла.

Бактың исә караклык 25 февральдә шук малайны банк картасы тоттырып кибеткә җибәрү белән бәйле түгел икән, чөнки картаны кухнялары өстәлендә күреп, ун көн элек үк телефонына фотога төшереп алган була ул. Әйтергә кирәк, авыл малае әлеге мөмкинлекне тәмәке, хәмер ише ярамаган әйберләр алу өчен файдаланмый, ә бәлки телефонында түләүле уен уйный, акчаны телефон аша реквизитлары билгеле булган банк картасыннан интернет кибеткә җибәрә, ике көндә 5405 сум акча күчерә.

Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Айрат Мөхәммәдуллин әлеге «уен»га банк счетыннан урлап, кешегә зур күләмдә матди зыян китерү дигән рәсми бәя бирә.

Зарар күрүче угры малайга законлы җәза бирүне сорый. Гариза язган кеше башкача әйтә дә алмый. Әмма судта ул хөкем ителүчене җәзасыз калдырырга теләвен дә белдерергә мөмкин. Чөнки улын ялгызы тәрбияләүче ханым матди зыянны кайтара. Ләкин якларның килешүе сәбәпле дигән билгеләмә белән җинаять эзәрлекләве туктатылган очракта да, быел 9 нчы сыйныфка барырга тиешле укучы хөкем ителгән зат булып саналачак.

Наил ВАХИТОВ.

14 яшеннән алтын-көмеш дөньясында

«Минем әнием дә, әтием дә – спортсменнар, – диде ювелир Данил Рәшитов. – Әтием Дамир Рәшитов тимераякта парлы шуу буенча спорт мастеры, заманында РСФСР-ның парлы шуу буенча җыелма командасы составында да булган. Ә әнием Алсу Рәшитова – тимераякта шуу спорты буенча спорт мастеры, дәвалау физкультурасы табибәсе.

Мин кечкенәдән иҗатка гына тартылдым. Дәү әтием Надыр аяк киеме төзекләндерү остасы иде. Мине ул балачакта ук металл чокып төрле нәрсәләр ясарга өйрәтте. Мәктәптә укыганда ук калын ир-ат балдагы ясадым. Яхшы килеп чыккач, андый балдакларны дус-ишләремә дә ясап бирдем, мәктәп ярминкәләрендә дә саттым. 1999 елны Казанның 4 нче сынлы сәнгать мәктәбен тәмамладым. Миңа хәзер 35 яшь. Быел октябрь аенда кечкенә юбилеемны – ювелирлык өлкәсендә 20 ел хезмәт куюымны бәйрәм итәчәкмен. Әтиемә рәхмәт. Ювелирлык сәнгатенә маһирлыгымны күргәч, ул мине 2002 елда, 14 яшемдә, мәгълүм татар ювелиры Илгиз Фазылҗанов остаханәсенә алып барды, шушында барысына да төшенерсең, барысына да өйрәнерсең, диде.

Ике сәгатьлек әңгәмә вакытында Илгиз Фәрит улы миңа сынлы сәнгатькә укыган бар белемнәремнән дә артык гыйлем бирде. Ул мине үзенә эшкә алды. Ювелир-модельер вазифаларын үтәп, мин көн саен яңа эскизлар ижат итеп килергә тиеш идем. Аннары балавыздан модельләр уйдым. Әгәр дә эскизлар булмаса, ул мине остаханәгә кертми иде.

Укытучым үзе бик тырыш, бик эшчән булу сәбәпле, башкалардан да шуны таләп итте. Коллективта – 15-20 оста, тагын ике менеджер эшләгәндер ул чакта, 2003 елда җитәкчебез Мәскәүгә күченде. Мин исә остаханәдә эшләп калдым. 2005-2012 елларда ювелир Фидель Уралский белән «Алмаз-Холдинг» заводында хезмәт куйдым (хәзер дә шунда эшеме дәвам итәм). Әмма мин укытучым Илгиз Фазылҗановны беркайчан да онытмыйм! Ул – гаҗәеп талант иясе!»

Д.Рәшитов практик осталыгын теоретик яктан да ныгыткан: Казан дәүләт мәдәният институтының «Декоратив-гамәли сәнгать» факультетында белем алган. Параллель рәвештә Казан халык һөнәрчелеге техникумында да ювелирлыкка укыган. «Үзле балчыктан күләмле сәнгать әйберләре ясарга өйрәнү ювелирлык өлкәсе өчен дә кирәк иде.

2012 елдан башлап, шәхси эшмәкәр буларак, үз остаханәмне тотам. Әмма бар эшчәнлегем моның белән генә чикләнми. Мин Татарстандагы XX-XXI гасырлардагы ювелир сәнгате үсеше темасына фәнни диссертация язам. Безнең совет чорындагы һәм хәзерге җирле ювелир сәнгате гомумән дә тиешенчә өйрәнелмәгән әле, шуңа күрә эшем актуаль дип саныйм».

– Данил, сез Татарстанда махсус мәдәни-һөнәри ювелирлык үзәге булдырырга кирәк дип саныйсыз. Ә моны ничек күзаллыйсыз?

– Республиканың сәнгати эшләнмәләр ясау белән шөгыльләнүче ювелирлары һәм шул ук вакытта татар ювелир сәнгате традицияләрен торгызучы ювелирларыбыз өчен үзәкләштерелгән мәйдан булдыруда күрәм. Әлеге үзәкнең беренчел максаты – нәкъ менә безнең төбәккә генә хас ювелир эшләнмәләр экспозициясе булуында. Бу үз нисбәтендә республикабызга туристларны җәлеп иттерәчәк, үзәк милли ювелир мәдәниятебезнең күпкырлы булуын ассызыклаячак. Параллель рәвештә татар ювелирлары көнкүрешен күрсәтеп бирә алырлык реконструкция мәйданы яисә ювелир сәнгатенә багышланган мини-музей да ачарга мөмкин дип исбатлыйм.

– Данил, сез Казанның иң беренче 3D дизайнер-ювелиры булып та саналасыз. Мондый төр ювелирлык юнәлешенә кайчан килдегез?

– 3D җайланмасын, санлы программа идарәле фрезер станогын иң беренче булып сатып алдым. Ювелир эшләнмәләрнең схемасын ясап, аларны шушы ысулда эшли башладым. Бу ул елларның иң алдынгы технологиясе иде.

Кайбер заказчыларга эшләнмәне берничә көн эчендә ижат итү, эшләнмәнең эскизын, визуаль картинасын алдан күрү дә бик мөһим. «Юк, мин барыбер башта балавыздан ясаячакмын», дип булмый, югыйсә, бу машинадан төшеп, кире ат арбасына утыру белән бер.

Данил Рәшитовның иҗади уңышларына да күз салыйк әле. Беренчедән, бу талант иясе Кол Шәриф мәчетендәге әлеге гыйбадәтханәнең кечкенә ювелир күчермәсен реставрацияләүгә үз өлешен керткән. Көмештән Сөембикә манарасының ювелир күчермәсен дә ижат иткән, Болгар җирендәге тарихи, архитектура комплексы композициясен ясаган. Аннары ювелир А.Гавриков белән берлектә югары дәрәҗәле кунакларга бүләк итү өчен заказ кабул итеп, Пётр һәм Павел чиркәве сынын ясарга алынган, шуларның берсен Казанга Татарстанның беренче Президенты М.Шәймиев белән очрашуга махсус килгән Һ.Клинтонга һәдия иткәннәр. Легендар шәхес А.Шварцнеггер губернатор вазифаларын үтәгәндә, аңа үзенчәлекле балдак та бүләк итеп салган Данил. Соңрак А.Шварцнеггер, балдакны ошатып, Данилга үз кул тамгасы белән Рәхмәт хаты да юллаган.

Быел зәркән остасы үзенең тагы бер якты максатын тормышка ашырды. Татарстан Мәдәният министрлыгы тарафыннан халык сәнгати һөнәрчелеген үстерү максаты буенча бирелгән грант акчасына ул көмештән, мельхиордан югары сыйфаттагы, татар орнаментлы бизәкләр һәм йөзекләр ижат итте.

Июнь ахырында әңгәмәдәшем Казан халык һөнәрчелеге техникумындагы чыгарылышның диплом яклау комиссиясе составында да булган. Оста өчен шунысы куанычлы, унбер студентның диплом эшләре арасында да татар ювелир сәнгатендә киң кулланылган филигрань ысуллы ювелир әйберләр дә булган.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 19.08.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2766

16+